А. Г. ЯХИН

Әдәбият

3

Икенче кисәк

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
3

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар телендә
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
3 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Икенче кисәк

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
рөхсәт ителгән

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 373.167.1:821.512.145*03
ББК 84(2Рос=Тат) я71
Я89

Рәссамнары:

Рәисә Сәйфуллина, Алексей Мамаев

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

- ?! — сораулар һәм биремнәр;
- — иҗади эш;
- — мөстәкыйль эш;
- — тиз, дөрес, аңлап уку өчен текстлар.

Яхин А. Г.
Я89 Әдәбият : Татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек : Ике кисәктә. Икенче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Мәгариф, 2010.— 159 б.
ISBN 978-5-7761-2066-4

ISBN 978-5-7761-2066-4

© «Мәгариф» нәшрияты, 2010
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2010

Вакыйгалар бәйләнеше.

Предметлар бәйләнешен искә төшерик.

Ат чанага җигелгән. Ат белән чана арасында бәйләнеш барлыкка килгән.

Имән агачы җирдә үсеп утыра. Агач белән җир арасында да бәйләнеш бар, диләр.

Кулыгызга каләм тотасыз — каләм белән сезнең арада бәйләнеш туа.

?! Башка бәйләнешләрне үзегез уйлап әйтегез.

Вакыйга — тәмамланган хәрәкәт, дип өйрәнгән идек. Агач утырту вакыйгасын күз алдына китерегез. Балалар, көрәкләр, үсентеләр тотып, мәктәп янына җыелалар, җир казып, агачлар утырталар һәм өйләренә таралалар. Бер вакыйга тәмамланды. Дәвам итегез, тагын бер вакыйга кушыгыз.

Тормышта вакыйгалар әнә шулай тыгыз бәйләнгәннәр.

«Вакыйга» һәм «бәйләнеш» атамалары белән танышыйк.

Предметның хәрәкәтенә вакыйга диләр. Вакыйга күп очракта әсәрнең бер өлеше була.

Ә менә бәйләнеш күп очракта бөтенләй күренми. Ике парта арасында нинди бәйләнеш булсын, ди.

Буш урын бит ул! Алай түгел икән шул. Алар янәшә торалар бит. Шуңа күрә парталар арасында янәшәлек бәйләнеше бар. Җитмәсә, парталар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаганнар. Шуңа күрә арада охшашлык бәйләнеше дә бар, дибез. Менә шундый кызыклы берәмлек ул — бәйләнеш. Үзе күренми, үзе бар.

«Әсәрдә бер генә вакыйганы да, бер генә образны да әсәрнең төп идеясен җанландыруга хезмәт итмәгән хәлдә кертмәскә, бер генә образны да «безработный» калдырмаска кирәк»,—дип язган Һади Такташ.

Такташ яшьләрне әсәр язарга әнә шулай өйрәтә. Эшсез, ягъни бәйләнешкә кермәгән вакыйга әсәргә кермәскә тиеш, ди.

Фикерләүче кеше, нинди генә һөнәр иясе булмасын, барыбер әйберләрнең бәйләнешләре белән эш итә. Охшашларын куша, охшамаганнары арасында каршылык, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре бар, ди.

«Ашыккан — ашка пешкән» мәкале безгә: «Ашыгып ашама, кайнар шулпа авызыңны пешерер»,— ди. Мәкальнең өлешләре өчәү: берсе — ашыгу, икенчесе — ашыгу аркасында ашка пешү, өченчесе — бәйләнеш (сәбәп). Кеше, ашыгып ашамаган булса, авызын пешермәс иде. Шуңа күрә ашыгу — сәбәп, авызны пешерү — нәтиҗә, дибез.

Бәйләнешләр күптөрле. Өченче сыйныфта еш очраганнары — *охшашлык.*

НАЧАР ГАДӘТЕ БАР...

Безнең песи үзе ишек ача белә,
Кирәк чакта ачып чыга, ачып керә.

Мияуламый, ялвармый ул беркемгә дә,
Йөри шулай бер бүлмәдән бер бүлмәгә.

Ачканда ул ача, ләкин яба белми.
Бу турыда уена да аның керми.

Ишек ачык кала бит дип исе китми.
Песи бит ул, — моңа аның башы җитми.

* * *

Охшатам мин Сәлимне дә шул песигә:
Ялынмый ул, ялвармый ул бер кешегә.

Теләгәнен үзе эшли һәммәсен дә:
Үзе тага, төшкән булса, төймәсен дә,

Төзәтә ул чанасын да, чаңгысын да,
Ясап куя хәтта радиоалгычын да.

Кыскасы шул: аның эшкә сәләте бар!
Ләкин аның бик начар бер гадәте бар:

Җыеп йөрми артыннан эш коралларын,
Кайда тотса, калдыра ул шунда барын.

Җыю аның уена да хәтта керми,
Һәммәсен дә әниләре җыеп йөри...

Әхмәт Исхак.

?! Шигырьне, песи холкы турында һәм Сәлим холкы турында дип, ике өлешкә бүлик. Вакыйгалар арасындагы бәйләнешне әйтегез.

Түбәндәге текстны үзегезгә бәя биреп языгыз. Сезнең Сәлимнән кайсы ягыгыз яхшырак һәм кайсы ягыгыз начаррак?

Сәлим — гап-гади өченче сыйныф укучысы. Без барыбыз да шундыйлар. Мин үзем дә — Сәлим кебек уңган бала. Кулымнан килмәгән бер генә эш тә юк. Бу яктан аңардан уздырам да әле. Мин дә төймәне үзем тагам. Ватык әйберләрне дә үзем төзәтәм. Күптән түгел, мәсәлән ... төзәттем. Ашаганнан соң, табак-савытны да үзем юам... (Дәвам итегез.)

Сәлим — ялкау малай. Мин кулыма тоткан бар нәрсәне үз урынына куям. Кыскасы, мин үзем — тәртип ярата торган уңган укучы... (Дәвам итегез.)

ЯХШЫЛЫККА — ЯХШЫЛЫК.

Күгәрчен, суда бер Кырмысканың батып һәлак булырга җыенуын күргәч, шунда ук авызына бер яфрак капты да суга ташлады.

Кырмыска ул яфрак өстенә менде дә, дулкын яфракны яр кырыена сөреп чыгарып, үлемнән котылды.

Бервакыт Аучы бу Күгәрченне ауларга әзерләнгәнен күргәч, Кырмыска, теге яхшылыкны искә төшереп, Аучының итек эченә керде.

Аучы Күгәрченне аулыйм дигән чакта гына, Кырмыска Аучының ботыннан бик каты тешләде. Авыртудан аучы кулындагы авын төшереп җибәрде дә, Күгәрчен, пррpx итеп, сәламәт очып китте.

Габдулла Тукай.

1. Хикәяне ике вакыйгага бүлегез. Аларны берәр генә җөмлә белән әйтеп бирегез. Икесенә дә исем табыгыз.

2. Күгәрчен Кырмыскага ни өчен ярдәм итә?
3. Кырмыска Күгәрченгә ни өчен ярдәм итә?
4. Ике вакыйга арасында нинди бәйләнеш бар?

АЛДАКЧЫ НАИЛ.

(Өзек.)

Нинди рәхәт! Кояш кыздыра. Су өсте җем-җем итеп тора. Яфраклар да селкенми, җил бөтенләй юк.

Җирдәге ком аякны пешерә. Менә шундый вакытта су керәсе килә. Без елга буена барабыз. Майкаларны, чалбарларны салабыз. Их, рәхәтләнеп, су коенырга тотынабыз: йөзәбез, чәчрәтәбез, чумабыз, узышабыз...

Беркөнне су коенырга Наил дә безнең белән ияреп барды. Ул да майкасын, чалбарын салды. Суга сикерде, йөзеп әчкә кереп китте.

Без кычкырабыз:

— Кермә, кермә, батасың!

Ә ул берни дә эндәшми. Бер кулын күтәреп, бер кул белән генә йөзә. Имеш, шундый батыр. Әй мактанчык! Безнең белән коенучы апа да кычкырды:

—Наил! Наил!

Ә бераздан Наил кырыйга борылды. Яр кырыена ук йөзеп килде һәм кинәт кычкырырга тотынды:

— Батам, батам, коткарыгыз!

Без йөзеп ярдәмгә киттек һәм гаҗәпләндек. Ул урын сап-сай, ә Наил бата.

Наилнең кулыннан тоттык, кырыйга ук сөйрәдек. Ул күзләрен йомган, үлгән кеше кебек ята. Ә без бик

курыктык. Апа да курыкты. Ул, Наилне күтәреп, яр кырыена алып чыккан иде:

— Ха-ха-ха! — дип, Наил шаркылдап җибәрде. Без шатланып киттек. Апа да куанды. Кояш болытка күмелгән иде, ул да чыкты, нурларын чәчәргә тотынды.

Апа:

— Алай алдакчы булырга ярамый,— ди.

Наил әйтә:

— Мин уйнап кына.

— Уйнап кына да ярамый,— ди апа.

Абдулла Алиш.

1. Хикәянең беренче вакыйгасы тәмамланды. Аны үз сүзләрегез белән сөйләп чыгыгыз да укыган өлешенә исем бирегез.

2. Хикәянең дәвамын — икенче вакыйгасын, үзегез уйлап, дәфтәрләрегезгә языгыз. Башта аңа исем уйлап табыгыз.

3. Наилгә иптәшләренең мөнәсәбәте турында сөйләгез.

СҮЗ БИРДЕМ.

Бик кызганыч, мин ул бәләкәй малайның исемен дә, торган җирен дә, әтисе белән әнисенең кем булуын да әйтә алмыйм. Караңгыда мин аның хәтта йөзен дә рәтләп күрә алмадым. Борынында сипкел бар иде кебек. Кыскасы, ыштаны җилкәсеннән төшкән бау белән корсак турысында каптырылган иде.

Беркөнне бакчада караңгы төшкәнче китап укып утырдым. Бакча капкасын бикләп куярлар дип, ашыга-ашыга чыгу ягына таба барганда, кинәт туктап кал-

дым. Читтәге куаклык артында кемнеңдер елаганын ишеттем.

Шул якка киттем. Бара торгач, тәрәзәсез ак төстәге таш сарайчыкка килеп чыктым. Сарайчык янында сигез яшьләрдәге малай басып тора. Башын аска иеп, ярсый-ярсый елый.

— Ни булды, үскәнем, ник елыйсың? — дип сорадым.

Малай кинәт елаудан туктады да, төз басып, миңа карады.

— Берни булмады.

— Алайса, нигә елыйсың соң?

Ул әле күз яшьләрен йотып бетермәгән иде, шуңа күрә сүзләрен бик авырлык белән генә әйтте.

— Караңгы төште. Бакча капкасын бикләрләр. Әйдә, киттек, — дидем мин. Малай кулын минем учтан тартып алды.

— Китә алмыйм.

— Нигә китә алмыйсың?

— Сакчы мин. Постта торам.

— Нинди сакчы?

— Шуны да аңламыйсыз. Уйныйбыз без. Мин уендагы сакчы.

— Кем белән уйныйсың соң син?

— Белмим. Мин эскәмиядә утыра идем. Олы яшьтәге малайлар килделәр дә: «Сугыш-сугыш уйныйсың киләме?» — дип сорадылар. «Килә», — дидем. «Алайса, син — сержант. Менә бу йорт — порох келәте. Шуны сакла», — диделәр. «Ярар, сакларммын», — дидем. «Мине, килеп, башка берәү алыштырганны көтәрмен. Моннан китмәм дип, сүз бир», — диделәр. «Моннан китмәскә сүз бирәм», — дип җавап бирдем.

— Сине монда кайчан куйдылар соң?

— Якты иде әле.

— Кайда соң алар?

— Киттеләр. Мине оныттылар.

— Шулай булгач, нишләп торасың соң монда?

— Торам дип сүз бирдем бит.

Көлеп җибәрә яздым. Ләкин көлү урынсыз булуын аңлап алдым. Ә бит малай хаклы, дип уйладым. Сүз биргәч үтәргә кирәк. Хәтта уйнаганда да үтәргә кирәк.

Малайга ничек ярдәм итәргә? Сакларга кушып кайтып киткән юньсез малайларны алып килер идем, аларны төнлә табып буламыни! Ә кеше ач килеш, туңып, сакта тора.

— Ашыйсың килә торгандыр? Бар, өеңә кайт та ашап кил. Син килгәнче, сакта үзем торырмын, — дидем.

— Ярамый. Син хәрби кеше түгел бит, — дип җавап бирде.

— Дөрес әйтәсең. Сине хәрби кеше генә азат итә ала, — дидем мин, бераз уйлап торгач.

?! Өзектәге вакыйганы үз сүзләрегез белән сөйләп чыгыгыз. Вакыйгага исем бирегез.

Малайны сүз бирүеннән хәрби кеше генә азат итә алгач, шундый кешене табарга кирәк дигән фикергә килдем. Малайга: «Аз гына көт», — дидем дә капкага таба чаптым.

Хәрбине шактый эзләгәннән соң гына таптым. Хәрби киемле берәү трамвайга керергә торганда, терсәгеннән тоттым да:

— Иптәш майор! Бер генә минутка керми торыгыз әле, — дип туктаттым һәм хәлне сөйләп бирдем.

Майор шунда ук ярдәм итәргә риза булды.

Бакча капкасын бикләргә генә торалар иде. Караңгыда әлеге ак йортны шактый эзләгәннән соң гына таптык. Малай шул ук урынында басып тора. Башын аска иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә елый.

— Менә хәрби кеше алып килдем, — дигәч, шатлыгыннан кычкырып җибәрде. Елаудан туктады. Гәүдәсен турайтып басты.

?! Бу өзек вакыйгасын да үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аңа да исем бирегез.

— Иптәш часовой, сез сержант икәнсез. Иптәш сержант, сезгә тапшырылган посттан китәргә приказ бирәм. Мин — майор.

— Тыңлыйм, иптәш майор. Посттан китәргә приказ бирелде, — диде көр тавыш белән малай.

— Молодец, иптәш сержант! — диде майор. — Синнән менә дигән сугышчы чыгачак. Сау бул.

— Караңгы бит. Өеңә озатып куйыйммы? — дип сорадым.

— Кирәкми. Безнең өй моннан ерак түгел. Мин кайтырга курыкмыйм, — диде малай.

Мин аның кечкенә сипкелле борынына карадым да шундый ихтыяр көче һәм ныклы сүзе булган малай ничек өенә кайтырга курыксын дип уйладым. Ул хулиганнардан да, караңгылыктан да, башка куркыныч нәрсәләрдән дә курыкмаячак.

Шундый малай белән танышуыма мин бик шат идем.

Алексей Пантелеев.

?! **1.** Хикәянең өченче вакыйгасын да үз сүзләрегез белән сөйләп чыгыгыз.

2. Өзекләрне бергә кушып сөйләгез.

3. Малай белән аны коткаручылар арасында нинди бәйләнеш барлыкка килде?

4. Шундый батыр малай нигә елый да елый? Җавап тапсагыз, хикәядәге тагын бер бәйләнешне күрәчәксез.

Сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше.

Җил белән агач ничек бәйләнгән?

Беренче вакыйга. Җил исә. Агач яфраклары арасына кереп уйный-уйный да күршедәге агачка күчә.

Икенче вакыйга. Агач шуны гына көтеп утырган кебек бөгелә, сыгыла, яфракларын лепердәтә-лепердәтә, җилгә рәхмәт әйтә. Җил үтеп киткәч, аның тагын килүен көтеп тынычлана.

Җил исмәгән булса, агач әрле-бирле бөгелмәгән-сыгылмаган булыр иде. Димәк, җил — агачны хәрәкәткә китерүче сәбәп, ә агачның хәрәкәте шуның нәтиҗәсе булды. Мондый бәйләнешкә **сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше** диләр.

Өченче вакыйга. «Утсыз төтен булмый» мәкалендә дә ике вакыйга бар. Беренчесе мондый: бер кеше коры-сары җыйган да учак яккан. Һавага кара төтен күтәрелгән — ут төтен чыгуның сәбәбе булган. Мәкальнең эчтәлеге шундый.

Ләкин шул ук мәкальнең мәкаль әйтүче (автор) салган мәгънәсе дә бар.

Бер кыз әнисенә, мине сыйныф кызлары яратмыйлар, дип зарланган.

Әнисе кызына: «Утсыз төтен булмый», — дип җавап биргән.

?! Әнисе кызына нәрсәне аңлатырга тырышкан?

* Ни чәчсәң, шуны урырсың.
* Калган эшкә кар явар.
* Ашыккан — ашка пешкән.

?! Мәкальләрнең үзегез теләгәнен сайлап, вакыйга итеп сөйләгез.

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Бер укучы бала гел «2»легә генә укый икән. Әнисе аны:

— Нигә син гел «2»леләр генә аласың? — дип, бик каты орышкан. Баласы:

—Үзең иртәрәк уятмыйсың бит. Мин мәктәпкә барганчы, «4»ле, «5»ле, «3»леләрне алып бетерәләр дә, миңа «2»леләр генә кала,— дигән.

?! 1. Мәзәктәге сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен табыгыз.
2. Әнисе улын орышкан. Әгәр орышу сәбәп булса, аның нинди нәтиҗәләре була ала? Җавабыгызны дәфтәрләрегезгә языгыз.

ЯШӘҮ.

Бөреләр үрли кояшка,
Балалар йөгерә уйнап...
Күчә-күчә илдән илгә,
Май килә дөнья буйлап.

Мөдәррис Әгъләмов.

?! Шигырьне икегә бүлегез. Бер якта — сәбәп вакыйгасы, икенчесендә нәтиҗә вакыйгасы булсын.

АПРЕЛЬ АЕ.

Апрель ае шук икән,
Бөтен карны юк иткән.
— Мин килдем,— дип әйткән икән,
Бозлар аккан да киткән.
Менә ул нинди икән!

Кыш та үтеп киткән күк,
Яз да җитмәгән сыман.
Чылтыр-чылтыр ага сулар
Тау-ташлар арасыннан.

— Яз җиттеме? — дип сорадым
Мин песи баласыннан.
Ул йөгерде сорарга дип
Үзенең анасыннан.

Анасы кояш нурында
Йоклаган бүрәнәдә.
Тыныч йоклый, төшләр күреп,
Салкын җил өрмәгәнгә.

Әминә Бикчәнтәева.

?! **1.** Шигырьдә сәбәп һәм нәтиҗә вакыйгаларын табыгыз.

2. Песи баласы әнисен йокысыннан уятып: «Әни, яз җиттеме?» — дип сорый. Әнисе баласына үзенчә аңлата. Ничек аңлата? Песи баласы шуннан соң нәрсә эшли? Шигырьне дәвам итегез.

СУ АНАСЫ.

(Бер авыл малае авызыннан.)

I

Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән,— юк янымда юлдашым.

Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап.

Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.

Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.

Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага,
Җен онытткан, ахры,— калган тарагы басмада.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.

Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба,—
Аһ, харап эш! — Су анасы да минем арттан чаба.

Кычкырадыр: «Качма! качма! Тукта! тукта, и карак!
Ник аласың син аны,— ул бит минем алтын тарак!»

Мин качамын — ул куадыр, ул куадыр — мин качам;
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк, ичмасам.

Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,
Су анасыны куарга күтәрелде барча эт!

«Вау!» да «вау!» да «һау!» да «һау» — бертуктамый
этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.

Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;
И явыз карчык! тарагыңнан коры калдың, дидем.

Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым!» — дидем;
«Сусадым, ардым, әни,— мин бик озак чаптым»,— дидем.

Сөйләгәчтен кыйссаны[1], алды тарагымны әни;
Курка үзе алса да,— уйлый эченнән әллә ни...

II

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.

---

[1] Кыйсса — хәл, вакыйга.

Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
«Шык!» та «шык!» — кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.

Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле.
Бу тавышка сискәнеп торган йокысыннан әни:

— Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери!

— Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак!

Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам: «Ходай! — дим,— инде мин
кайда барыйм?»

Һич өзексез «шык!» та «шык!» безнең тәрәзәне кага;
Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага.

Әнкәем алтын таракны тиз генә эзләп табып
Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып.

Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине!

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә, иясе юк!» — дип, әйберләргә тими башладым.

Габдулла Тукай.

?!
1. Шигырьне вакыйгаларга бүлегез.
2. Төп вакыйга — сәбәп-нәтиҗә вакыйгасы. Шуны табыгыз.
3. Шул вакыйганы бик кыска итеп әйтегез.

ХӘЙЛӘКӘР ӘТӘЧ.

Борын-борын заманда бик матур, бик батыр хәйләкәр бер Әтәч булган. Әтәч бервакыт урамда йөргәндә алтын балдак таба да муенына кия. Моны бер бай күреп ала. Балдагыңны бер атнага биреп торсаң, мин сиңа тары бирер идем, ди. Әтәч тиз күнә. Бер атнадан соң кире бирү шарты белән, балдагын байга биреп тора. Атна үткәч, Әтәч, байга барып, балдагын сорый. Ә бай бирмичә куып чыгара. Ике көннән соң Әтәч тагын бай янына китә. Бара-бара Әтәчкә зур Аю очрый.

— Әтәч, кая барасың? — дип сорый Аю.

— Байга алтын балдагымны сорарга барам,— ди Әтәч.

— Мин дә барыйм әле,— дип үтенә Аю.

— Әйдә, кер эчкә,— ди Әтәч. Аю Әтәчнең авызыннан эченә кереп китә.

Тагын китә бу. Бара-бара каршына Бүре килеп чыга.

— Әтәч, кая барасың? — дип сорый Бүре.

— Байга алтын балдагымны алырга барам, — ди Әтәч.

— Мин дә барыйм әле? — дип сорый Бүре.

— Әйдә, кер эчкә, — ди Әтәч. Бүре Әтәчнең авызыннан эченә кереп китә.

Бара торгач, Әтәчкә Төлке очрый...

?! 1. Дәвам итегез. Төлке вакыйгасын үзегез сөйләгез.

Байга барып җиткәч, Әтәч капка башына менә дә:

— Бай абзый, алтын балдакны бир! — дип, берничә мәртәбә кычкыра.

Бай, хезмәтчеләренә әйтеп, Әтәчне тотарга куша. Әтәчне тоталар. Әйдә, атлар таптап үтерсен дип, атлар абзарына ябалар. Абзарга керү белән, Әтәч: «Аю, чык эчтән», — ди. Аю чыгып, атларны кыйнап ташлый да Әтәч эченә яңадан керә.

Икенче көнне, тәкәләр, сарыклар сөзеп, таптап үтерсен дип, Әтәчне сарыклар абзарына ябалар...

?! **2.** Шуннан соң нәрсә була? Әкиятне дәвам итегез.

Өченче көнне, казлар талап үтерсен дип...

?! **3.** Шуннан соң нәрсә була?

Дүртенче көнне, инде болай булмый икән дип, Әтәчне коега ташлыйлар. Коега төшү белән, Әтәч: «Су, кер эчкә!» — ди. Кое эчендәге су Әтәч эченә керә дә бетә.

Бишенче көнне, мичкә бик көчле ягып, янып үлсен дип, Әтәчне мичкә аталар. Әтәч, мичкә керү белән: «Су, чык эчтән!» — ди. Кое суы, Әтәч эченнән чыгып, мичтәге утны сүндерә. Шуннан соң Әтәч эченнән Аю, Бүре, Төлке чыгып, байны бәргәләп ташлыйлар. Балдакны һәм байның бөтен малын алып, көлешә-көлешә кайтып китәләр.

— Кеше балдагына кызыксаң, шулай була ул, — ди Әтәч.

?! **4.** Әкиятне, кыскарта-кыскарта, өч өлешкә бүлегез. Аннан соң сәбәп-нәтиҗә вакыйгаларын әйтегез.

5. Авторлар юри адәм ышанмаслык итеп арттырган урыннарны табыгыз.

АНА БӘЕТЕ.

Аклы ситсы күлмәгемнең
Җиңенә кара тигән,
Кайгы-хәсрәт бик куәтле,
Башымны җиргә игән.

Сандугачның балалары
Кара түгел, бар да ала,
Аналарыннан аерылды
Матур, таза биш бала.

Бу дошман бик куәтлеме,
Әйтегезче, чибәрем?
Берәү-икәү генә түгел,
Биш малайны җибәрдем.

?! **1.** Ана хәсрәтенең дәрәҗәсен табыгыз.
2. Хәсрәт хисенең сәбәбен әйтегез.

1. Түбәндәге вакыйгаларның сәбәпләре генә әйтелде. Нәтиҗәләрен табып языгыз.

Яңгыр яуса ...
Ай калыкты ...
Юл пычранды ...
Минем китап бик таушалган ...

2. Бу юлы вакыйгаларның нәтиҗәләре генә әйтелде. Сәбәпләрен табып языгыз.

Күлмәк җиңе ертылды ...
Өйгә кергәч, әти бик мактады ...
Тамакка салкын тиде ...

ИКМӘК ВАЛЧЫГЫ.

Юлга чыга ике юлдаш —
Бай белән ярлы.
Бай тук була, ә ярлы ач —
Буш була карыны.

Юл киселә, бара торгач,
Бер текә ярда.
Ашап ял итмичә булмас —
Туктыйлар ялга.

Күмәч белән ашый берсе
Маен, итләрен...
Суга манчый икенчесе
Каткан икмәген.

Туйгач, ярлы ашын төрә,
Җыя янчыгын,
Шунда ул җиргә төшерә
Икмәк валчыгын.

Алырга дип иелгәндә,
Киткәндәй качып,
Тоттырмый бит бер дә генә,
Тәгәри валчык.

Валчыкны тотам дип, ярлы,
Сикерә-йөгерә,
Шулай итә-итә, ярның
Төшә төбенә.



Менә ул валчыкны өреп,
Кадерләп ала...
Ә бай юлчы моны күреп
Шаккатып кала.

«Таудан валчык кына ташлап
Шулай төшә алгач,
Мин төшәрмен бигрәк ансат —
Мин ташлыйм калач!» —

Ди дә ата бер түгәрәк
Калачны аска,
И китә шунда, тәгәрәп,
Ул таштан ташка.

Бай чаба калач артыннан —
Юл хәтәр, ай-яй!
Тукта, бу ни? Яр башыннан
Мәтәлә бит бай...

Менә шунда, ике күзем,
Әкият тә бетә.
Истә тот бабайлар сүзен:
«Икмәк рәнҗетмә!»

Нури Арсланов.

?! Шигырьне ике өлешкә бүлегез. Алар арасында каршылык бәйләнеше булуын аңлатыгыз.

ТЫЛСЫМЛЫ КОЕ.

Кайчандыр бик саран хан яшәгән. Аның бердәнбер кызы булган. Кызы, киресенчә, игелекле, юмарт икән. Әтисенең хәер сораучыларны сарайдан куып чыгарганын күрсә, елый-елый:

— Шул хәерчеләргә бер кисәк ипи кызгандыңмы? Бераз ипи бирсәң, ризыгыбыз бетәр идеме? — дия торган булган.

Әтисенең кызына ачуы чыккан.

— Тагын бер генә мәртәбә каршы әйтсәң дә, беренче очраган хәерчегә тоттырам да җибәрәм. Хәерче хатыны булып яшәрсең. Менә шунда авызыңа кабарлык икмәк кисәге булырмы-юкмы — белербез, — дип кычкырган.

Шул сөйләшүдән соң күп тә үтмәгән сарайга бер хәерче егет килеп кергән. Ханның кулына таяк алуы булган, кызы егет алдына килеп баскан да:

— Кума, эти. Бер ярлыга аз-маз хәер биргәннән бөлмәбез, — дигән.

Хан ачуыннан нишләргә белмәгән:

— Кем бар анда! Ишәк китерегез! — дип кычкырган.

Ишәкне китергәннәр. Хан, кызы белән хәерчене ишәккә атландырып, икесен дә сарайдан куарга кушкан. Кызын ул:

— Кемнең авызына кабарлык икмәге юклыгын белерсең моннан соң! — дип озаткан.

Ә егет кызга, кыз егеткә бер күрүдә гашыйк булган. Тиздән туйларын да уздырганнар.

Егет хан кызын тауга алып менгән, тау тишегенә кертеп, мин менә шушында яшим, дигән.

Тау тишегендәге начар гына ятагында егетнең әнисе авырып ята икән.

Егет ничек өйләнүен әнисенә сөйләп биргән. Чирле карчык авыр сулап куйган да:

— Язмышыгыз шулдыр. Бәхетле булыгыз, — дип, теләк теләгән.

Әнисе егетне таныш сәүдәгәренә җибәргән. Ул сине дөяләр куучы итеп эшкә алыр, дигән.

Сәүдәгәр егетне эшкә алган. Әниеңә, хатыныңа бир, ерак юлга чыгасың дип, акча тоттырган. Өч көннән егетебез сәүдәгәрләр белән ерак юлга чыккан. Көн артыннан көн үткән. Товар төялгән дөяләр сап-сары чүлләрдән барганнар да барганнар. Бара торгач, тирән кое янына туктаганнар.

Коега төшүчегә бирү өчен, акча җыйганнар. Ләкин үзе теләп төшүче күренмәгән.

— Мин төшәм, ни булса, шул булыр, — дигән егет.

— Төшә күрмә, анда төшкән кешенең менгәне юк. Әниеңне кызган, — дип үгетләгәннәр танышлары.

— Сусыз барыбыз да үләчәкбез, төшәм, — дигән егет һәм, су савытларын алып, аска төшеп киткән.

Су тутырылган савытларны югарыга менгергәннәр. Егетне тартып алу өчен, озын аркан төшергәннәр. Ләкин менеп җиттем дигәндә генә, кое стенасы ярылып, егетне кемдер ярыкка сөйрәп керткән.

Җир асты яп-якты икән. Егетне чиртсәң очып китәрлек өрәктәй ябык кеше һәм ташбака каршы алган. Егет як-ягына караган: уңда да, сулда да тынсыз кешеләр ята икән.

Ябык кеше егет күзенә текәлеп караган да:

— Мин сиңа өч табышмак әйтәм. Җавапларын тапсаң, бүләкләр биреп азат итәм. Җавапларын таба алмасаң, менә шушы кешеләр кебек, монда ятып калырсың, — дигән.

— Ярый, язмыштан узмыш юк. Әйт табышмакларыңны, — дигән егет.

— Бу дөньяда балдан да баллырак ни бар? — дип сораган өрәк.

— Дөньяда яраткан кешеңнең иреннәреннән дә татлы берни юк, — дип җавап биргән егет.

Өрәкнең чырае ямьсез киткән, гәүдәсе калыная төшкән, ә ташбака кабыкчасы шартлап ярылган.

— Бу дөньяда күңелледән дә ни күңеллерәк? — дип, өрәк икенче табышмагын әйткән.

— Яраткан кешең белән яшәү, — дип, аз гына да тоткарланмыйча җавап биргән егет.

Өрәккә кеше төсе керә башлаган. Ә ташбака кабыкчасы, челпәрәмә килеп, җиргә коелган.

— Бу дөньяда матурдан да матур ни матур? — Монысы — өрәкнең өченче табышмагы.

—Яраткан кешең матур,— дип, бер дә шикләнмичә әйтеп салган егет.

Бу сүзләрне ишеткәч, ташбака кинәт бик чибәр кызга әйләнгән. Ябык кеше дә юкка чыккан, аның урынында бик чибәр ыспай егет пәйда булган.

—Без бер-беребезне яратабыз,— дигән егет хәерче егеткә.—Туебызның икенче көнендә безне явыз сихерче сихерләде. Яраткан кешеңә тугрылыгыңны күрсәтеп, син бездән сихер көчен алдың. Ә җирдә яткан кешеләргә карап:

—Әй! Әсирләр, уяныгыз! Сез иркле хәзер! — дип кычкырган. Һушсыз яткан кешеләр шунда ук сикереп торганнар.

—Без үз юлыбыз белән китәбез, син коедан чык,— дип, сүзен дәвам иткән егет.— Күргән-белгәннәргә әйт, моннан соң коедан кем күпме тели, курыкмыйча су алсын,— дип өстәгән.

Хушлашканда, хәерче егеткә ике кып-кызыл гранат җимеше бүләк иткән.

Егетне коедан сөйрәп чыгарганнар. Ул юлдашларына башыннан үткәннәрне сөйләп биргән. Сәүдәгәрләр, хәйран калып, коега төшүче өчен җыйган алтыннарын биргәннәр.

Кузгалып китәргә генә торганда, тәмам хәлдән таеп, тагын бер кәрван килеп туктаган.

—Суыгызның бер өлешен бирмәссезме! — дип ялварганнар кунаклар.

—Хәзер коедан кем күпме тели, шулкадәр су ала ала,— дип ышандырырга тырышкан безнең егет. Ләкин кунак сәүдәгәрләр аңа ышанмаганнар. Букчаларын тутырып, алтын биргәннәр дә, суны үзең алып бир, дип ялынганнар.

Хәерче егет бер дә көтмәгәндә баеган. Барлык алтыннарын һәм ике гранат җимешен каршы килгән кәрван башлыгына биргән. Әни белән хатыныма тапшырыгыз, дип үтенгән.

Кәрван башлыгы егет гозерен үтәгән. Акча белән җимешләрне мескен хатыннарга тапшырган. Хатыннар шатланып туя алмаганнар. Хан кызы, каенанасын сыйлыйм дип, гранат җимешен ачып җибәрсә — орлыклар урынына эче тулы менә дигән энҗе икән!

Хан кызы, иң оста табиблар чакыртып, каенанасын дәвалаган. Аннары ире кайтуына хан сараедай йорт салдырган. Сарайны әтисенең тәрәзә каршындагы биек тауга утырткан. Ул сарайның кирпечләре алтын белән көмештән булган.

Хан, иртән торып, сарайны күргәч, һуштан язар хәлгә җиткән.

— Мондый могҗизаны кем салдыра алыр? — дип баш ваткан. Ләкин күпме белергә теләсә дә белә алмаган.

Өч ел үткәч, хәерче егет кәрваны белән кайтып төшкән. Әнисе белән хатыны каршы чыгып алганнар. Яңа өйләренә таба юнәлгәннәр.

Егетебез сәяхәттән дә буш кул белән кайтмаган икән. Өчәүләп матур гына тормыш иткәннәр.

Күпмедер вакыт үткәч, хатыны иренә:

— Әтине кунакка чакырып кайтмассыңмы? — дигән.

Егет, бүләкләр алып, хан сараена киткән. Бүләкләрен тапшырган. Хан чиксез шатланган: аның бүләк энҗедәй зур энҗене беренче күрүе булган.

Ханны яңа сарайда зурлап каршы алганнар. Кызы битен челтәр япкыч белән каплаган булган. Шуңа күрә хан кызын танымаган.

— Бу кадәр байлыкны кайдан алдыгыз? — дип сораган.

— Юмарт кешенең авызына кабарга икмәк кисәге һәрвакыт була, — дип җавап биргән кызы.

Хан, бу сүзләрне ишеткәч, хәсрәткә баткан.

— Кызым һаман шулай дия торган иде. Ә мин аны кызып китеп куып чыгардым. Кайда икәнлеген белсәм иде, — дигән.

Хан кызы битлеген күтәреп куйган. Әтисенә башыннан үткәннәрне сөйләгән. Хан шатланган. Туйга бөтен шәһәр халкын чакырган. Җиде көн күңел ачкан халык.

?! Хан саран. Саранлыгы аркасында явызлык эшләгән: хәерчене мыскыл иткән, кызын, мәсхәрәләп, сарайдан кудырган. Ханның бу яман эшләре сәбәп булса, сәбәпнең нәтиҗәсен табыгыз.

Габделхәй Сабитовның ике хикәясе белән танышыйк.

Әдипнең барлык әсәрләре диярлек мәктәп дәреслекләренә кергән. Менә нинди оста язучы иде ул. Аның хәтта сез өйрәнәсе балачак истәлекләре дә бик матур хикәяләр дәрәҗәсендә язылганнар. Үзенең ничек иҗат итүе турында язган кыска гына өзекне укысагыз, әсәрләренең һәр юлына, һәр сүзенә ничек игътибарлы булуын күрерсез. Укучыларын яраткан һәм хөрмәт иткән әдип кенә әсәренә шулай җан җылысын кушып яза ала.

Менә ул өзек:

«Гадәттә, мин кулъязмаларымны сакламыйм, басылып, беренче нөсхәсе кулга керү белән ерткалап ташлыйм... Әгәренки кайчан да булса, ягъни үзем теге ...

төп йортка кайтып киткәннән соң, балалар, кардәшләр актарып караса, Ходай сакласын, һич тә үрнәк булырлык түгел ләбаса. Берәүләр әнә бер тын белән кирпечтәй роман язып ташлый, ә мин кечкенә генә хикәяләр белән дә күпме җәфа чиккәнмен, сүзнең төгәл мәгънәсен таба алмыйча, биш-алты сүз алмаштырып язганмын да сызганмын. Кайчак бер өем кәгазь исраф итеп[1], шуннан күңелгә ятышлы, төгәл фикерле нибары ике-өч җөмлә калган... Ә менә шушы истәлекләремнең кулъязмасы иске китаплар арасына кысылып, ничектер сакланып калган...»

Габделхәй Сабитов — өлкән яшьтәге әдип, үзенең балачактагы кичерешләре турында яза. Сез дә моннан өч-дүрт кенә ел элек булган кичерешләрегезне искә төшереп карагыз әле. Искә төшерүе ансат булмас, билгеле. Ә Габделхәй Сабитов балачактагы кичерешләрен бөтен нечкәлекләре белән хәтерли. Истәлекләрне укыганда, шуңа игътибар итегез.

ТӘҮГЕ ШАТЛЫК.

Адәм баласы, дөньяга килгәч, иң беренче авыр кайгысын ана сөтеннән, имчәктән аерылган вакытында кичерә, имеш.

Башка барлык сабыйлар кебек, мин дә ул кайгымны хәтерләмим. Ә менә беренче зур шатлыгым ярыйсы гына хәтеремдә.

Кыш буе каты авырып яттым.

---

[1] Исраф итеп — әрәм итеп.

Инде бу бала кеше булмас дип, авызыма су тигезеп саклаганнар.

Ә мин, әрсез, берәү дә көтмәгәндә тернәкләнә[1] башладым.

Тәрәзәгә каткан калын боз катламын эретеп, өйгә бер бәйләм язгы кояш нуры сирпелде. Көч-хәл белән кулымны күтәреп, нур юлына учымны куйдым.

Шунда бөтен тәнемә ниндидер бер рәхәт, үтә ләззәтле җылылык йөгерде. Җир йөзендәге барлык җан ияләрен бар иткән күк кояшы миңа да өлеш чыгарды, тагын бер артык тамакны яшәргә, ашарга азындырды.

— Әни, карыным ачты,— дим.

— Һай, Алла! Һай, бәрәкәт! Каян чыкты әле бу? — дип таң калды әни.— Кыстап-кыстап та каптырып булмый иде ләбаса. Кичәгенәк тә нинди тәмле тавык шулпасын түкереп кенә ташладың. Йа Раббем, сихәтләнергә булсын. Котымны алдың бит, бәбкәчем. Мә, кабып кара әле.

Кабу гына түгел, авыз тутырып йоттым тавык шулпасын. Туймастай булып, комсызланып ашарга керештем. Китергән кадәрлесен бетергәч:

— Тагын! — дидем.

Китте-барды шул көннән. Азык төткәрә[2] алмыйлар. Тугыз-ун яшьлек апам йөгерә. Әти өйдә чакта, берсенә дә ирек куймыйча, үзе кылбырдак килә[3].

Мул заман түгел. Үзләренә арыш умачы, миңа исә һаман тәмлесе килеп тора. Күрше-күлән түтиләр дә,

---

[1] Тернәкләнү — ныгу, терелү, аякка басу.

[2] Төткәрү — җиткерү.

[3] Кылбырдак килү — ыгы-зыгы килү.

«Габделхәй энемә» дип, еш кына майлы кызыл эремчек, кыстыбый-фәлән кертә.

Тәнемдә көн саен, сәгать саен хәл-җегәр арта барганны тоям. Әмма аягыма баса алганым юк әле. Язгы тамчылар тамганын тәрәзә аша күзәтеп, оеп кына ята бирәм. Кичләре салкын, тәрәзә пыяласын көмеш абагалар бизәкли.

Көннәрдән бер көнне, кайры туныннан салкын исе аңкытып, әти кайтып керде. Никтер бик шат күренә, авызы ерылган.

— Улым! Мин сиңа бик шәп бүләк алып кайттым бит әле!—ди. Тун изүен ычкындырды да, куеныннан ниндидер төенчек чыгарып, идәнгә куйды.

Төенчек тере иде.

Көчек!

Кып-кыска кәкре аяклы, сары түшле, кара төймә борынлы, йомгактай түгәрәк аклы-сарылы көчек.

Нинди тойгылар шаукымы кеч биргәндер — аңлата алмыйм. Үзем яткан агач караватартына тотынып, ничек идәнгә төшеп басканымны да хәтерләмим.

Әти белән әни хәтта куркып та калдылар кебек. Апа, сикергәли-сикергәли, кул чәбәкли:

— Терелде, терелде, йөри башлады.

Ләкин... Көчек янына барыйм дип, кулымны карават башыннан ычкындыруым булды, тезем сыгылып төште дә лып итеп идәнгә утырдым. Тик уема һичбер шик-шөбһә килмәде, мүкәләп киттем... Мин барам, идән сайгагы буйлата әвеш-тәвеш[1] атлап, көчегем каршы килә... Очраштык.

Һәм вәссәлам.

---

[1] Әвеш-тәвеш — кыек-мыек.

Күңелемнең моңарчы өнсез торган әллә нинди кыллары шунда зыңлый башлады, ахрысы. Гомер буена башымны исәр иткән бииһая[1] көчле хис — җиһанга, тереклек ияләренә тыелгысыз мәхәббәт хисе әнә шул мизгелдә уянгандыр, дип уйлыйм.

Тәгаен, шулай булгандыр.

Чөнки, әйткәнемчә, бу язда бер бәйләм кояш нуры тәнемә тереклек сулышы өрде, кәкре тәпиле йөнтәс бер мәхлук аякка бастырды.

Һәм әнә шул көннән күңелемдә адәм баласына хас төрледән-төрле хис-тойгылар туа башлады.

Габделхәй Сабитов.

?! Истәлектәге вакыйгаларны сөйләргә әзерләнегез, сөйләр өчен, үзегезгә план төзегез. План әсәрне вакыйгаларга бүлә. Мәсәлән, планны болай башларга мөмкин:

а) Кечкенә Габделхәйнең авыруы турында... (Дәвам итегез.)

---

[1] **Бииһая** — очсыз-кырыйсыз.

— Көннәр матурланды, урамга чыгарсың, улым,— диде әни. Бөкре Искәндәрдән кечтек кенә чабаталар үрдереп кайтты.

— Кара әле, нинди чибәр итеп үргән! — дип соклана үзе.— Гарип булса да, кулы алтын бичараның.

Чабаталарымны киеп, иң элек өйдә арлы-бирле йөрдем, аяк сынадым.

— Кар суы үтәр,— диде әти. Сөяннән күтәртмә[1] ясап, чабата табанына беркетте.

Өйалды ишеген ачуга, йөземә кояш җиле бөркелде. Шактый вакыт күзләремне ача алмый тордым. Ачып баксам, тәмам өнсез калдым. Хәйран тамаша! Менә нинди икән ул дөнья дигәннәре!

Әлегә эреп бетмәгән уйдык-уйдык бозларга, йөгерек гөрләвекләргә таң калып карап тордым. Кыектан тып-тып тамган кояшлы тамчыларны учыма җыярга теләдем — ябык бармакларым арасыннан агып беттеләр.

Келт итеп исемә төште: Полканым күрми кала бит шушындый тамашаны.

Полкан дигәнем әлеге карсак көчегем инде. Ни өчен Полкан икәнен уйлаганым булмады. Алып кайткан көнне үк әти:

— Полкан исемле ул, улым, усал булыр, шәт! — дигән иде. Соңынтынрак төшендем: Полкан, Махно, Колчак нindидер усал атаманнар булганнар икән. Ул

---

[1] Күтәртмә — аякны юешләтмәс өчен, чабата астына куела торган ике агач шакмактан гыйбарәт җайланма.

чакларда, шуңа, этләре усал булсын дип, шундый исем кушканнар.

Алып чыктым Полканымны. Баскычның соңгы басмасына куйдым. Уйлап та бирмәде, ишегалдына җыелган күлдәвеккә таба китте.

Ә күлдәвек янында, сыңар аягына басып, ата каз моңаеп тора иде. Әйдә, сәке астында, йомырка баскан ана казны шулай көтә ул.

Якынлашып килгән көчекне күрүгә, шунда ук икенче аягы да пәйда булды. Ул, муенын алга сузып, киң канатларын җәеп, зәһәр ысылдый-ысылдый һөҗүмгә ташланды.

Котым алынды. Әмма ниндидер көч мине әйтерсең кинәт аркамнан этәрде. Бөтен куркуларыма карамастан, көчләп, ихтыярсызлап, шунда ата каз белән көчек арасына барып керергә мәҗбүр итте. Каз, очынып килгән шәпкә, үземә ташланды. Күтәртмәләрем шома бозда таеп, нәкъ күлдәвек эченә егылдым.

Тәрәзәдән күреп, ак оекбаштан килеш, әни атылып чыкты, култыгымнан күтәреп торгызды.

— Менә әкәмәт, кара син явызны. Чукымадымы? Берәр җирең авыртмадымы? Әйдә, керик инде.

Полканымны алыйм дип иелгән идем, тагын мәтәлеп киттем.

— Һай, Алла, бер күтәртмәң сынып төшкән бит,— диде әни.

Моңа кадәр еларга онытып торам икән, башта әкрен генә мышкылдап, аннары сөрән салып еларга керештем.

— Йә, бетте-бетте, елама,— дип юатты әни.— Әтиең бүген үк яңаны ясап тагар.

Бу хәлне ишеткәч, әти, мактап, башымнан сыйпады:

— Шулай кирәк, улым, шулай кирәк. Дустыңа куркыныч килгәндә, куркыныч килгәндә, күлдәвеккә түгел, утка керергә дә ярый, — диде.

Габделхәй Сабитов.

1. Хикәя Габделхәйнең яз матурлыгын күреп соклануы һәм этен яратуы турында. «Кечкенә Габделхәйнең үзе өчен ачыш ясавы турында» диярга була. Малай нинди ачыш ясый?

2. Малай этен ятратканга, курыкмыйча, казга ташлана. Үзе өчен тагын ачыш ясый. Нинди ачыш ясый?

КАРАЧКЫ.

— Айдар бакчасында көнбагыш үстерә икән. Каргалар куркытыр өчен, карачкы ясап куйган. Күрдеңме?

— Юк. Нинди соң?

— Шундый куркыныч итеп ясаган, каргалар хәтта былтыр урлаган көнбагышны да кире кайтарганнар.

Каргаларны шул дәрәҗәдә куркыткан карачкы рәсемен ясагыз. Карачкы янына очып килүче карганы, мәзәк сөйләүче малайны да ясарга онытмагыз.

ТӘРБИЯ.

Бер кеше улын кыйный икән.

— Нигә кыйныйсың? — дип сорыйлар.

— Базарга чүлмәк сатарга җибәрәм, шуңа кыйныйм, — дигән хуҗа.

— Шуның өчен бала кыйныйлармыни? — дип гаҗәпләнгәннәр күршеләре.

— Мин аны базарга барасы булганга кыйнамыйм,

чүлмәкне ватма, дип кыйныйм,— дип җавап биргән чүлмәкче.

— Ватмаган чүлмәк өчен дә кеше кыйнамыйлар, — дигәннәр күршеләре...

— Чүлмәк ватылгач кыйнауның ни файдасы бар? — дип, сорауга сорау белән җавап биргән малайның әтисе.

?! Хуҗа хаклы да, хаксыз да. Ни өчен хаклы? Ни өчен хаксыз? Исбат итегез.

КИҢӘШ.

Льюис Кэрролл исемле инглиз язучысының бөтен дөнья балалары яратып укый торган ике китабы бар. Берсе — «Алиса могҗизалар илендә», икенчесе «Алиса көзге артындагы илдә» дип атала.

Могҗизалар илендә король Куянга шигырь укырга куша.

— Кай җиреннән башлыйм? — дип сорый Куян.

— Башыннан башла. Ахырына җиткәнче дәвам ит. Ахырына җиткәч тукта,— ди король.

?! Корольнең ялгышын әйтегез.

ИҢ ЯХШЫСЫ.

— Машина алдыгызмы әле, Сания?

— Юк, бар акчаны санап-санап карадык та иң яхшысы кинога барып кайту булыр дигән уйга килдек.

?! Мәзәктә ике теләк бар. Араларында — каршылык бәйләнеше. Шул бәйләнешне табыгыз.

Каршылык бәйләнеше.

Озын белән кыска, матур белән ямьсез, юан белән нечкә, биек белән түбән, баш белән аяк, килү белән китү, эшчән белән ялкау арасында каршылык посып утыра.

Сәбәп белән нәтиҗә бәйләнеше кебек, каршылык бәйләнеше дә әсәрне ике өлешкә бүлә.

?! Түбәндәге мәкаль һәм табышмакларның кайсысында каршылык, кайсысында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше бар?

* Башың эшләмәсә, аягыңа авырлык килер.
* Өч тиенлек куян, биш тиенлек зыян.
* Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел.
* Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.
* Юктан бар була, бардан юк була. *(Җил.)*
* Тышта туңмый, өйдә туңа. *(Тәрәзә бозы.)*
* Никадәр озын булса да, чирәмгә утырса күренми. *(Яңгыр.)*

КОМСЫЗЛАНСАҢ.

Бер байның акчасы югалган. Ул кеше:

— Янчыгы белән ике йөз алтыным югалды. Тапкан кешегә яртысын бирер идем! — дип, бөтен базар халкына игълан иткән.

Күп тә үтмәгән бер кеше моның алтыннарын табып китергән. Бай саран кеше икән. Әйткән нәзерен[1] бозган. Табучыга акча бирмәс өчен, аны караклыкта гаепләмәкче булган.

---

[1] Нәзер — вәгъдә. Һичшиксез, әйткән сүземдә торачакмын дип сүз бирү.

— Дөрес, минем янчык бу. Ләкин андагы алтыннар арасында бер кыйммәтле асылташ та бар иде. Ул кая? — дигән.

Теге кеше дә төшеп калганнардан түгел икән:

— Алайса, сез үз янчыгыгызны эзләгез. Бусы сезнеке түгел икән. Бу янчыкта асылташ юк иде! — дип китеп барган.

Каршы якларны табар өчен, мәзәкне кыскартып сөйләргә кирәк. Кыскарту — әсәрнең иң кирәкле өлешен генә калдыру ул. Мәсәлән:

1. Бай, алдашып булса да, алтыннарын янда калдырмакчы булган.

2. Бай бар булган алтыннарыннан да коры калган.

БАТЫР КЫЗ.

Әнисе кызын:

— И кызым, нинди зур үстең инде, ә үзең өйалдына да ялгыз чыгарга куркасың! — дип үгетли, ди.

— Юк, әни, мин хәзер курыкмыйм инде. Әйдә, бергә чыгыйк, менә үзең күрерсең! — дигән кызы.

?! Мәзәкне, каршы якларга аерып, кыскартып сөйләгез.

ЭТЛӘРНЕҢ ДУСТ БУЛЫШУЫ.

Ашханә тәрәзәсе төбендә Актырнак илә Сарыбай кояшка каршы җылынып яталар иде.

Шулай ятканда, сүздән сүз чыгып, этләрнең тормышларыннан, көн күрмешләреннән күп сүзләр сөйләнде.

Актырнак әйтә: «И дустым! Бу дөньяда сөешү-дусташудан да татлырак нәрсә бар микән, ике җанның

берләшеп, берсен берсе тәгъзим[1] вә ихтирам итүеннән дә күңелле эш бар микән? Менә безнең арамызда шундый дустлык булса, без гомеремезнең ничек үткәнен дә белмәс идек».

Сарыбай, моны тыңлап торгач: «Мин күптән шуны уйлыйдыр идем. Без икемез дә бер йортның каравылчылары булгач, безгә... ни сәбәпле талашырга? Хуҗаларга рәхмәт: ашарга, эчәргә бар; ач булмыйбыз. Белмим, ни өчендер, безнең ата вә бабаларымыз берберсе илә тату тормаганнар. Менә, Актырнак дуст, бир кулыңны, без икәү Кыяматкә кадәр аерылмаска дуст булып кушылыйк һәм үземездән соңгыларга да күчергеч булыйк»,— дип сүзне бетергәч, Актырнак Сарыбайга кулын бирде, бөтенләй ахирәт дустлары булдылар.

Бу эштән соң яңа дустлар бик куаныштылар. Хәзер генә анадан туган кеби җиңеләйделәр. Шатлыклары

---

[1] Тәгъзим итү — хөрмәтләү.

эчләренә сыймаганлыктан, кая барып бәрелергә дә белмиләр иде.

Шуннан берничә минут үтмәде, бу ике дустлар кочаклашып, берсен берсе куышып, сикерешеп уйный гына башлаганнар иде, гөнаһ шомлыгына каршы, шул арада ашханә тәрәзәсеннән бер сөяк ташладылар.

Менә берзаман дустлар сөяккә йөгерешеп бардылар. Сөякне берсенең дә бирәселәре килми, һәр икесе тешләрен ыржайтып талашырга, чәйнәшергә тотындылар, канга батыштылар.

Бу хәлне хуҗалары күргәч, дустларның өстләренә салкын су сибеп, көчкә-көчкә генә аерып җибәрделәр.

Габдулла Тукай.

?! Мәсәлне ике генә вакыйгага калдырып бүлегез. Алар арасында каршылык ятарга тиеш.

КЕМ?

Өч кыз бәхәсләшкән.

—Укырга кергәч, беренче укучы мин булачакмын. Әни миңа мәктәпкә йөри торган сумка сатып алды,— дигән беренче кыз.

— Син түгел, беренче укучы мин булам,— дип каршы төшкән икенче кыз.— Әнием миңа ак алъяпкыч белән кара күлмәк текте.

— Юк, юк,— дип бүлдергән дустын өченче кыз.— Минем сумка белән пеналым да бар, ак алъяпкыч белән кара күлмәгем дә бар. Өстәвенә миңа, чәчемне үрү һәм күбәләк ясар өчен, ак лента да бүләк иттеләр.

Бәхәсләшкәннәр кызлар, бәхәсләшкәннәр, бәхәсләшә торгач, хәтта тавышлары карлыккан. Аннары Машаларга киткәннәр. Өйләренә керсәләр, Маша әлифба укып утыра.

— Әйт әле, Маша: безнең кайсыбыз иң алдынгы укучы булачак? — дип сораганнар.

— Кайсыгыз беренче укучы булуын әйтә алмыйм. Вакытым юк. Минем әле тагын өч хәреф өйрәнәсем бар,— дигән Маша.

— Ә нигә өйрәнәсең ул хәрефләрне?

— Сыйныфта иң артта калучы укучы булмас өчен өйрәнәм,— дип җавап биргән Маша.

Евгений Пермяк.

?! **1.** Хикәяне ике өлешкә бүлегез. Икенче өлеш беренчесенең капма-каршысы булырга тиеш.

2. Бәхәсләшүче кызлар өчесе дә ялгышалар. Ничек ялгышалар?

3. Бәхәсләшүче кызлар ялкаулармы, әллә мактанчыклармы?

ФИЗЗАРЯДКА ЯСЫЙ КУЯН.

Кызыл күзен ачуы —
Төпкә менеп басуы!

Бер, ике, өч — утыра,
Бер, ике, өч — ул тора.
Йә ботакка тотынып,
Ала даган атынып.

Алан тулы төп тә төп,
Сикергәли дөп тә дөп...
Кинәт читкә тартыла —
Куян уктай атыла.

Ә-ә, бар икән юлаучы.
Юлаучымы? Юк, аучы!
Аучы куа куянны,
Куян тоя куганны.

Шундый кызу элдерә —
Ничек кенә өлгерә?
Чыныккан шул, ул чыдам.
Котылды бит аучыдан!

...Иртәгесен аучы да
Ишегалдына чыга.
Бер, ике, өч — утыра,
Бер, ике, өч — ул тора.
Йә турникка тотынып,
Ала тиз-тиз атынып...

Куян куып туйганмы,
Аучылыкны куйганмы?
Ю-ук.
Физзарядка ясамасаң,
Тотып булмый куянны!

Шәукәт Галиев.

?! Шигырь тәмамланды. Алай да дәвам итегез әле. Аучы да физзарядка ясагач, нәрсә була?

ЯЛ ИТМИ КАЛАМ.

Төшке ашны ашагач,
Ял итәргә ятабыз.
Тәннәрегез, күзләрегез
Ял итсен, ди апабыз.

Ял итәргә дип ятам да
Мин ялгыш йоклап алам.
Шулай итеп, әз генә дә
Ял итә алмый калам.

Мәрзия Фәйзуллина.

?! **1.** Шигырьдәге кыз ялкаумы, наданмы, шаянмы, беркатлымы? Аңлатыгыз.

2. Каршылык тапсагыз, шигырь ике өлешкә бүленә. Бүлегез.



ТАБЫН ЯНЫНДА.

Иртә белән табында
Әткәй әйтте тагын да:
— Юньләп ашарсың микән,
Икмәк валчыгын, иркәм,
Коймый башларсың микән?
Ахры, синең күкләргә
Тавык кирәк чүпләргә!

Ә инде төшке ашта
Сыйпады әткәй баштан:
— Өстәл яның чиста, ди,
Ашарга син оста, — ди.

Чак кына көлми калдым:
Хәйләмне белми калды,
Тавыкны күрми калды.

Шәүкәт Галиев.

71 Үзегез сорау бирегез һәм соравыгызга җавап табыгыз.

ТЕЛ.

Сәгыйтьнең дә теле бар,
Сәгатьнең дә теле бар.

Гармунның да теле бар,
Янгынның да теле бар.

Телнең төрле теле бар,
Тагын кемнең теле бар?

Роберт Миңнуллин.

«Тел» сүзенең эче тулы каршылык, ди Роберт Миңнуллин. Тел озын да, кыска да булмый. Ләкин күп сөйләүчегә «озын телле» диләр. Нур Гайсин, шул каршылыктан файдаланып, мондый шигырь язган:

ОЗЫН ТЕЛ.

Мине әби озын телле
Дип әйтәдер, белмим нигә?
Телең озын дип битәрли
Кайчагында әнием дә.
Көзгедән дә карап алам
Көненә мин әллә ничә,

Алар уйнап әйтәләрдер,
Телем һаман элеккечә.
Телем озын түгеллеген
Белмәскә мин баламыни,
Озын телле булган кеше
Сүзен әйтә аламыни?
Әгәр дә тел озын булса,
Авызыма сыймас иде,
Әнием дә докторларга
Күрсәтмичә калмас иде.

Нур Гайсин.

Искә төшерик: әсәр эчендәге каршылык — авторның иҗаты, уе, табышы ул. Каршылык һәм охшашлык кебек бәйләнешләре булмаса, әдәби әсәр күргән-белгәнне кемгәдер сөйләү генә булып калыр иде.

Мәсәлән, «Озын тел» шигырендә бер әби онығына күп сөйлисең ди. Шигырь авторы, шул хәбәрне шигырь итү өчен, аның эчендә каршылык тудырырга кирәклеген яхшы белгән. Ләкин ул каршылыкны ничек тудырырга? Уйлаган, уйлаган да эзләп тапкан. Халыкның күп сөйләгән балага «озын телле» дип бәя бирүен искә төшергән.

?! 1. Шигырьдәге каршылыкны табыгыз.

2. «Озын телле» дип урынлы-урынсыз, кирәкмәгәнне сөйләп йөрүче кешеләргә әйтәләр. Шигырьдәге баланы ни өчен «озын телле» диләр? Аңлатыгыз.

МИҢА ОХШАГАН МАЛАЙ.

Әтием мине сөя дә:
— Үзем төсле улым, ди.
Нәкъ минем шикелле селти
Йөргән чакта кулын, — ди.
Әнием дә гел охшата
Мине үзенә генә:
— Карагыз әле улымның
Ике күзенә генә.
Нәкъ минеке — зәңгәр төймә,
Шулай куе керфеге.
Гел минеке төсле аның
Чәченең һәр бөртеге.—
Әбием сүзгә кушыла:
— Минем төсле оныгым.
Чагыштырып карагыз бер
Әнә почык борынын.—
Бабай, тамак кыра-кыра:
— И Алланың рәхмәте,
Сөйләмәгез, — нәкъ үзем, ди,
Бөтен килеш-килбәте. —
Бәхәсләшә әти, әни,
Әбием белән бабай,
Ә көзгедән карап тора
Миңа охшаган малай.

Вәсимә Хәйруллина.

?! Шигырьне ике өлешкә бүлү өчен, охшаш урыннарны кушып, барысына да уртак исем бирергә кирәк. Шулай итегез. Ике өлеш каршылыгын аңлатыгыз.

ХӘСӘН БЕЛӘН ХӨСӘН.

Хәсән белән Хөсән — игезәкләр. Кайсы кем булуын белеп кара! Бер-берсенә шулхәтле охшаганнар.

«Әй Хөсән!» — дип эндәшә оныкларының берсенә бабалары. Һәм ялгыша. «Әй Хәсән!» — дип эндәшә, тагы ялгыша.

Хәер, бер дә гаҗәп түгел. Өстәвенә бабалары авылда яши һәм оныкларын сирәк күрә.

Менә ул шәһәргә килеп чыкты. Ике тамчы су кебек бер-берсенә охшаган оныкларын тезенә утыртты да кызыклы әкият сөйләде. Ә икенче көнне авылларына алып китәргә җыена башлады.

— Хәзер оныкларыңны таный аласыңмы инде? — дип сорады кызы.

— Авылга кайткач, һичшиксез, беләчәкмен, — диде бабалары һәм елмайды.

Авылда аларны әбиләре каршы алды.

— Монысы Хәсән, ә монысы Хөсән, — дип таныштырды оныкларын бабалары һәм бу юлы да буталды.

— Барыбер түгелмени! Икесе дә үзебезнекеләр бит, — диде әбиләре һәм оныкларын төрле җимешләр белән сыйлады.

Кич җиткәч, бабалары элеккесеннән дә кызыграк әкият сөйләде. Иртән йоклап яткан оныкларына карап:

— Берсе икенчесенә шулхәтле охшаган малайларны гомеремдә дә күргәнем булмады, — дип гаҗәпләнде.

Алай да алар арасында кечкенә генә булса да аерма бар иде. Берсе сикереп торды да юынырга чапты, икенчесе урын өстендә шактый озак аунады.

Ә торгач, мич янында ни турындадыр уйланып утырды да утырды.

— Бар, син дә юын, — диде бабасы.

— Э-э... — дип, нидер әйтмәкче булды малай.

— Аны әни юындыра, ул үзе еш елый, — диде икенче туганы.

— Кара син аны! — дип гаҗәпләнде бабалары һәм юынган малайдан: — Син кем: Хәсәнме, Хөсәнме? — дип сорады.

— Мин Хәсән, ул Хөсән, — диде агасы.

Тамакларын туйдыргач, бабалары халат киде дә:

— Йә, оныкларым, хәзер басуга барыйк. Мамык сабаклары җыеп кайтыйк, — диде.

— Мин бармам, ахрысы, — диде малайларның берсе. Ә икенчесе, киресенчә, шатланды.

Бабалары шатланган малайдан:

— Син Хәсәнме, Хөсәнме? — дип сорады.

— Хәсән, — дип җавап бирде малай.

— Шулай, шулай. Син Хәсән. Ярый алайса, икәү китик. Ә Хөсән өйдә калсын, — диде бабай.

Ләкин Хөсән өйдә утырырга да иренде. Кырга баручылар артыннан ул да иярде.

Кышкы юлдан өчәү киттеләр. Ә көн шактый салкын иде. Ләкин бабалары тагын бер әкият сөйләде. Монысы алдан сөйләгән икесеннән дә кызыграк иде.

Юлда яткан зур таш янына килеп җиттеләр. Малайларның берсе аны атлап чыкты. Икенчесе бар көчен җыйды да ташны читкә тәгәрәтте. Бездән соң килүчеләр абынмасыннар, диде.

— Син кем: Хәсәнме, Хөсәнме? — дип сорады бабалары.

— Мин Хәсән, — дип җавап бирде малай.

Мамык басуына килеп җиттеләр.

— Йә, батыр егетләр, сабакларны җыя торыгыз, ә мин, танышыма барып, ат алып килим, — диде бабалары.

— Э-э, — диде Хөсән. Ә Хәсән эшкә кереште.

Күпмедер вакыт үткәч, игезәкләр бер-берсенә элеккечә охшамаганнар иде инде. Берсе, салкыннан зәңгәр төскә кереп, башын якасы эченә яшергән, ә икенчесенең, эшли-эшли, йөзләре кызарган. Хәтта пальтосын да салган.

— Пальтоңны өстемә яп әле. Нигәдер өшим. Ичмасам, бабай да юк. Тизрәк өйгә кайтып китәсе иде, — диде, еларга җитешеп, Хөсән.

— Эшләп ал, җылынырсың, — дип киңәш бирде Хәсән. Алай да пальтосын бирде.

— Э-э... — дип җавап бирде Хөсән.

Бабалары әйләнеп кайтты. Оныкларының берсен пальтосыз, икенчесен ике пальто кигән килеш күргәч:

— Син Хәсәнме, Хөсәнме? — дип сорады.

— Мин Хәсән, — дип җавап бирде Хәсән.

— Әйе, әйе, син Хәсән, — диде бабалары. — Моннан соң онытмам инде.

Аннан соң мамык сабакларын арбага төяделәр, сабаклар өстенә Хөсәнне утырттылар. Бабасы белән Хәсән җәяү атладылар.

«Шулай. Бер малайның икенчесенә шулкадәр охшамавын моңа кадәр бер дә күргәнем юк иде», — дип уйлады бабалары, кайта-кайта.

Ш. Мирмухсин.

?! **1.** Хикәяне каршы якларга бүлегез. Икесенә дә исем бирегез.

2. Игезәкләр бер-берсенә охшаганнар да, охшамаганнар да. Шул каршылыкны аңлатыгыз.

УМАРТА КОРТЫ ВӘ ЧЕБЕННӘР.

Ике чебен, чит мәмләкәтләргә китәргә әзерләнеп, үзләре илә бергә китәргә Умарта кортын да чакыра башладылар.

Бу чебеннәр чит җирләрнең бик яхшы икәнлеген байгышлардан[1] ишеткәннәр иде.

Чебеннәр ник китмәсеннәр? Туган җирләрендә боларны рәнҗетәләр һәм, чакырылмаган кунак шикелле, бичараларны ашъяулык тирәсеннән куалар, татлы ашларны да ашатмыйлар.

Һәммә ашамлык нәрсәләр өстенә пыяла калфаклар каплап, мыскыл иткән шикелле, тик чебеннәрнең күзләрен генә кызыктыралар.

Почмак тарафларына бөтенләй барыр хәл дә юк: анда усал үрмәкүчләр ау корганнар.

Онытылмасын әле: Умарта корты боларга ни дип җавап бирде? Ул: «Миңа туган-үскән җирем кадерле. Мин үземнең кәрәзле балым илә алпавытларны, байларны, хәтта авыл кешеләрен үземә гашыйк иттем. Мин монда да сөекле. Әмма сезгә сүзем юк; сез теләсәгез кая барыгыз. Ләкин белегез ки...»

Габдулла Тукай.

?! **1.** Ике өлеш арасында каршылык бәйләнеше булуын исбат итегез.

2. Умарта корты чебеннәргә китмәгез дими. Ихтыярыгыз, китсәгез китегез, ди. Ни өчен калыгыз дими?

3. Чебеннәрнең һәм умарта кортларының әсәрдә күрсәтелгән икешәр сыйфатын әйтегез.

4. Әсәрне дәвам итегез. Умарта корты чебеннәргә тагын нәрсәләр әйткән?

---

[1] Байгыш — күп хәсрәт кичергән мескен кеше.

СӘЕР УКЫТУЧЫ.

Безнең укытучы — бик сәер кеше. Кичә үзе, 5+5 ун була, диде. Бүген, 3+7 ун була дип, миңа «2»ле куйды.

?! Мәзәктә каршылык юк. Ләкин аны, автор ярдәме белән, начар укучы бала тудырган. Ничек тудырган? Шуны аңлатыгыз.

КЫҢГЫРАУЛЫ ТЫЧКАН БАЛАСЫ.

Борын-борын заманда Чичи исемле бер тычкан баласы яшәгән. Ул, муенына асып, кечкенә генә кыңгырау йөртә икән. Йөгергәндә, кыңгырау чың-чың-чың чыңлый торган булган.

Бермәлне Чичи, бодай ашарга дип, салам чүмәләсе астына кергән. Тамагын туйдыруын туйдырган, ләкин кыңгыравын югалткан. Бик борчылган тычкан баласы. Кыңгыравымны ничек табыйм дип, озак баш ваткан. Табарсың, тапмый ни, кыңгырау менә моның кадәр генә, ә чүмәлә әнә никадәр бит! Шулай дип уфтанган да учак янына киткән.

— Учак, Учак, күмереңне биреп тор әле?

— Нишлисең ул күмер белән?

— Салам чүмәләсе астында кыңгыравымны югалттым. Чүмәләне яндырам.

Учак Чичигә кул гына болгаган.

— Синдәй бала-чага кулына утлы күмер тоттырырга ярыймы соң? — дигән.

Чичи Елга янына килгән.

— Елга, Елга, бер генә уч су бир әле?

— Нишләмәк буласың бер уч су белән?

— Учак күмер бирмәде, утын сүндермәкче булам.

— Юк-юк, синең ише бала-чагага су бирмим мин.

Шуннан соң Чичи далада утлап йөрүче ишәкләрне эзләп тапкан.

— Ишәкләр, ишәкләр, Елга суын болганчык итегез әле?

Аптыраганнар ишәкләр:

— Нигә дип болгатыйк чиста Елганы? — дип сораганнар.

— Елгадан бер уч су сораган идем, бирмәде.

— Үзебез суын эчә торган Елганы болгатып пычратырга тилеме әллә без!

Тәмам хәлдән тайган тычкан баласы. Балалардан ярдәм сораган.

— Малайлар, малайлар, таякларыгыз белән шул ишәкләрне тәпәләгез әле. Елга суын болганчык итегез әле, дип үтенгән идем, баш тарттылар...

?! **1.** Тычкан баласы тагын кемнәр янына барып ярдәм сорарга мөмкин? Әкиятне дәвам итегез.

2. Әкият авторы тычкан баласы аша нинди кешеләрдән көлә?

КОЯШТАГЫ ТАП.

Еракта, бик еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер урган, нидер төзәткән, нидер яңарткан...

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе, авырып, түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын өенә чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара кӧеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам?

Малай, үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит, кичләрен уеннан арып кайткач, салкын су эчәргә яратасың,— дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым,— дигән әнисе аңарга,— суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай, чиләген күтәреп, урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда, шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле»,— дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе, аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт»,— дигән. Һәм, йотлыгып-йотлыгып, суны эчә башлаган. Эчкән саен, күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай, сөенә-сөенә, урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде»,— дип уйлаган ул. Шулай дип уйлавы булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кошкортлар, куркышып, ояларына качканнар. Шомлы итеп, елап-елап, этләр өрергә тотынган. Малай, ни уйларга да белмичә, курка-курка, өенә чапкан.

— Әни,— дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып,— нишләптер, кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни,— дигән малай, башын түбән иеп,— мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар, кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаганнар. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы кара тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

Фәнис Яруллин.

?! **1.** Легенданың бер өлеше сәбәп, бер өлеше нәтиҗә булуын исбат итегез.

2. Ана шифалы су эчмәсә дә тиз терелде. Ни өчен шулай тиз терелде?

3. Кояштагы тапның мәгънәсен әйтегез.

Күренеп торган бәйләнешләр.

Беренче рәсемгә карагыз. Алма ботакта эленеп тора.

Икенче рәсемдә алма җиргә төшкән. Хәзер аны җир күтәргән.

Өченче рәсемдә алма кыз кулында ята.

Уйларга уңайлы булсын өчен, алманың асылынып торуы да, җиргә төшүе дә, кулда ятуы да **бәйләнеш** дип бер генә сүз белән әйтелә.

БЕРЕНЧЕ КАР.

Төн буена туктамастан тышта ап-ак кар ява,
Капланып кырлар, болыннар, Җир йөзе ап-аклана.
Ниндәен тиз үзгәреш бу, ниндәен тиз алмашу!
Арба урнында бу көн, кошлар кебек, чана чаба.
Күрмәссең тышта яланбаш һәм яланөс бер кеше,
Чөнки тыш салкын-суык, — аннан адәмнәр саклана.

Нәҗип Думави.

7! Шигырьдәге күренеп торган бәйләнешне табыгыз.

МӘКТӘПКӘ БАРМАДЫМ.

Без мәктәпкә һәр көн саен
Урман аша йөрибез.
Укытучы бик борчыла,
Килми калса беребез.

Бүген бармадым, урманнан
Әйләнеп кайттым кире.
Яшереп тормыйм... Куркытты
Урманның хәтәр җире!

Куркыткандыр, дисез?
Аю чыккандыр, дисез?
Шүрәле очрагандыр йә
Елан чаккандыр, дисез?..

Юк, мине куркытмадылар,
Аю-бүре кумады.
Мине өркетер шүрәле
Урманында юк әле...

Икенче бер сәбәп белән,
Урманнан кайттым кире.
Өркетте мине, куркытты
Аның кәккүкле җире!

Әнә шул язмыш юраучы
Юлымнан ялгыштырды...
«Нинди билге алам?» — дигәч,
Ике тапкыр кычкырды...

Галимҗан Гыйльманов.

?! **1.** Укучы малай шигырьдәге бәйләнешне үзе әйтеп бирә. Нинди бәйләнеш ул: сәбәп-нәтиҗәме, каршылыкмы, охшашлыкмы, чагыштырумы?

2. Шигырьнең беренче өлешендә героебыз «мин куркак түгел» дип мактана. Икенче өлешен табыгыз.

3. Шигырьне дәвам итегез.

Күзгә күренми торган бәйләнешләр.

Күренеп торган бәйләнешне күрә белергә генә кирәк иде. Күренми торган бәйләнешне уй белән табып була.

Мәсәлән: сезнең берәүгә ачуыгыз килде, ди. Кем хаклы булуын ачыкламый торып, сез аны башкалар алдында хур итеп ачулана башладыгыз, ди.

Ә иптәшегез сезгә берни әйтми елмаеп карап тора. Ул елмайган саен, сезнең ачуыгыз килә, ә ул һаман дәшми. Елмая да елмая.

Сезнең иптәшегезгә мөнәсәбәтегезне башкалар бик тиз сизәләр. Ләкин алар дәшмәүче иптәшегез елмаюында «Шушындый усал, тәрбиясез баламыни әле син, ә мин сине юньле иптәш дип йөрим тагын» җавабын абайлап алалар. Иптәшегезне хур итәсе урында, үзегез хур буласыз. Хәзер сез иптәшсез калдыгыз.

Әнә нинди көчкә ия ул — күренми торган бәйләнеш.

Ялкаулык белән минем арада да күренми торган бәйләнеш бар. Аны башкалар әллә каян күреп торалар. Ә мин күрмим.

> Күзгә күренми торган бәйләнеш әсәрләрдә бик күп була, чөнки ул — авторның укучысы белән сөйләшү алымы.

ТАПКЫР КӨТҮЧЕ.

Элек көтүчеләрне бер көнне бер гаилә, икенче көнне икенче гаилә ашата торган булган. Чират авыл бае гаиләсенә җиткән. Ә аның хатыны саранның да

сараны икән. Чәй эчкәндә, кәтүче борчак кадәр генә шикәрен, җеп белән бәйләп, самовар борынына асып куйган.

— Нишләп алай итәсең аны? — дип сораган бай хатыны.

— Чебен күтәреп китмәгәе дип курыктым, — дип җавап биргән көтүче.

?! Мәзәктәге күренми торган бәйләнешне табыгыз.

ЯРЫШ.

Хәлим белән ярышабыз,
әйберләрне алышабыз:
имеш, бездә әйбер күпме,
алышырга җитәрлекме?

Хәлим миңа каләм бирде,
мин автомат бирдем аңа.
Хәлим миңа пәке бирде,
мин өч солдат бирдем аңа.
Хәлим дәфтәр бүләк итте,
ә мин аңа — карандашлар.
Хәлим китап бүләк итте,
ә мин аңа — матур ташлар.

Менә шулай вакыт үтте,
алышырга әйбер бетте.
Аптырагач, Хәлим әнә
ак мәчесен тотып килә:
— Мә, качмасын, саклап йөр, ди,
ә син Акбаеңны бир, — ди...

Камил Мостафин.

?! **1.** Шигырь тәмамланмады. Автор аны ничек тәмамларга мөмкин?

2. Ахыры табылгач, шигырьне ике өлешкә бүлегез.

3. Ике өлеш арасындагы бәйләнеш күренми, ләкин ныклабрак уйласаң табып була. Табыгыз.

ДУС.

I

Алты яшь тулгач уйга калдым. Миңа бу дөньяда яшәүче кешеләр бар да ошыйлар. Аларның эшләре дә ошый. Ә миңа кем булырга? Әле күктәге йолдызларны өйрәнүче буласым килә, әле диңгезләр гизүче капитан. Ә иртән йокыдан торгач, боксёр булырга ниятләдем.

— Әти, миңа боксёрлар капчыгы алып кайт әле. Авыр булсын, күннән булсын, — дидем.

— Акылдан шаштыңмы әллә, дускай? Моңа кадәр күн капчыксыз да бик матур яшәдек әле, моннан соң да яшәрсең, — диде әти һәм, киенеп, эшенә китте.

Әтигә үпкәләвемне әни шунда ук сизеп алды.

— Тукта әле, улым. Башка бик матур фикер килде,— диде әни. Тиз генә бөгелде дә диван астыннан иске кәрзин тартып чыгарды. Ватык-җимерек уенчыкларымны актара торгач, эт зурлыгындагы аю сөйрәп чыгарды.

— Ике яшең тулгач, Наилә апаң бүләк иткән иде. Менә дигән аю. Әнә нинди зур. Ә корсагы син сораган күн капчыктан да катырак.

II

Үпкәм күккә очты. Шатлыгым эчемә сыймады. Аюымны җайлап утырттым. Бәргәләп кул көчен арттыру өчен, бик уңайлы булды.

Менә ул минем иске уенчыгым. Шоколад төсендәге аюым. Ул шактый тузган. Күзләре дә ике төрле. Берсе үзенеке, икенчесе — мендәр төймәсе. Менә ул минем каршымда аякларын як-якка җәеп утыра. Корсагын миңа таба сузган.

Карап-карап тордым да үзенә, кинәт аның белән уйнаган вакытлар искә төште. Мин бит аны кайчандыр кулымнан төшерми идем. Хәтта ашаганда да үз янымда утырта торган идем. Мин аңа манный боткасы ашата идем. Ботка яисә варенье буялган битенә карап, рәхәтләнеп көлә идем. Мин бит ансыз йокларга да ятмый идем. Энем итеп тирбәтә, колагына әкиятләр сөйли торган идем. Мин аны шундый, шундый ярата идем. Кирәк булса, аның өчен җанымны да бирергә риза идем. Менә хәзер кайчандыр иң якын дустым булган аю диванда ике төрле күзләре белән миңа карап көлә. Ә мин, аны кыйнап, күнегүләр ясарга тиеш...

— Ни булды? Кай җире ошамый? — дип сорады әни.

Ә мин ни булганын үзем дә белмим. Бик озак дәшми тордым. Яшь тамчылары җиргә тәгәрәп төшмәсен дип, күзләремне түшәмгә текәдем... Аннары, тынычлана төшкәч:

— Берни булмады, әни. Боксёр булу уеннан баш тарттым. Мин бервакытта да боксёр була алмыйм икән, — дидем.

Виктор Драгунский.

?! 1. «Әсәр нәрсә турында?» соравына «Малайның күн капчык соравы турында» дип җавап бирер идегез. Тагынниләр турында дип җавап бирергә мөмкин?

2. Малайның боксёр булу уеннан ни өчен баш тартуын белсәгез, күренми торган бәйләнешне табасыз. Табыгыз.

ҖИЛ КУМАДЫК.

Уены белән мавыгып,
Равил кайтты кич кенә.
Андый чакта әниләре
Әйтми калмый һич кенә:

— Тугыз яшьлек зур малайсың,
Үзең һаман белмисең.
Ашарыңа да онытып,
Ник җил куып йөрисең?

Равил әйтә:
— Юк, әнием,
Белмисең, җил кумадык.
Су буенда болай гына
Йөгерешеп уйнадык.

Нур Әхмәдиев.

?! **1.** Шигырьне аңларга тырышып укыгыз. Ике өлешкә бүлегез.

2. Өлешләр арасындагы бәйләнешләрне табыгыз.

3. Күзгә күренми торган бәйләнешне табарга тырышыгыз.

Әйтми калдыру.

Әдәби әсәрләрдә автор белән укучы сөйләшә, дип өйрәндек. Алар ничек сөйләшә?

Автор әсәрендә нәрсәнедер әйтми калдыра. Укучысына ягымлы гына итеп: «Мин әйтеп бетермәгәнне тапсаңчы, хөрмәтле укучым», — ди. Автор хәтле автор безне шулай зурлагач, ничек каршы киләсең: әсәрдән ул юри әйтми калдырган бәйләнешләрне табарга тырышабыз. Автор белән без шулай сөйләшәбез. Мәкальләргә күз салыйк.

Күрше тавыгы каз хәтле,
Йомыркасы баш хәтле,—

диелә мәкальдә. Мәкаль әйтүче безгә карап елмая. «Йә, нәрсә аңладың?» — дип сорау бирә.

Эзлибез: мәкаль, әлбәттә, тавык турында түгел. Чөнки, күрше тавыгы бик тырышса да, баш хәтле йомырка сала алмый. Бераз уйласак табабыз. Көнләшү хисе — бик матур хис ул. Мәсәлән, мин үземнән яхшырак укучыдан көнләшәм һәм аңардан да әйбәтрәк укырга тырышам. Бу мәкальдә автор безгә башкаларның уңышыннан көнләшмәскә куша икән бит!

?! «Елыйсы килгән бала атасының сакалы белән уйнар» мәкален һәм «Энә белән кое казый» әйтемен аңлатыгыз.

ЯЛГАНЧЫ.

— Син ялганчы икәнсең!

— Нигә алай дисең?

— Ир туганым берәү генә дигән идең бит!

— Дөресе дә шулай.

— Ә сеңлең әйтте: «Минем ике абыем бар», — диде.

ТӘРБИЯЛЕ БАЛА.

Сәлим исемле малай урамда елап тора.

— Нигә елыйсың, акыллым? — дип сорый берәү.

— Машина үтеп китмичә, урам аша чыга күрмә, дигән иде әнием. Бер машина да үтми, — дигән тәрбияле малай.

?! Мәзәкләрдәге әйтелми калган бәйләнешләрне әйтегез.

ҖӘЛ.

Бер малай, бер дуамал,
Шундый уен уйлаган:
Урамда яшь юкәгә
Ике куллап тотынган,
Төрле якка талпынган —
Имеш, таган атынган!
Шарт итеп юкә сынган,
Малай җиргә атылган,
Кулларын авырттырган,

Ыңгырашкан, сызланган,
Шактый үксеп утырган.
Кешеләр бик кызганган:
— Җәл, — дигәннәр, — җәл бик тә,
Харап булган бит юкә!..

Шәүкәт Галиев.

?! Автор, кешеләр белән бергә, юкәне кызганган һәм нәрсәнедер әйтеп бетермәгән. Мин әйтергә теләгәнне үзегез әйтегез дигән. Автор нәрсәне әйтми калдырган?

АТ БЕЛӘН ТӨЛКЕ.

Урман эченнән карт Ат бара. Үзе бара, үзе, тар сукмактан атлый-атлый, күңелсез уйлар уйлый икән.

— Гомерем буена бер генә көн дә ял итмәдем. Эшләдем дә эшләдем. Картайгач, хуҗам ашатмый башлады. Абзарымнан куып чыгарды. Кая барыйм? Картайган көчсез атның кемгә кирәге бар?

Төлке дә шул ук сукмактан килә икән. Очрашканнар.

— Кая китеп баруың, Ат дус? — дип сораган Төлке.

— Кая баруымны үзем дә белмим. Эшләр хәлем калмагач, хуҗам куып чыгарды. Үзең беләсең, мин бит аңа гомерем буе эшләдем. Җитмәсә, мыскыл итте. Минем янда бераз торасың килсә, Арыслан алып кайт, диде. Нишләргә дә белмим инде, Төлке дус. Карт атка Арыслан хәтле Арысланны җиңәрлек көч каян килсен, ди! Ярдәм итә күр, кая барыйм, ни эшлим?

— Ярый, — дигән Төлке. — Син хәзер үлгән булып ят. Арысланны хәйлә белән китерермен дә койрыгы-

ңа бәйләрмен. Сөйрәп, өеңә алып кайтырсың. Хуҗаңа менә дигән бүләк булыр, — дигән Төлке.

Ат сузылып яткан. Күзләрен йомган. Ул арада Төлке Арыслан каршына килеп баскан да:

— Исән-саумы, данлыклы Арыслан? — дигән.

— Сәлам, Төлке! Ни йомыш белән килдең?

— Үлгән ат таптым. Туйганчы кунак булырсың. Моннан ерак та түгел. Әйдә, күрсәтәм, барасыңмы?

— Һай, рәхмәт сиңа, Төлке. Бик тә вакытында килдең. Дүрт көн буена ач йөрим, — дигән урман патшасы.

Ат янына җитәрәк, Төлке Арысланга:

— Юл уртасында тамак туйдыру әдәпсезлек булыр. Койрыгыңа итне бәйләп куйсам, ояңа тартып кайтыр идең дә шунда ашар идең, — дигән.

— Бәйлә соң алай булгач,— дигән Арыслан.

Төлке яшереп куйган җиреннән бау алып килгән.

— Койрыгыңа авырлык килмәсен өчен, бәлки, итне аякларыңа һәм ялыңа бәйләп тартырсың? — дип сораган Төлке.

— Ничек уңайлы булса, шулай ит. Син бит оста бәйлисең,— дип җавап биргән Арыслан.

Төлке Арысланның аякларын да, муенын да төйнитөйни бәйләп куйган. Бауның икенче очын ат койрыгына таккан.

— На-а-а, Ат дус! Әйдә, тор. Йөгеңне өеңә алып кайт. Мыскыл иткән өчен, хуҗаңнан үчеңне ал,— дигән Төлке.

Ат, көч-хәл белән булса да, Арысланны өенә тартып кайткан.

— Ай-яй, картлач, мондый эшне ничек булдыра алдың? — дип шаккаткан хуҗа.

— Бер дә аптырама, хуҗам. Бу Арыслан үзенең тугрылыклы хезмәтчеләрен оясыннан куып чыгарган булган. Шуның өчен ялчылары аңа шушылай бәйләп җәза биргәннәр. Мә, чишеп ал. Кунагың булыр. Буш вакытта бергә-бергә сөйләшеп утырырсыз,— дигән.

?! **1.** Әкиятне кыскартып сөйләгез.

2. Ике зур вакыйгага бүлегез.

3. Алар арасындагы бәйләнешне табыгыз.

4. Атның хуҗасына әйткән сүзләрен автор безгә дәвам итәргә куша. Дәвам итегез.

ҮРТӘСЕН ӘЛЕ МИНЕ.

Сөйләп киттеләр бары:
Кошлары, хайваннары...

Мәче әйтә: «Бик күптән,
Никтер, ул миңа дошман.
Гел кычкыра, гел шаулый,
Мине үртәп мыраулый».

«Дөрес, дөрес,— ди Акбай,—
Кәли — бик усал малай.
Рәнҗетә ул мине дә,
Әле беркөн килде дә
Җикте бит, әй, чанага —
Шуннан үзең чамала...»

Инде тыңлыйк Үрдәкне:
«Ул мине дә йөдәтте.
Юкка-барга бәйләнә,
Тилгән булып әйләнә.
Үземә таш ыргыта,
Бәбкәләрем куркыта».
Бик озак сөйләштеләр,
Шактый күп киңәштеләр.
Тик күз кысып бер якта
Тора сыңар аякта —
Ата каз, ул: «Кыйгак, ди,
Торасызмы, елап, ди,
Китерегез Кәлине,
Үртәп карасын мине!..» —
Дип елмая Ата каз,
Ник елмая Ата каз?

Эльмира Шәрифуллина.

?! Автор соравында шигырьнең әйтелмәгән өлеше ята. Сорауга җавап бирегез.

СӘГАТЬ ЯРДӘМ ИТТЕ.

Коля мәктәптән кайтты. Кулына стенадагы көн тәртибе язылган кәгазьне алды. Аңа кызыл карандаш белән тагын бер пункт өстәде. «Кичке сәгать биштән алып алтыга кадәр өйдә әни белән әбигә ярдәм итәм»,— дип язып куйды.

Шул көнне, сәгать биш тапкыр сугу белән, тумбочкадагы фикус гөлен кузгатмакчы булды.

— Нигә кузгатасың аны? — дип сорадылар әнисе белән әбисе.

— Арткы бүлмәдәге сез кер киптерә торган бауны чишәм. Тумбочкага басмыйча, буй җитми,— дип җавап бирде Коля.— Хәзер мин сезгә көн дә ярдәм итәчәкмен,— дип тә өстәде.

Әнисе белән әбисе бер-берсенә карап елмайдылар.

?! 1. Хикәянең укыган өлешенә исем бирегез.

Бер минут үтте микән, юк микән, Коля арткы бүлмәдән:

— Берәрегез тумбочканы тотып торыгыз әле. Монда идән тактасы тигез түгел икән! — дип кычкырды.

Әбисе, тегү эшен ташлап, ярдәм итәргә килде.

Коля, тумбочкага басып, кер бавын чишәргә кереште. Ләкин күп тә үтмәде, әнисен чакырды:

— Әни, кайчы алып кил әле. Төенен чишеп булмый. Ә син, әби, китми тор, бауны җыеп куярсың.

?! 2. Бу өлешкә дә исем уйлап табыгыз.

Бауны кисеп төшергәч, Коля әнисе янына килде. Әнисе үтүк кызганын көтеп тора иде.

— Кызгач, үтүгеңне үзем китерермен. Бар, әни, эшеңне кара. Биштән алтыга кадәр мин сезгә ярдәм итәм бит.

Коля, кызды микән дип, бармагын үтүккә тигергән генә иде:

— Әллә-лләм, әллә-лләм, — дип кычкырып җибәрде. Бармагын сабынга уа-уа:

— Тизрәк марганцовка белән марля китерегез. Бармакны бик нык пешердем, — дип кычкырды.

— Берни булмаган, хәтта кызармаган да, — диде әбисе.

— Ә син күзлегеңне киеп кара. Журналлар укыганда, күзлексез карамыйсың бит!

Коля әбисе ярдәме белән бармагын бәйләде һәм әнисе янына килде.

3. Өзекне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Исем уйлап табыгыз.

4. Бу өзек алдагы ике өзекнең кайсына охшаган? Охшаган өзекләрне без нишләтә идек?

— Син үтүклә, мин су сиптереп торырмын, — диде әнисенә һәм, авызын тутырып, су алды. Аннан соң, иреннәрен кысып, яңакларын кабартты һәм бар көченә өреп җибәрде. Кергә бер генә тамчы су төште. Калган суны ялгыш йотып җибәрде.

— Әбиең янына бар. Энәсенә җеп сапларга ярдәм ит. Монда мин үзем дә үтүкли алам, — диде әнисе.

— Минут эчендә саплыйм мин аны, — дип шатланды Коля.

Ул арада телефонга түләр өчен кәгазь китерделәр.

— Тукта әле, башта кәгазьне тикшерим. Дөрес яздылар микән?

Коля счёт кәгазен алды да диванга ятты.

— Әби, миңа кәгазь белән карандаш китер әле. Исәплим.

— Йа Алла! — диде әбисе һәм, теккән җиреннән торып, кәгазь эзләргә юнәлде.

Күрше бүлмәдә әбинең күзе стенадагы сәгатькә төште. Сәгать янына басып, бераз уйланып торды да сәгатьнең олы телен унбиш минутка алга күчереп куйды. Сәгать алты тапкыр сукты.

Коля шунда ук ян бүлмәдән:

— Кәгазь кирәкми. Уйнарга чыгу вакыты җитте,— дип кычкырды.

Әби сәгатьне туктатты да «уф» дип җиңел сулап куйды.

Юрий Ермолаев.

?! **5.** Соңгы өзекне дә үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аңа да исем уйлап табыгыз.

6. Автор безгә нәрсә турында әйтеп бетермәде?

ПОЧМАКТА ТОРАМ.

Әни почмакка
Бастыра мине.
Нигә икәнен
Беләсез инде.
Чыкмый тыным да.
Еламыйм хәтта.
Елау турында
Уйламыйм хәтта.

Торам төз генә,
Теләшми генә,
Сер бирми генә,
Сөйләшми генә.
Әзер мин монда
Көн дә торырга —
Өйрәнәм бит мин
Солдат булырга!

Өйрәнә торам
Сакта торырга!

Роберт Миңнуллин.

?! Бу шигырьдә дә автор әйтеп бетермәгән каршылык бар. Шуны табыгыз.

УРМАН ЧИТЕНДӘ.

Кыш башлангач та, укытучы балаларга кошлар өчен җимлекләр ясап куярга һәм анда нинди кошлар килеп туенуын күзәтергә кушкан иде.

Укучылар моңа шатланып риза булдылар. Мәктәптән кайткач, җимлекләр ясап, аларны бакчаларга яки өйалларына куя башладылар.

Бу эш Таңсылу белән Вәлигә бигрәк тә ошады. Әтиләре урман караучысы булганга, алар урман читендәге бер өйдә яшиләр иде.

Вәли, тактадан бәләкәй бер өстәл һәм җимлек ясап, урман буендагы карт чыршы төбенә куйды.

Кошлар өчен бик яхшы җимлек булды бу. Салынган азыкны кар басып китмәсен өчен, очыртып бетермәсен дип, Вәли җимлекнең читләренә тар гына такта кадаклап куйды. Җимлек бик әйбәт булып чыкты, ә иң мөһиме: ул Вәлиләрнең тәрәзәләреннән күренеп тора иде.

Балалар җимлеккә ярма, икмәк валчыклары һәм коры миләш салып торалар. Алар үзләре дә миләшне бик яраталар иде. Шуңа күрә дә көз көне, беренче салкыннар төшкәч тә, миләшне бер капчыкка җыеп куйганнар. Ә менә хәзер аның кошларга кирәге булды.

Һәр көн иртән, мәктәпкә китәр алдыннан, Таңсылу белән Вәли җимлеккә яңа җим салалар.

Бервакыт шулай якшәмбе көн балалар кошларга җим салалар да, читтәнрәк күзәтергә дип, тәрәзә янына килеп утыралар.

Тышта бик салкын. Үткән төндә бик күп кар яуган иде. Карт чыршылар өсләренә мамык тун, ә башларына ак бүрек кигән сыман торалар. Алар кояшта үзләренең әнә шул ак кар киемнәре белән җемелдәшеп утыралар.

Кошчык тактага җитез генә очып төште, үзенең нәзек кенә томшыгы белән икмәк кисәген эләктереп алды да очып та китте. Янәшәдәге агачка барып кунды, икмәкне, тәпиләре белән кысып, еш-еш чукырга тотынды.

Шуннан соң бер төркем купшыкайлар килеп җитте. Алар өстәлгә төштеләр дә, ашыга-ашыга, ярма чүпли башладылар.

— Ә болары тагы да сылурак,— диде Вәли. Ул кызыл түшле ике кошка төртеп күрсәтте.

Бу ике кош җимлек янындагы агачка килеп кундылар, уңайлы гына итеп утырдылар. Мамыкларын кабартып кагындылар да купшыкайларның өстәлдә урын бушатканын сабыр гына көтә башладылар. Кызылтүшләр һич тә кузгалмыйча утыра бирәләр: кар каплаган ак ботакта ике кызыл чәчкә утырамыни!

Озакламый купшыкайлар җим чүпләп туйдылар һәм, үзара чыркылдашып, урман эченә очып киттеләр. Шуннан кызылтүшләр, ашыкмый гына җимлеккә төшеп, тамак туйдыра башладылар. Алар миләш бөртекләрен, үзләренең киң томшыклары белән алып, авызларында изәләр, орлыкларын чүплиләр дә, башларын бик кызык итеп селкетә-селкетә, миләшнең йомшак өлешен авызларыннан кире чыгаралар.

Кинәт кенә бер як читтән өстәл өстенә озын томшыклы юантык бер соргылт кошчык килеп кунды. Каядыр ашыккан сыман, ул томшыкларына булдыра алган кадәр орлык тутырды да очып китте.

— Әй, ашыга да инде бу миләш чыпчыгы, ут чыккан диярсең! Үзенә юньләп карап та булмады,— диде аны күзәтеп торган Таңсылу.

Өстәлдә кошлар юк иде инде. Аның каравы җимлек янындагы өске ботакта тиен утыра. Ул җимлектәге сыйдан күзен дә алмый. Ләкин түбән төшәргә, күрәсең, курка иде.

Балалар: «Төшәрме, юкмы?» — дип, тын да алмый күзәтәләр.

Тиен ачыккан булса кирәк. Ул ботак буйлап бер тапкыр үтте, ике тапкыр үтте, яңадан элекке урынына килеп утырды, тирә-ягына каранып алды да, җәһәт кенә сикереп, өстәлгә килеп төште.

Таңсылу белән Вәли, шатланышып, «Килде бит!» дигәндәй, бер-берсенә карашып куйдылар.

Тиен арткы аякларына утырды һәм, алгылары белән кипкән миләш тәлгәшен алып, тиз-тиз генә ашарга тотынды. Бер тәлгәшне ашап бетергәч, ул теше белән икенче тәлгәшне эләктереп алды. Аннары, баягы ботакка сикереп менеп, күздән югалды.

Шуннан бирле тиен көн саен балалар ясаган җимлеккә килеп йөри башлады. Балалар да шундый кадерле кунакның килеп туенып китүеннән бик канәгать булдылар.

Шәриф Биккол.

?! **1.** Хикәянең беренче өлеше кошларны ашатуга әзерләнү турында. Ул өлеш кайсы урында тәмамлана? Аңа исем табыгыз.

2. Икенче өлешне ничек табабыз? Анда вакыйгалар күп бит.

3. Икенче өлешкә дә исем уйлап табыгыз.

4. Автор хикәясендә безгә нәрсә турында әйтергә тели? Шушы сорауга җавап бирсәгез, әйтелми калган урынны тапкан буласыз.

5. Хикәяне сез ничек дәвам итәр идегез?

БҮРЕ.

Бүрегә үз илендә көн беткән. Этләр белән кешеләрдән тәмам гарык булган.

Юлда аңа бер акыл иясе очраган.

— Кайларга юл тотасың? — дип сораган акыл иясе.

— Бәхет эзләп, башка илгә китеп барышым. Мине күрү белән, сунарчылар мылтыкларыннан ата башлыйлар, көтүчеләр этләрен өстерәләр, таяклар ыргыталар,— бар да миннән котылмакчы булалар.

— Чит илгә тешләреңне дә алып китәсеңме? — дип сораган акыл иясе.

— Алып китмичә... Тамакны ничек туйдырыйм, ди, мин тешләремне монда калдырсам,— дигән Бүре...

?! Дәвам итегез. Акыл иясе бүрегә ничек җавап бирергә мөмкин?

КАРА ХУРЛЫК БОЛЫТЫ.

«Ике»ле алмадым!» — диеп
Кайтты да ул мактанды.
Әнкәсе дә бик куанды,
Әткәсе дә шатланды.

Көндәлеген карадылар...

Зәки Нури.

?! Беренче өлеш белән икенче өлеш арасында каршылык бәйләнеше булса, шигырьне автор ничек тәмамлаган?

КАЙСЫ КИРӘГРӘК?

Кызы белән әнисе сүз көрәштерәләр икән. Кызы әйткән:

— Ай бик матур да, кирәгрәк тә, — дигән.

Әнисе әйткән:

— Таптың сүз! Кояш — тереклек чишмәсе, ул бөтен дөньяны яктырта.

— Юк, Ай кирәгрәк. Кояш бит ул көндез генә яктырта, ә көндез болай да якты! Ай дисәң, ул төнлә, караңгы чакта яктырта...

?! Автор бәхәсләшүчеләрнең ялгышын әйтмәгән. Безгә табарга кушкан. Табыгыз.

АҢЛАШЫЛДЫ.

Ничә малай ничә күреп
Әйтте ничә мәртәбә:
— Сыйлангансың икән, диләр,
Тәмле булдымы тәбә?

— Каян белгәннәр? Бергәләп
Хәйлә корганнар мәллә —
Посып кына тәрәзәдән
Карап торганнар мәллә?

Тәрәзәнең капкачларын
Ябып йөрдем шалт та шолт.
Караңгыда катык каптым,
Карангалап ялт та йолт.

Чыккан гына идем өйдән,
Калдым тагы шаккатып —
Ерактан ук кычкыралар:
— Ашагансың бит катык!

Хәзер инде алар мине
Алай үртәп йөрмиләр.
Бик үртәрләр иде дә шул,
Ашаганны белмиләр!

Шәүкәт Галиев.

?! Шигырьдә без нәрсә табарга тиеш?

КАЗ.

Каз суда йолдыз шәүләсен, күргәч, Балык дип белде һәм, ничә мәртәбә аны ауламакчы булып тырышса да, шәүлә урыныннан кузгалмагач, шәүлә икәнен белде дә аулауны ташлады.

Иртәгесен Каз суда чын Балыкны күргән иде, ну, бу да кичәге кеби шәүләдер дип ауламады вә аңар әйләнеп тә карамады.

Габдулла Тукай.

?! Каз, ялганны — чын, чынны ялган дип, ике тапкыр ялгышты. Габдулла Тукай шул вакыйгадан безгә, укучыларга, нинди киңәш биргән?

ТӨЛКЕ БЕЛӘН ШАКАЛ.

Шакал елый-елый бара икән. Каршына Төлке килеп чыккан.

— Нигә елыйсың? — дип сораган Төлке.

— Миңа тавыклар патшасы бул, диләр.

— Бул соң. Тавыкларга падишаһ булу начармы әллә? — дип гаҗәпләнгән Төлке.

— Әйткәннәре ялган булмагае, дип елыйм, — дигән Шакал.

?! Әйткәннәре ялган булса, Шакал нәрсә югалта?

МЕСКЕН ФЕДЯ.

Федя исемле малайның балалар йортына килүенә өч көн инде. Ләкин ул берәү белән дә дуслашмады. Хәтта башкалар белән сөйләшергә дә теләмәде. Боек, моңсу малай иде ул. Ник бер елмайсын. Ник берәрсе белән уйнарга теләсен. Ул, ни турындадыр уйланып, эскәмиядә тыныч кына утырды да утырды.

Аның янына балалар килми башладылар. Шундый күңелсез малай белән кемнең уйныйсы килсен.

Тәрбияче апалары, бераз күнегә төшсен әле дип, Федяны борчымады. Ә дүртенче көнне кулына китап тоттырды да:

— Ничәнче сыйныфка утырту өчен, ничек укуыңны беләсем килә. Китаптан берничә юл кычкырып укы әле, — диде.

— Мин укый белмим,— диде Федя. Аның бит очлары кып-кызыл иде.

Балалар аңа гаҗәпләнеп карадылар. Арада «пырх» итеп көлүчеләр дә булды. Ун яшьлек малай хәреф танымасын, имеш.

— Шулай ук бөтенләй укый белмисеңмени? Бәлки, хәреф тә танымыйсыңдыр? — дип сорады тәрбияче апалары. Аннары «А» хәрефен күрсәтте дә:

— Бу нинди хәреф? — дип сорады.

Федя битендәге кызыллык арта төште. Ә бераздан ап-ак булып агарды.

— Мин моның нинди хәреф булуын белмим,— диде.

Сыйныф кычкырып көлеп җибәрде. Ә тәрбияче апасы:

— Шушы яшькә җитеп, ни өчен хәреф тә өйрәнмәдең? — дип сорады.

— Фашистлар мине әни белән бергә Германиягә алып киткәндә, миңа биш яшь иде. Без анда заводта эшләдек. Анда фашистлар безне укырга өйрәтмәделәр.

Балалар шып булдылар. Берсе дә көлмәде.

— Ә хәзер әниең кайда? — дип сорады тәрбияче. Федя авыр сулап куйды да:

— Әни Германиядә үлде. Ул озак чирләде. Фашистлар аны барыбер эшләргә мәҗбүр иттеләр. Әни күп эшли алмады, үлде,— диде.

— И мескен бала! Хәреф танымыйм дип оялма. Өйрәтербез. Без сине туган энебез кебек яратырбыз,— диде тәрбияче. Ә балаларга борылып:

— Балалар, Федя белән бергәләп уйнагыз,— диде.

Ләкин Федя уйнаудан баш тартты. Ул, гадәтенчә башын аска иеп, эскәмиядә утыра бирде. Ә беркөнне укытучы апасы аны табиб янына алып барды.

— Сәламәт, шат күңелле булсын өчен, Федяга берәр дару бирмәссезме? Дәваланса, балалар белән уйнар иде, моңаеп, ялгыз гына эскәмиядә утырмас иде,— диде.

— Андый дарулар юк шул бездә,— диде табиб.— Хәер, даруы булмаса, чарасы бар. Сәламәт, шат булу өчен, бердәнбер чара — көлү.

— Аңлыйм! Аны ничек тә булса көлдерергә кирәк. Көлсә, ул да башкалар кебек булачак,— диде тәрбияче.

— Шулай шул,— дип җавап бирде табиб,— көлмәсә, елмаерлык итеп булса да шатландырырга кирәк. Көлсә, елмайса, тап-таза малай булачак.

Табиб киңәшен белеп алгач, балалар Федяны ничек кенә булса да көлдерергә тырыштылар. Көлмәсме дип, юри егылган булдылар, песи булып кыландылар. Сикерделәр. Кулда йөрделәр. Ләкин Федяны көлдерә алмадылар.

Шуннан соң балалар хәтәр гамәлләр уйлап таптылар. Берсе кулындагы таягы белән үз башына шундый тондырды — балалар дәррәү көлделәр. Көтелмәгән хәл һәм залга яңгыраган тавыш көлдерде аларны. Батыр малай үзе генә көлмәде. Башы авыртуына түзә алмыйча, еларга җитешеп, баш чүмечен уа-уа чыгып китте.

Шундый уңышсыз уеннан соң балалар менә нәрсә уйлап таптылар. Кәгазьне йомарлап, кечкенә генә туп ясадылар. Аны песи аягына җеп белән бәйләп куйдылар. Песи, билгеле, тупка ташланды. Ләкин күпме

тырышса да тота алмады. Тотам дип, акылдан шаша язды: сикерде, чапты, сөртенеп егылды, ләкин тубы барыбер тоттырмады.

Бик кызык иде. Бар да көлделәр. Кайберәүләр хәтта чирәмгә егылып көлделәр.

Ләкин Федя бу юлы да көлмәде. Хәтта елмаймады да.

Көлә белмәгәч, ул бервакытта да көлмәячәк дигән фикергә килделәр балалар.

Бермәлне балалар йортына яшь ханым килде. Светлов Гришаның әнисе. Якшәмбе көнне улын өенә алып кайтырга дип килгән иде.

Шатланып, елмаеп керде. Әнисен күргәч, Гриша да, көлә-көлә, әнисе тирәсендә бөтерелде.

Чыгарга дип кузгалганнар иде инде, Гриша әнисенең Федяга күзе төште. Малай, эскәмиядә утырып, аларга хәсрәтле күзләре белән карап тора иде. Уйчан, сагышлы карашын күргәч, Федя янына килде һәм:

— Син бүген өегезгә кайтмыйсыңмыни? — дип сорады.

Федя ишетелер-ишетелмәс кенә җавап бирде:

— Юк, өем юк минем, — диде.

Гриша әнисенә:

—Аның өе дә, әнисе дә юк. Фашистлар... — диде.

Шуннан соң Гришаның әнисе Федяны:

— Теләсәң, әйдә безгә, — дип чакырды.

Гриша кычкырып ук җибәрде:

— Кайтабыз. Нигә кайтмаска! Безнең өйдә күңелле, кызык. Уйнарбыз, — диде.

Кинәт бар да күрделәр: Федя елмайды. Ул авыз кырые белән генә елмайды. Ләкин елмаюын бар да күрделәр. Кул чаптылар һәм:



— Яшәсен Федя!.. Ул елмайды! Ул хәзер таза-сәламәт булачак! — дип сөенделәр.

Гришаның әнисе Федяны кочаклап үпте дә аңа:

— Моннан соң һәр якшәмбедә безгә кайтырбыз. Теләсәң, мин синең әниең булыр идем, — диде.

Шунда Федяның тагын бер тапкыр елмаюын бар да күрделәр. Ә ул, елмаеп, әкрен генә:

— Әйе, телим, — диде.

Гришаның әнисе бер кулын Федяга, икенче кулын улына сузды. Алар өчәү җитәкләшеп балалар йортыннан чыктылар.

Шул көннән соң Федя атна саен аларга кайтты. Гриша аның иң якын дустына әйләнде. Хәзер ул бик нык үзгәрде. Еш шатланды һәм елмайды, көлде.

Шундый чагында аны урамда табиб очратты.

— Ул көлде, шуңа күрә сәламәтләнде. Көлү — кешеләр өчен бик яхшы дәва ул, — диде.

Михаил Зощенко.

?! Хикәянең бер өлеше Федяның хәсрәтле чагы турында. Икенче өлешендә күңелендә башка хисләр өстенлек ала. Федя күңелендәге шундый үзгәрешләрне аңлатыгыз.

КАБАРТМА.

Элек заманда авылдан авылга соранып йөрүче ике теләнче үзара бәхәсләшмәкче булганнар.

Берсе әйткән:

— Әгәр минем капчыгымда ничә кабартма барлыгын белсәң, икесен дә сиңа бирәм, — дигән.

Тегесе:

— Ике! — дигән.

Кабартмалы теләнче иптәшенең зирәклегенә хәйран калган.

— Ничек белдең? — дип сораган.

?! Мәзәктә катнашучыларга бәя бирегез.

САБАН ТУЕНДА.

Безнең авыл янында,
Каенсар урманында
Бик зур Сабан туе була
Һәр ел июнь аенда.

Без бу Сабан туена
Барган идек быел да.
Күрше-тирә авыллардан
Бик күп халык җыелган.

Казаннан да килгәннәр,
Мәскәүдән дә килгәннәр,
Бәрәскәдән, Мәтәскәдән —
Бик күп, бик күп җирләрдән.

У-у-у... малай, анда халык!
Бер миллион әллә тагын.
Санап карамагач, аның
Кайдан беләек санын.

Әтиләр дә бар анда,
Әниләр дә бар анда,
Бабайлар да, әбиләр дә,
Бәбиләр дә бар анда.

Бөтен дөнья төялеп
Күчеп килгән диярлек.
Әхмиләрнең Акбае да
Килгән, безгә ияреп.

Исең дә китәр, анда
Ничә төрле халык бар,
Барсы да бер гаилә кебек —
Дус һәм тату халыклар.

Үзем белмим болай мин,
Әти әйтә шулай дип;
Алар белми әйтми инде —
Дәү кешеләр, шулай бит?

Уйнап тора музыка,
Зур урман шау-гөр килә,
Җырлыйлар да, бииләр дә
Төрлесе төрле көйгә.

«Эх, яблочко!»га,
Кайсылары «Полька»га,
Кайсы «Әтнә», «Әпипә»гә
Такмак әйтеп кул чаба.

Үкчәң сиртмәле мәллә?
Үзең әллә туп мәллә?
Җиргә тими биегәндә,
Тәпиең дә юк мәллә?

Бас, бас, кодача,
Егетләрчә, кызларча,

Тыпыр-тыпыр тик биеп тор,
Табаннарың чыдаса.

Һоп, һоп!
Һоп! Һоп, һи-и!
Итәгеңне җый, Әлфия!
Итәгең җиргә тия.

Чыдый алмый әти дә,
Гармун уйнаган көйгә,
Кеше күрмәгәндә генә,
Тып итеп, җиргә тибә.

Тирә-якта бик матур
Чирәмле җиргә ятып,
Бик күңелле ял итәләр,
Патефоннар уйнатып.

Кайсылары, шаулатып,
Самоварлар кайнатып,
Бик озаклап чәй эчәләр,
Беткәч тагын яңартып.

Кайсылары пилмәннәр,
Бәлешләр китергәннәр,
Әйтерсең лә өйләренә
Кайтмаска дип килгәннәр.

Таныган төсле карап,
Халат кигән апалар
Киләләр дә, мактый-мактый,
Туңдырмалар саталар.

Мактыйсы юк бит аны,
Йомыркалы, шикәрле,
Авызыңа капмас борын
Эреп китә, бик тәмле.

Әй, әтигә мактыйм мин:
— Әмма да тәмле соң, дим,
Апаның да күңеле булсын,
Алыйк тагын берсен,— дим.

Бари Рәхмәт.

?! 1. Өченче һәм бишенче дүртьюллыкларның эчтәлекләре охшаган. Аларны кушып, уртак исем бирегез.

2. Эчтәлекләре шуларга охшаган башка дүртьюллыклар табыгыз.

3. Барысын бергә ике-өч кенә җөмлә белән әйтегез.

4. «Уйнап тора музыка...» дип башланган дүртьюллык халыкның күплеге турында түгел. Нәрсә турында? Бу дүртьюллыкка исем бирегез. Калган дүртьюллыкларны кушып, исем бирегез.

СЕРНЕ АЧТЫ.

Ирага әтисе белән әнисе тутый кош бүләк иттеләр. Ира кошын шунда ук сөйләргә өйрәтә башлады. Бераздан тутый кош эт кебек өрергә, песи кебек мияуларга һәм: «Исәнмесез, балалар!» — дияргә күнекте. Менә хәзер сыйныфташларга илтеп күрсәтергә дә була. Минем нинди укытучы булуымны бар да белсен әле, дип шатланды. Ира мәктәпкә барырга җыенганда, әбисе:

— Кибеткә барып, чәй алып кайт әле, кызым, — дип йомыш кушты.

— Шул гына җитмәгән иде! Вакытым юк. Башымны әйләндермә! — дип җавап бирде Ира.

Әбисе нинди йомыш кушса да, ул һәрвакыт: «Шул гына җитмәгән иде», «Башымны әйләндермә», «Вакытым юк»,— дип җавап бирә иде.

Ира, читлектәге тутый кошын алып, мәктәпкә китте.

Җылы җил хуш исләр чәчә, кояш елмаеп карый, сыйныфташларының мактавын күз алдына китереп, Ира елмая.

Мәктәптә аны укучылар сырып алды.

— Ни дә булса сора әле! Җавап бирсен.

— Шауламасагыз, хәзер сорыйм,— диде Ира һәм тутый кошына:

— Әдәпле бул, Чико, балалар белән исәнләш,— дип боерды.

Тутый кош: «Исәнмесез, балалар!» диясе урында, йоннарын кабартты да Ирага:

— Башымны әйләндермә! — дип кычкырды. Күрәсең, Ираның әбисенә әйткән сүзләрен исенә төшергәндер.

Балалар шаккаттылар, ә Ира каушап калды һәм шунда ук тутый кошына:

— Песи ничек мияулый? Мияулап күрсәт әле, Чико,— дип сорау бирде.

Тутый кош Ирага шәмәхә күзләрен акайтып карады да:

— Шул гына җитмәгән иде! — дип мыгырдады. Ира, еларга җитешеп:

— Ә эт ничек өрә? Эт булып өр, Чико,— дип сорады.

— Бик кирәк. Вакытым юк! — дип кычкырды тутый

кош һәм, баскан ботагыннан башка ботакка күчеп, Ирага арты белән утырды.

Балалар көлделәр, ә Ираның тутый кошына ачуы килде:

— Бу кадәр юньсез булсаң булырсың икән, Чико! Берни әйтергә теләмисең! — диде.

— Ничек әйтергә теләмәсен, ул безгә бик күп нәрсә турында сөйләде, — диде Алёша. Балалар көлешә-көлешә таралдылар.

Григорий Остер.

?! Автор безгә киңәшен әйтмәгән. Үзебезгә табарга кушкан. Табыгыз.

Автор хыялы.

Автор әсәрен иҗат итә. Иҗат итү ул — яңалык уйлап табу. Автор безнең кебек күп күрә, күп ишетә, күп укый. Һәм әнә шул күреп-ишетеп белгәннәре арасыннан тотына сайланырга. Әллә кайчан уйлап куйган әйтәсе киңәшен бездән яшереп кую чарасын эзли. Уйлый торгач, әсәренең ике өлешен таба. Киңәшен, кеше күрмәгәндә генә, шул өлешләр арасына яшерә дә куя. Менә хәзер, хөрмәтле укучылар, автор белән сөйләшә-сөйләшә, үзегезгә кирәкле киңәшне эзләп табыгыз, ди.

Автор уе шуның белән тынычланды, дип уйлый-сызмы? Юк, тынычланмады. Берзаман уеның дәрте шундый арта, шундый арта... җиңнәрен сызгана да тотына бу күз күрмәгән, колак ишетмәгән вакыйгалар уйлап табарга! Авторга кызык — яңадан-яңа могҗиза-лар уйлап табуга ни җитә! Безгә дә кызык: әбиләрнең себеркегә атланып очуын күз алдына китерү ни тора! Бүрек кию белән юкка чыгучы кешегә ияреп йөрү кызык түгелме? Үзе синең яныңнан бара, үзе юк.

Авторның тиктормас уе безне җирдән күкләргә алып менә, диңгез төбенә төшереп, су астындагы алтын сарайларда яшәтә... Ә иң мөһиме: эзләнүчән автор уе безнең уйны да үз артыннан ияртә.

Менә шундый канатлы уйга **хыял** диләр. Ә хыял-ның яраткан дөньясы — әкиятләр иле. Ни өчен шулай? Чөнки ул илне авторның хыялы тудыра.

Түбәндәге әкият алты яшьлек малайның туган көнен үткәрү турында. Әгәр автор (әдип): «Ялмар исемле малайның туган көнен бик матур итеп үткәрделәр»,— дип язса, без бу язманы әсәр димәс идек. Сезнең туган көннәр дә шулай үтте бит. Әгәр автор уе туган көнне читтәге куаклар арасына кертеп адаштырса, димәк, ул әкият яза. Әкиятне укып елмаябыз, көләбез. Адашкан туган көнне кызганабыз, яратабыз.

ОНЫТЫЛГАН ТУГАН КӨН.

Зоопаркта бик дәү бер фил яшәгән. Аның хатыны һәм Ялмар исемле улы булган. Әти фил ай-яй дәү булган. Әни фил дә гәүдәгә иреннән калышмаган. Хәтта Ялмарны да бәләкәй димәс идем. Бик бәләкәй филләр булмый бит.

Көннәрнең берендә Әни фил белән Ялмар шаккаталар! Әти фил, арт аякларын күтәреп, башында басып тора...

— Ни булды? Нигә башыңда торасың? — дип сораган Әни фил.

— Нәрсәнедер исемә төшермәкче булам,— дигән Әти фил.

— Нәрсәне исеңә төшермәкче буласың соң?

— Нәрсә икәнен белсәм, искә төшерү өчен шушылай тырышыр идеммени, күгәрченем? — дигән Әти фил.

— Бар, Ялмар, чап, әтиең югалткан нәрсәне тизрәк табарга тырыш,— дигән улына Әни фил.

Ялмар юлдан җан-фәрманга чабып киткән. Аннары, куаклыклар янындагы калкулыкка менеп, бераз тын алырга утырган. Бер уңайдан күктәге болытларның куышып уйнауларын да күзәткән.

Кинәт ул кемнеңдер елавын ишеткән. Якында гына елый, үзе күренми.

— Елама. Ярдәм итимме? — дип сораган Ялмар.

Теге кемдер елаудан туктаган.

— Кем син? — дип сораган Ялмар.

— Мин онытылган туган көн. Ләкин кемнең туган көне булуымны белмим.

— Башыңа ай-яй зур бәла төшкән икән шул, — дигән Ялмар. — Бәйрәм бәлешең бармы соң синең?

— Булмый ни. Бәлешсез туган көн буламыни? Минекендә алты шәм бар. Димәк, кемгәдер бүген алты яшь тулган.

«Алты яшь тулу нинди бәхет, — дигән үз-үзенә Ялмар. — Алты яшь җиде яшь тулган кебек әйбәт. Биш яшь тулу да начар түгел, дүрт яшь тә ярыйсы. Ә сигез яшьтә син үскән кеше буласың инде. Алай да алты яшь тулуга ни җитә?»

— Бик ярдәм итәр идем дә бит, туган көнен оныткан кешене белмим шул, — дигән Ялмар һәм өенә кайтып киткән.

Кайтса, әтисе ашап утыра.

— Исемә төште! Кичәме, иртәгәме, бүгенме булуы хәтердә иде бит югыйсә. Белдем бит! — дигән Әти фил.

— Нәрсә белдең? — дип сораган Ялмар.

— Бүген синең туган көнең булуын онытан әтиең, — дигән Әни фил, бүлмәгә керә-керә. — Бүген синең туган көнең, Ялмар.

Ялмарның шатлыгыннан башы күккә тия язган. Ул шунда ук җан-фәрманга куаклык янындагы калкулыкка торып чапкан.

— Ишетәсеңме? Син минем туган көнем икәнсең

бит! Миңа бүген алты яшь тулган! — дип кычкырган Ялмар.

— Ура, ура, ура! — дип шатланган онытылган туган көн.

Кич җиткәч, Ялмарга алты шәмле бәлеш бүләк иткәннәр. Ул, озын хортум-борынын сузып, бер өрүдә шәмнәрнең алтысын да сүндергән.

«Алты яшь тулу нинди бәхет!» — дип, шатлануын дәвам иткән Ялмар.

Дональд Биссет.

?! Әкияттә кызыклы табышлар күп. Шулар турында сөйләгез.

АННАБЕЛЬ.

Аннабель исемле сыер яшәгән. Гади сыер түгел, диңгез корабын һәлакәттән коткарган[1] сыер.

Томанлы көнне ул диңгез ярындагы болында утлап йөргән[2]. Томан куе булган. Аннабель, күрмичә, чәнечкеле шайтан таягын йотып җибәргән.

Ай-яй-яй! Шуннан соң эченең ничек авыртуын белсәгез икән! Авыртуына чыдый алмагач, Аннабель мөгри башлаган. Шундый итеп мөгрәгән, аның тавышын хәтта диңгездәге зур корабта да ишеткәннәр. Капитан, биноклен күзенә куеп, тавыш иясен эзләгән. Ләкин, күпме караса да, куе томан эченнән бернәрсә дә күрә алмаган. Ярдәмчесеннән:

— Без хәзер кайсы урында? — дип сораган.

---

[1] Һәлакәттән коткару — бу урында батудан коткару.
[2] Утлап йөри — үлән ашап йөри.

— Тәгаен генә әйтә алмыйм. Ләкин ярдан ерак булмаска тиешбез,— дип җавап биргән капитан ярдәмчесе.

— Сигнал бирегез, — дип боерган капитан.

Капитан ярдәмчесе сигнал биргән.

— У-у-у-у-у-у! — дип, дөньяны яңгыраткан сирена.

Аннабель кораб тавышын ишеткән. «Тагын бер сыер шайтан таягы ашагандыр. Эче авыртадыр. Табибка хәбәр итәргә кирәк»,— дип уйлаган. Аннабель ул сыерга мөгрәп җавап биргән. Тавышыңны ишеттем, ярдәм итәрмен, дип аңлаткан.

— Ишетәсезме? — дип сораган капитан.

Ярдәмчесе сирена тавышын туктаткан. Колагына ап-ачык тавыш килеп кергән:

— М-у-у-у-у-у!

— Аннабель тавышы. Димәк, без ул утлый торган яланга таба барабыз, — дигән капитан. Шунда ук:

— Стоп машина! Артка ишегез! — дип боерган.

— Якорь ташлагыз!

— Сигнал бирегез!

Якорь төпкә төшеп бәрелгән. Кораб туктап калган. Сирена кабат үкерә башлаган:

— У-у-у-у-у-у!

Ул арада кояш күренгән. Капитан, ярга карап: «Ярый әле, корабымны туктатырга өлгергәнмен, югыйсә тагын бер генә минут соңга калсам да, ярга бәрелеп челпәрәмә киләсе икән», — дип сөенгән. Ә корабын ул фәкать Аннабель ярдәме белән генә исән калдырды бит.

Аннабельнең тагын: «М-у-у-у-у! М-у-у-у-у-у!» — дип мөгрәве ишетелгән.

«Гаҗәп, бәлки, аның эче авырта торгандыр»,— дип уйлаган капитан. Ярга табибын җибәргән. Аңа:

— Менә моны да бүләк итеп бирегез әле үзенә, — дигән һәм эченә көмеш медаль салган тартма тоттырган.

Табиб ярга аяк басканда, Аннабель әле һаман мөгрәвен дәвам итә икән. Ләкин, дару йоту белән, эченең авыртуы ялап алгандай юкка чыккан.

— Капитан сиңа менә моны да бирергә кушты, — дип, табиб тартманы Аннабельгә сузган. Ә тартмага: «Корабны һәлакәттән коткарган өчен, капитаннан Аннабельгә», — дип язылган булган.

Тартмада чын-чыннан көмеш медаль булган. Табиб аны Аннабель муенына асып куйган. Медале белән чиксез горурланган Аннабель.

— Синең мөгрәвең безнең корабны исән калдырды. Ә хәзер сау бул. Корабка ашыгам. Америкага кайтасы бар, — дигән табиб.

Табиб корабына әйләнеп кайткан. Ул арада кояш томанны тараткан. Аннабель, диңгезгә күз атып:

— М-у-у-у! — дигән.

— У-у-у! — дип җавап биргән аңа кораб.

Кораб ярдан ераклашкан. Аның «У-у-у»ы акрынайганнан-акрыная барган. Ләкин бинокле белән капитан медальле Аннабельне күрә алган әле.

— М-у-у-у! — дигән Аннабель, диңгезгә карап. — М-у-у!

Ачык диңгез уртасындагы корабтан «У-у-у!» тавышы ишетелгән.

Аннабель үзен үтә дә бәхетле итеп хис иткән. Чирәм чемчengәndә, аның медале кояшта ялт-йолт килеп ялтыраган.

Дональд Биссет.

Халык әкиятләре, гадәттә, нәрсәдер югалту яки өч туганның ил гизәргә чыгып китүе белән башлана. Аларга дошманнарын җиңәргә үз хатыннары, дию хатыннары, юлда очраган әбиләр, бабайлар ярдәм итә. Автор язган әкиятләрдә эш башкачарак тора. Аларның даими башламы да, ярдәмчеләре дә, бертөсле персонажлары да юк. Әкият авторлары кешеләр холкын хайваннарга, җәнлекләргә, җансыз предметларга бүләк итәргә яраталар. Хыяллары белән берсеннән-берсе тылсымлырак, гаҗәбрәк вакыйгалар уйлап табалар.

Сыерның диңгез корабларын коткарганын кемнең күргәне бар?

Чынлыкта Аннабель кораб коткарам дип мөгрәми дә. Эче авыртканга гына мөгри. Ләкин без ул сыерны яратабыз. Автор аңа кешенең бик матур сыйфатларын биргән. Ул үзе ярдәмгә мохтаҗ чакта да башка сыерларга ярдәм итү юлларын эзли. Ул — кешеләр кебек, игелекле персонаж. Шуңа күрә аның үзенә дә игелек күрсәтүчеләр күп. Игелек турындагы әкият тормышчан әкият кенә була ала.

БОРЧАК ӨСТЕНДӘГЕ ПРИНЦЕССА.

Яшәгән, ди, бер принц. Менә аның өйләнер чагы җиткән. Ул бары тик принцессага гына өйләнергә теләгән. Тегенди-мондыена гына түгел, иң гүзәленә, иң чынына!

Бөтен дөньяны урап кайткан ул, әмма үзенә кәләш таба алмаган. Принцессалар күп булган анысы. Тик

менә аларның чынмы-түгелме икәнлекләрен ничек белергә?

Менә, шулай итеп, безнең принц буш кул белән кайтып кергән һәм кара кайгыга калган: бигрәкләр дә чын принцессага өйләнәсе килгән шул аның.

Беркөнне кичен көчле давыл чыккан. Яшен яшьнәгән, күк күкрәгән, чиләкләп яңгыр коя башлаган.

Кинәт кемдер сарай капкасын каккан, капканы ачарга карт король үзе чыккан.

Капка төбендә принцесса тора икән. Йа Хода, нинди хәлгә калган ул! Өс-башына адәм карарлык түгел. Яңгыр суы кызның чәчләреннән күлмәгенә, күлмәгеннән аяк киемнәренә ага икән. Шундый чыланган, мескенкәй, әйтерсең лә әле генә елгадан тартып чыгарганнар үзен...

Җитмәсә, нәкъ менә үзенең чын принцесса булуына ышандырырга тырыша бит әле!

«Ярар соң, белербез кемлегеңне»,— дип уйлаган карт король, ләкин бу хакта берәүгә дә бер сүз әйтмәгән. Ул йокы бүлмәсенә кергән, караваттан бөтен ястык-мендәрләрне идәнгә ишеп төшергән дә коры такталар өстенә бер бөртек борчак куйган. Аннан соң ул борчак өстенә егерме ястык белән каз мамыгыннан ясалган егерме түшәк өйгән.

Менә шул урынга йокларга салганнар да инде принцессаны. Иртән аның ничек йоклавы белән кызыксынганнар.

—Аһ, коточкыч начар йокладым! — дип зарланган принцесса.— Төн буена ник бер генә тапкыр булса да керфек кагыйм, ичмасам! Нинди урында йоклавымны мин беләм дә, бер Хода үзе генә белә! Миңа бүген таш-түмгәкләр өстендә ятканмындыр сыман тоелды.

Бөтен тәнем болай күгәреп чыкмас иде югыйсә. Аһ, бик начар йокладым мин, бик начар!

Шунда барысы да аның чын принцесса булуына ихластан ышанганнар. Шулай булмыйча, кечкенә генә бер борчак бөртеген егерме кат ястык белән егерме кат түшәк аркылы тойган бит ул! Бары чын принцесса гына шулкадәрле иркә булырга мөмкин.

Һәм принц аңа өйләнгән.

Ә теге борчак бөртеген музейга озатканнар. Алай-болай ялгыш берәрсе алмаган булса, ул бүген дә шунда торадыр әле.

Менә бит нинди хәлләр дә була бу дөньяда!

Ханс Кристиан Андерсен.

4 Әкиятне үзебезчә сөйлик: «Яшәгән, ди, бер крестьян егете. Эшчән, тәртипле егет. Менә аның өйләнер вакыты җиткән...» Дәвам итегез. Ул нинди кызга өйләнергә теләгән?

ЕЛАНГА ӘЙЛӘНГӘН ПАТША КЫЗЫ.

Бер патшаның кызы туа. Әтисе белән әнисе шатланып туя алмыйлар. Ләкин бәла аяк астында, диләр. Сарайга[1] явыз сихерче карчык килеп керә дә нәни кызны Еланга әйләндереп китә. Елан яңа туган балага орынганда гына сихереннән котылачак, дип чыгып китә.

Бу якларда кызы белән бер ярлы крестьян яшәгән. Кызы көн дә, болынга чыгып, сарыкларын көтә икән. Көннәрнең берендә ул үлән арасында искиткеч матур Елан күрә. Кыз Еланны алып башыннан сыйпый. Ә Елан шуны гына көткән икән, кешечә болай ди:

— Мине өеңә алып кайтып тәрбиялә. Яхшылыгыңа яхшылык белән җавап бирермен. Тик минем турыда берәүгә дә әйтмә,— ди.

Кыз шулай итә дә. Еланны өенә алып кайта. Әтисенә күрсәтмичә генә, иртә-кич сөт эчертә.

Еллар үтә, кыз белән Елан үсә. Ә беркөнне Елан дустына:

— Әтиеңә әйт, базарга барып, сиңа зур сандык алып кайтсын,— ди.

Көтүче кыз Елан үтенечен шатланып үти, әтисенә, зур сандык алып кайт, дип ялвара. Әтисе яраткан кызына базардан зур сандык алып кайта. Ә сандыкны ачып карасалар — эче тулы алтын һәм асылташ! Кызның әтисе чак кына һуштан язмый кала. Күп тә үтми, ул җир сатып ала. Анда зур, гүзәл йорт салдыра. Хәзер кыз сарык көтүен ташлый, ата белән кыз ачлыктан котылып яши башлый. Бераздан Елан кызга:

---

[1] Сарайга — патшалар яши торган йортка.

— Иң матур күлмәгеңне әзерләп куй. Иртәгә шаһзадә ауга барганда, тәрәзәң яныннан үтәчәк, — ди.

Шулай була да. Шаһзадә матур йортны күреп гаҗәпләнә, ә тәрәзәдән карап торган кызга шунда ук гашыйк була. Егет киткәч, Елан:

— Өч көннән патша киләчәк. Улына сине сораячак, — ди. Өч көннән патша килеп төшә. Булачак килененең чибәрлеген охшата. Улына кияүгә чыгарга рөхсәтен сорый. Кыз риза була. Патша туй көнен әйтеп китә.

Иртәгә туй буласы көнне Елан дустына:

— Иртәгә сине шәһәргә алып китәчәкләр. Үзең белән, пыяла савытка салып, мине дә алып кит, — ди.

Кыз бу юлы да Елан кушканны эшли.

Патша сараена килеп җитәрәк, Елан кинәт үсә-зурая башлый. Зурая торгач, пыяла савытын ватып чыга. Кыз, күкрәгенә сыенып, колагына:

— Сау бул, дустым. Балаң тугач, бакча ягындагы тәрәзәңне ачып куй. Курыкма, — ди. Шулай ди дә җиргә сикереп төшә.

Яшьләр патша сараена барып җитәләр. Туйларын үткәрәләр. Алардан да бәхетле кеше булмый.

Вакыт үтә. Килен бала таба. Елан көттерми. Шунда ук, чыжылдый-чыжылдый, ачык тәрәзәдән шуышып керә. Бүлмәдәгеләр бар да куркып качалар. Елан бала тоткан яшь ана күкрәгенә шуышып менә.

Бүлмәгә, коты очып, шаһзадә килеп керә һәм шакката: каршында елмайган хатыны, ә аның янында баласын күтәргән чибәр кыз басып тора.

Ул арада, хатынын ияртеп, патша керә.

Кыз, аларга карап:

— Мине явыз сихерче карчык куркыныч Елан

иткән иде. Инде яман сихердән котылдым. Хәзер туганнарымны табасы иде, — ди.

Патша да, хатыны да шатланалар. Улларын, киленнәрен, кунак кызын кочаклап үбә башлыйлар.

?! 1. Әкиятне кыскартып сөйләгез. Бер җөмләгә генә калдырганчы кыскартыгыз. Ул җөмлә әкиятнең эчтәлеге булырга тиеш. Ә эчтәлек ул — авторның безгә әйткән киңәше.

2. Авторның хыялы уйлап тапкан урыннарны әйтегез.

ГУЛЛИВЕР ПӘҺЛЕВАННАР ИЛЕНДӘ.

I

Лилипутлар иленнән исән-имин әйләнеп кайкаңнан соң, Гулливер өендә күп тормады. Ике ай үтүгә, ул ерак илләргә юл тотучы кораб табибы иде инде. 1702 нче елның 20 нче мартында кораб ярдан кузгалды. Бер ярымутрауда кышлаганнан соң, кораб тагын кузгалып китте. Ләкин көтмәгәндә җил-буран чыкты. Корабны егерме көн буена кая тели шунда куып йөртте. Ниһаять, тынды. Еракта яр күренде. Җиргә якынрак килеп якорь салгач, капитан берничә матросны, көймәгә утыртып, су алырга җибәрде. Алар белән бергә Гулливер да китте. Матрослар су эзләгән арада, Гулливер утрау белән танышты. Тирә-як таш та ком. Юллар да күренми, йортлар да. Күзәтерлек кызыклы нәрсә тапмагач, Гулливер кайту ягына борылды. Диңгез ярына килеп җиткәч, ни күзе белән күрсен — матрослар, җан-фәрманга ишеп, корабка таба йөзәләр. Алар артыннан күз күрмәгән, колак ишетмәгән таудай гәүдәле пәһлеван чаба. Чаба, чөнки диңгез аның тезенә дә җитми. Гулливерның башы әйләнеп китте. Җиргә авып, ташлар арасына шуышты.

II

Чаба торгач, куе урман эченә керде. Наратка охшаган юан-юан шома агачлар арасыннан китте. Агачлар башына күтәрелеп караса, ни күзе белән күрсен — агач башында арпа башаклары асылынып тора. Урман дигәне арпа басуы булып чыкты. Бара-бара Гулливер биек койма каршына килеп чыкты. Гулливер аның югары чиген бик җентекләп карагач кына күрә алды. Койманы үтү мөмкин түгел иде. Күпме эзләсә дә, керер ярык та таба алмады.

Көтмәгәндә, каршында башы күккә тиярлек пәһлеван пәйда булды. Ул диңгездә көймә артыннан чабучы алыптан да биегрәк иде. Гулливер, коты очып, арпа басуына чапты. Калын арпа сабагы артына качып, пәһлеванны күзәтте. Бермәлне, күк күкрәде диярсең, алып кемгәдер дәште. Ерактан аңа берничә күк күкрәве җавап бирде. Бу алыпка тагын үзе кебек җиде алып кушылды. Болары хезмәткәрләре булса кирәк, кулларына ураклар алып, арпа басуын урырга керештеләр.

Хәл мөшкел иде. Гулливерның күзенә берни күренмәде. Ул аркылы-торкылы яткан саламнарны үрмәләп үтә-үтә егылганчы чапты. Бермәлне башын күтәреп караса — баш очында кап-кара плитә асылынып тора: коточкыч зур башмак табаны. Урак уручыларның берсе икән. Башмагы белән менә-менә таптыйм дип торганда, Гулливер кычкырып җибәрде. Пәһлеван аның тавышын ишетте. Башаклар арасыннан эзләнә торгач, Гулливерны күреп алды. Башта ул аңа, бу бөҗәк тешләмәгәе дип, күзен алмый карап торды. Аның кешечә нидер әйтүен ишеткәч, бу кешечә сөйләшә торган чикерткә аңа ошады. Гулливерны кулъяулыгына төреп, өйгә таба чапты.

Күп тә үтмәде, Гулливер йорт хуҗасы кулында иде инде.

Хуҗа да аны күзе янына ук китереп, бик җентекләп, әйләндерә-әйләндерә карады. Кешегә охшаган бөҗәкне күрү өчен, уракчы хезмәткәрләр дә җыелды. Хуҗа Гулливерны җиргә төшерде. Дүрт аяклап чабачак, дип уйлады, күрәсең.

Ләкин Гулливер үзенең кеше булуын исбат итте: эшләпәсен салды, башын иеп сәлам бирде. Алыплар хәйран калдылар. Хуҗа Гулливерны, яулыгына төреп, өенә алып керде.

III—IV

Хуҗа Гулливерны хатынына күрсәтте. Хатын, башта куркып, артка чигенде. Колак тондырырлык итеп чәрелдәде. Ләкин кечкенә кунак белән бераз танышкач яратты. Гулливерны үз тәлинкәләре арасына утыртып сыйлады.

Хуҗаларның чибәр генә, акыллы гына кызлары бар иде. Аңа тугыз яшь тулса да, буе кыска, нибары өч катлы йорт хәтле генә иде. Ул Гулливерны «грильдриг», ягъни кечкенә кеше дип йөртә башлады. Аңа җиде күлмәк текте. Яшәр өчен бик матур йорт ясатты.

Хуҗа кызыннан Гулливер аларча сөйләшергә өйрәнде.

V

Хуҗасы Гулливерны шәһәрдән шәһәргә йөртә. Аны халыкка күрсәтеп, акча эшли. Гулливер, халык алдында чыгыш ясый-ясый, тәмам хәлдән тая. Бу бәладән аны король кешесе коткара. Берзаман көтмәгәндә килеп керә дә, король китерергә кушты дип, Гулливерны

сарайга алып китә. Король аны гаиләсенә күрсәтергә ниятләгән икән.

Хуҗа кызы Гулливерны юа, матур итеп киендерә һәм король сараена алып китә. Гулливер король гаиләсенә, бик тырышып, белгәнен күрсәтә. Моңа кадәр аның бервакытта да шпагасы белән шулай җитез селтәнгәне юк иде әле. Гулливерның тырышлыгы ханбикәгә ошый. Ханбикә аңардан чыгышы, туган иле турында сораша һәм сарайда калырга тәкъдим итә. Гулливер, әлбәттә, шунда ук риза була.

Аны хуҗасыннан сатып алалар. Һәрвакыт янында булсын дип, хуҗа кызы янында калдыралар.

Ханбикә Гулливерны корольгә күрсәтә. Король башта аның кеше булуына ышанмый. Кемлеген белү өчен, илнең иң танылган галимнәрен чакырта.

Галимнәр, озак тикшереп өйрәнгәннән соң, мондый фәнни нәтиҗәгә киләләр: ул ерткыч түгел, чөнки ике генә аягына басып йөри һәм гади кеше кебек сөйләшә. Кош та түгел, чөнки канатлары юк. Балык та түгел, югыйсә койрыгы булыр иде. Илебезнең фәнни китапларында һәм сүзлекләрендә кешегә охшаган мондый бөҗәк турында берни дә язылмаган. Ул, мөгаен, кеше түгелдер, диләр.

Гулливер, бу сүзләрне ишеткәч, бик нык үпкәли:

— Теләсә нәрсә әйтегез, ләкин мин — кеше. Безнең якта минем кебек миллионлаган кеше яши. Безнең таулар, елгалар һәм агачлар, безнең өйләр, манаралар, атлар, хайваннар — бар да сезнекенә караганда берничә тапкыр кечкенәрәк,— ди.

Галимнәр кычкырып көләләр.

— Мондый бөҗәк сүзләренә ышанырга әллә безне тиле дип белдеңме? — диләр.

Король исә үз сүзен әйтә:

— Ул — бөҗәк түгел, кечкенә кеше,— ди һәм ханбикәгә Гулливерны саклап тәрбияләргә куша. Ханбикә Гулливерны болай да кәрләсеннән күбрәк ярата. Шуңа күрә кунагына, яшәү өчен, кулыннан килгән кадәр яхшы шартлар тудыра.

Моңа кадәр кәрлә илдәге иң кечкенә пәһлеваннардан саналган. Ләкин аны Гулливер белән чагыштырып буламы соң? Кәрләсен кәрлә, ләкин аның буе пәһлеван балаларының җилкәсенә җиткән.

Король сараенда Гулливер үзен бәхетле саный. Хәзер ул, пәһлеваннарны күргәч, аларның олылыгына да, күк күкрәгән кебек сөйләшүләренә дә күнегә. Ханбикә аны иркәли, ә кызлары ансыз ашарга да утырмыйлар.

Ләкин Гулливерга ямьле тормышын ямьсезләүче дошманы белән бик еш көрәшергә туры килә. Гулливер монда күчеп килгәч, ханбикәнең кәрләсенә бер дә игътибар итми башлыйлар. Ул король сараенда кашын җимереп, усалланып йөри. Гулливерны аеруча дошман күрә. Ханбикә белән кызлары янында утырып ашауларын күргәндә, башка хезмәтчеләр белән үз булып сөйләшүен ишеткәндә, кәрләнең җен ачулары чыга. Җае чыккан саен, Гулливердан үч алу ягын карый...

Кыз бүлмәдән бер генә минутка чыга. Кәрләгә шул да җитә. Кәрлә диванга сикереп менә. Гулливерны, тотып, каймак савытына ыргыта. Гулливер шунда ук каймак төбенә төшеп китә.

Ә явыз кәрлә бүлмәдән җан-фәрманга чабып чыга да бер почмакка кереп кача.

Мескен Гулливер куе каймак эчендә бата-калка тыпырчынган арада йоткан салкын каймак бер чиләккә җиткәндер.

Аны, һәрчактагы кебек, багучы кызы коткара...

Гулливер бу илдән болай котыла.

Диңгез күрәсем килә дигәч, аны, өенә ябып, ялчы малайга бирәләр. Малай, өйне ярга куеп, азга гына читкә китә. Шул арада пәһлеваннар илендәге ниндидер дәү кош, Гулливерны өе-ние белән күтәреп, күккә күтәрелә. Күктә, ике кош сугышканда, өй кош тырнагыннан ычкына. Бәхете булгандыр, өй диңгезгә төшә, һәм Гулливер исән кала. Тиздән үтеп баручы кораб кешеләре аны коткаралар. Гулливер, шулай итеп, исән-сау үз өенә кайтып керә.

Джонатан Свифт.

?! Автор хыялы сурәтләгән образлар һәм вакыйгалар турында сөйләгез.

БАТЫР ТЕГҮЧЕ.

Җәйге көннәрнең берсендә бер абзый тәрәзә каршында тегү тегеп утыра икән. Кәефе күтәренке булганга, эше дә әйбәт тәгәри, ди. Нәкъ шул чакта урам буйлап бер хатын үтеп бара икән, үзе әледән-әле:

— Әйбәт кайнатма[1] сатам! Тәмле кайнатма сатам! — дип кычкыра, ди.

Сатучы хатынның тавышы тегүчегә бик ягымлы булып ишетелгән, ул, үзенең ябык озын муенын тәрәзәдән сузып:

— Монда мен әле, кадерлем, товарыңны үзем алырмын, — дип кычкырган.

---

[1] Кайнатма — варенье.

Сатучы, авыр кәрзиннәрен күтәреп, тегүче яшәгән өченче катка күтәрелгән дә аның алдына төрле-төрле кайнатма салынган чүлмәкләрен тезеп куйган. Тегүче аларның барысын да җентекләп карап, иснәп чыккан. Аннары хатынга:

— Кайнатма миңа бик ошый. Дүрт мыскал үлчәп бир әле, кадерлем. Бәлки, чирек кадак та артык булмас,— дигән.

Байтак әйберемне сатармын, ахры, моңа, дип өметләнгән хатын, кәефе кырылып, тегүчегә сораган кадәр кайнатмасын үлчәп биргән дә ачулы мыгырдана-мыгырдана китеп барган.

Шушы кайнатма беләкләремә көч, буыннарыма дәрман өстәсен иде, дип теләгән тегүче. Аннары шкафындагы ипидән зур гына бер телем кисеп алган да әлеге кайнатманы юка гына итеп шуның өстенә яккан. Тәмле булырга охшый үзе, рәхмәт төшкере. Башта шушы куртканы тегеп бетерим инде, дигән. Кайнатма яккан ипи телемен өстәленә куйган да, ашыга-ашыга, киемен җөйли башлаган. Ул арада тәмле кайнатма исе бөтен бүлмәгә таралган. Стена, түшәмнәргә кунып, ялкау гына арлы-бирле очып йөргән чебеннәр өерләре белән кайнатма ягылган ипи телеменә ябырылганнар. «Кем чакырды соң әле сезне монда?» — дип үртәлгән тегүче. Чыдамаган әрсез кунакларны пыр туздырып куа башлаган. Ләкин чебеннәр немец телен аңламаганмы, тәмле сыйдан баш тартасылары килмәгәнме, тагын да ишәебрәк җыела барганнар. Эшләр болайга киткәч, тегүченең сабырлыгы тәмам беткән. Чүпрәк кисәге эләктергән дә, әле сез шулаймыни, күрсәтим әле, алайса, күрмәгәнегезне дип, чебен өеренә шап берне! Чүпрәген алып санаса, алдында җиде чебен тәгәрәшеп ята, ди.

Тегүче, шундый батырлык күрсәтүенә үзе дә таң калып: «Менә мин нинди егет!» — дигән. Аннары бу хакта бөтен шәһәр белергә тиеш, дип уйлап алган. Үзенә билбау теккән. Аңа зур-зур хәрефләр белән «Бер сугуда җидәүне егучы!» дигән сүзләр чигеп куйган. «Һәй, нигә безнең шәһәр генә, бөтен дөнья белергә тиеш мине!» — дип уйлаган ул бераздан.

Тегүче билбавын буган да, дөнья гизәргә ниятләп, юлга җыенган. Юлда ашарга берәр нәрсә тапмакчы булып, бүлмәсенең астын-өскә китергән. Ләкин күгәреп беткән сыр кисәгеннән башка берни дә таба алмаган, ахыр чиктә шуны кесәсенә тыгып куйган.

Кайсы якка караса, шул якка барган да барган. Көн барган, төн барган бу, шулай итеп, ниндидер бер король сараена килеп җиткән. Көн буе йөри-йөри, ярыйсы ук арыган. Йомшак чирәмгә утыруы белән йокыга да киткән. Шулай йоклап ятканда, моның янына кешеләр җыелган, барысы да, кызыксынып, тегүчене күзәтәләр икән. Билбавындагы «Бер сугуда җидәүне егучы!» дигән сүзләрне укыгач, болар:

— Ай-яй, ил тыныч чакта нишләп йөри икән монда бу баһадир? Мөгаен, бик көчле сугыш чукмарыдыр бу,— дип тел шартлатканнар. Аннары билгесез батыр турында корольгә хәбәр итеп:

— Әгәр дә мәгәр сугыш-фәлән чыга калса, файдалы кеше бит бу, һич тә кулдан ычкындырырга ярамый аны,— дигәннәр.

Бу фикер корольгә дә ошаган. Ул хезмәтчеләреннән берәүне тегүче янына җибәргән.

Әлеге хезмәтче йоклаган тегүче янына килгән. Тегенең уянганын көтеп басып тора икән. Күпмедер шулай ятканнан соң, тегүче киерелә башлаган, аннары

күзләрен ачкан. Король хезмәтчесе шунда ук йомышын үтәргә ашыккан.

— Үземнең дә килүем нәкъ менә шуның өчен иде. Шушы минуттан король хезмәтенә әзермен,— дип җавап биргән тегүче.

Сарайда аңа зур хөрмәт күрсәткәннәр, баһадирның үзенә аерым бер бүлмә биргәннәр. Билгесез килмешәкнең кинәт болай күтәрелүе король вәзирләренең көнчелеген уяткан. Алар тегүчене тотып ашардай булганнар, күңелләреннән аның җәһәннәмгә олагуын теләгәннәр. Үзара:

— Киләчәктә әллә нинди хәлләр булуы ихтимал. Әгәр дә мәгәр, гауга кубып, аның белән даулаша башласак, барыбызны да тотып дөмбәсләячәк бит бу. Бер сугуда эһ тә итми җидебезне тәгәрәтәчәк, арабыздан кем дә аңар каршы тора алмаячак,— дип пошыналар икән.

Шулай уйлашканнар, киңәшкәннәр дә, бергәләшеп король алдына килеп, үзләрен хезмәттән азат итүне үтенгәннәр.

— Аның белән бергә хезмәт итә алмыйбыз, бер сугуда җидәүне ега торган кешегә беркем дә сүз ката алмаячак,— дигәннәр.

Король тәмам хафага төшкән. Билгесез бер кеше аркасында үзенең ышанычлы хезмәтчеләреннән колак кагарга бер дә теләмәгән. Тегүчене бүтән әйләнеп кайтмаслык җиргә олактырырга ният кылган. Король тегүчене чакырырга кеше җибәргән.

Король урманнарының берсендә ике пәһлеван яшәгән икән. Алар кешеләрне талап, үтереп, йорт-җирләрен яндырып, бик күп бәла-каза китергәннәр, ди. Юлбасарларга каршы чыгарга берәү дә батырчылык

итмәгән. Тегүче кергәч, аңа йомыш кушкан. Шушы ике пәһлеванны җиңә алсаң, бердәнбер кызымны ярәштерәм. Өстәвенә ярты мәмләкәтемне бүләк итәм, дигән. Ярдәм кирәк булса, үзең белән кораллы йөз җайдак алырсың, дигән дә, вәгъдәсен раслап, ант эчкән.

Миндәй егеткә король кияве булу начар булмас иде булуын, дип уйлаган тегүче. Аннары корольгә:

— Баш өсте, галиҗәнап. Пәһлеваннарны җиңәчәгемә тамчы да шигем юк, кораллы гаскәрең дә кирәкми. Бер сугуда җиде җанны теге дөньяга олактырган баһадирга ике юлбасар гына нәрсә ул?! — дигән.

Тегүче юлга чыккан. Теләмәсә дә, король әмере буенча, аны атка атланган йөз кораллы кеше озата барган. Пәһлеваннар яшәгән урманга килеп җиткәч, тегүче, озатучыларны туктатып:

— Шушында гына торыгыз, юлбасарлар белән исәп-хисапны үзем генә өзәрмен,— дигән.

Урман эченә ялгызы кереп киткән тегүче. Бераздан тукталып, тирә-ягына карана торгач, пәһлеваннарны да күреп алган. Бер агач төбендә йоклап яталар икән болар. Гырылдауларыннан тирә-яктагы агачларның юан-юан ботаклары чайкала, ди. Тегүче ике кесәсенә дә ташлар тутырган. Агач башына, пәһлеваннар йоклап яткан турыга үрмәләгән. Биек агачның урта бер җиренә җиткәч, бер ботакка утырган. Шуннан соң пәһлеваннарның берсенә таш ыргытырга тотынган. Пәһлеван берзаман күзләрен ачкан да, иптәшенең кабыргасына төртеп:

— Нигә әле һаман миңа сугасың да сугасың? — дип ачуланган.

— Нишләп сиңа сугыйм, ди, мин? — дигән икенчесе.

Пәһлеваннар яңадан йокыга киткәннәр. Хәзер инде тегүче пәһлеваннарның икенчесенә таш ыргыта икән.

— Ни дип син мине болай дөмбәслисең әле? — дип ярсыган хәзер икенче пәһлеван.

— Нишләп сугыйм, ди, мин сиңа, аптыратма әле! — дигән беренчесе.

Көне буе йөреп, икесе дә нык арыган булганга, шулай бераз даулашып алганнар да тагын күзләре йомылган боларның. Тегүче яңадан уенын дәвам иттергән, кесәсеннән иң зур ташны сайлап алган да, селтәнеп, беренче пәһлеванның күкрәгенә тондырган.

Беренче пәһлеван корт чаккандай сикереп торган. Иптәшен бар куәтенә агачка китереп орган, ди. Икенчесе дә җавапсыз калмаган. Алар шулай икесе дә бик каты сугышканнар. Юан-юан агачларны төбе-тамырлары белән суырып алалар да бер-берсен дөмбәслиләр икән. Икесе тиң җансыз калып җиргә тәгәрәгәнче сугышканнар пәһлеваннар. Шуннан соң гына тегүче куначасыннан җиргә сикереп төшкән. Үзенә үзе: бәхетем бар икән әле, мин утырган агачны йолкып алсалар, тиен кебек, агачтан агачка сикереп сыпыртырга туры килгән булыр иде. Аннары кылычын алган да бу бер-бер артлы пәһлеваннарның күкрәкләренә кадаган. Шуннан соң гына урманнан чыккан, үзен көтеп торучы гаскәргә:

— Корольнең боерыгы үтәлде, икесен дә дөмектердем. Үземә дә җиңел булмады булуын. Агачлар йолкып алып, шулар белән каршы тормакчылар иде, эшләре пешмәде. Бер сугуда җидәүне егучыга кем каршы тора алсын, ди, инде!

— Яраландыңмы соң? — дип кызыксынган гаскәр.

Тегүче:

— Барысы да тәртиптә, чәч бөртегемә дә кагыла алмадылар,— дип җавап биргән.

Озатучы атлылар, сөйләгәннәре чынмы икән моның дип, урман эченә кереп киткәннәр. Андагы хәлләрне күргәч хәйран калганнар. Пәһлеваннар, чыннан да, җирдә тәгәрәп ята, тирә-якта төбе-тамыры белән йолкынган агачлар ауный, ди.

Сарайга кайтып җиткәч, корольдән вәгъдәсен[1] үтәвен таләп итә икән тегүче. Король исә, ашыгып, вәгъдә бирүенә үкенә башлаган. Баһадирдан котылу өчен, яңа хәйлә эзләргә керешкән.

— Кызымны, ярты мәмләкәтемне алыр өчен, тагын бер батырлык эшләргә кирәк. Урманыбызда сыңар мөгезле коточкыч бер җанвар яши. Ул безгә ел саен бик күп бәла-каза китерә. Менә шуны, тотып, читлеккә ябарга кирәк,— дигән король. Тегүче күзен дә йоммый:

— Ике пәһлеваннан курыкмаганны, бер кыргый җанвардан куркаммы соң? — дигән.

Тегүче эшне озакка сузмаган, дилбегә белән балта алган да урманга кереп киткән. Гаскәренә бу юлы да урман кырыенда көтеп торырга кушкан. Озак эзләргә туры килмәгән. Явыз мөгезборын үзе аның каршысына килеп чыккан. Килеп тә чыккан, куркыныч мөгезе белән өстенә дә ташланган моның. Ашыкма, ашыкма, ашыккан ашка пешкән, дигән тегүче. Туктап, мөгезборынның якынрак килгәнен көтә башлаган. Җанвар мөгезе белән чәнчим дигәндә генә, тегүче тиз арада агач артына

---

[1] **Вәгъдә** — биргән сүзен үтим дип ант итү.

качкан. Мөгезборын исә җан-фәрман чабып килгән уңайга очлы мөгезен төбенә кадәр агачка батырган.

Батыруын батырган, тик мөгезен суырып алырга көче җитмәгән.

—Килеп каптыңмы, аңгыра малкай? — дип, тегүче җанварның муенына муенчак бәйләгән. Аннары балтасын алып, агачка кадалган мөгезне кисеп ташлаган. Шуннан соң юашланган хайванны җитәкләп, сарайга алып кайтып киткән.

Ләкин король бу юлы да биргән вәгъдәсен үтәргә ашыкмаган, моңарга өченче йомыш кушкан.

—Урманда бер бик явыз кабан дуңгызы бар, шул мур кыргыры дөньяның астын-өскә китереп, туздырып йөри. Туйга хәтле менә шуны тотып кайт. Кирәк дисәң, ярдәмгә иң оста аучыларны сайлап ал,— дигән.

—Шул да булдымы эш, бу бит минем өчен балачага уены гына,— дигән тегүче.

Ярдәмгә бирелгән кешеләрдән дә баш тарткан. Аучылар моңа сөенгән генә.

Кабан дуңгызы тегүчене күреп алган. Үткен тешләрен ыржайтып, өстенә ыргылган. Якында гына бер абзар бар икән. Җитез тегүче куян тизлеге белән шунда элдерткән. Кабан дуңгызы аның артыннан чапкан. Ул арада тегүче тәрәзә аша тышка сикергән. Абзарны урап чыгып, ишеген тыштан ябып та куйган. Шулай итеп, кеше өркетеп йөргән явыз җан үзе кулга төшкән, юан корсагы аңа тәрәзә аша сикереп чыгарга ирек бирмәгән.

Шуннан соң гына тегүче, кулга эләккән ул кыргый хайванны үз күзләре белән күрсеннәр өчен, аучыларны чакырып китергән.

Корольгә вәгъдәсен үтәргә туры килгән. Кызы белән ярты мәмләкәтен тегүчегә биргән. Әгәр король үзе алдында гап-гади бер тегүче басып торуын белсә, җен ачулары чыккан булыр иде, билгеле.

Король өчен әллә ни шатлыгы булмаса да, утыз көн уен, кырык көн туен иткәннәр. Билгесез бер тегүче менә шулай король кияве булып киткән.

Атна үткән, ай үткән, ел үткән. Шулай берзаман король кызы иренең йокы аралаш: «Әй син, шул курт-каны тек. Менә бу чалбарны җөйләп бир. Юкса аршын таягы белән аркаңны каезлыйм хәзер»,— дип сөйләнүен ишеткән. Шунда ук иренең кем булуын аңлап алган.

Иртәгесен кыз әтисенә, гади тегүче хатыны булу миңа хурлык, дигән. Король, кызын юатырга тырышып:

— Бүген төнлә йокы бүлмәгезнең ишеген бикләми калдыр, күрше якта ышанычлы хезмәтчеләрем торыр. Алар ирең йокыга киткәч, аяк-кулларын бәйләп, корабка илтерләр. Кораб алдакчыны җәһәннәм артына ук олактырыр,— дигән.

Кыз моңа шатланып риза булган. Әмма ата кешенең сүзләрен тегүченең корал йөртүчесе ишетеп калган. Тегеләрнең тозак коруларын вакытында килеп әйткән.

— Язмыштан узмыш юк, исән булсак, бу бәладән дә котылырбыз,— дигән тегүче.

Кич булгач, һәр көндәгечә хатыны белән йокларга яткан тегүче. Беравыктан хатыны, ирен йокыга киткәндер инде дип уйлап, урыныннан торган да йокы бүлмәсенең ишеген ачып куйган, аннары үзе яңадан түшәгенә килеп яткан. Шулчак юри генә йоклаганга сабышып яткан тегүче, шәрран ярып:

— Әй син, хәзер үк куртканы тегеп, менә бу чалбарны җөйләп бир әле. Юкса аршын таягы белән

аркаңны каезлыйм хәзер. Бер сугуда җидәүне дөмектергән, ике пәһлеванны үтергән, мөгезборынны кулга төшергән, ерткыч кабан дуңгызын абзарга тотып япкан баһадир мин! Бүлмә ишеге артында калтыранып торучы козгыннар гына өркетә алмас! — дип кычкыра башлаган.

Тегүченең бу сүзләрен ишеткән хезмәтчеләр бик нык курыкканнар. Уңны-сулны белми кача башлаганнар. Бу хәлдән соң инде берәү дә тегүчегә каршы чыгарга батырчылык итмәгән. Шулай итеп, ул король булып калган, гомере буе тәхеттә утырган.

Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар.
(Касыйм Фәсахов тәрҗемәсе.)

?! Әкият сюжетын сөйләргә әзерләнегез.

1. Әкияттәге вакыйгалар тәртибен күз алдына китерегез. Дәфтәрегезгә, «Кайнатма», «Батырлыгы...» дип, хәтерегездә калган вакыйгаларны бер-ике сүз белән генә языгыз.

2. Китабыгыздан карап, вакыйгаларны тагын бер кат күздән кичерегез. Онытылган вакыйгаларны өстәгез.

3. Тегүче сыйфатларына бәя бирегез.

4. Король дәрәҗәсенә җитү өчен, тегүчегә нинди сыйфаты ярдәм итә?

5. Король һәм аның вәзирләре ни өчен җиңеләләр?

ТЕЛӘНЧЕ ЯУЛЫГЫ.

Борын-борын заманда Кытай илендә бер бай яшәгән. Байларның барысы да усал, комсыз булалар. Ә бу бай Кытайдагы барлык байлардан да усалрак, комсызрак булган. Өстәвенә хатыны да үзе кебек комсыз, усал икән.

Менә шул кешеләр кол сатып алганнар. Билгеле инде, иң арзан кол эзләгәннәр. Ә иң арзаны иң ямьсез кыз икән. Усал байлар ямьсез кызны «маймыл» дип кенә йөрткәннәр. Өйдә гел бер үк фәрман яңгырап торган:

— Маймыл, җыештыр!

— Маймыл, алып кил!

— Маймыл, барып кайт!

— Маймыл, китер!

Көннәрнең берендә, хуҗалар кунакка киткәч, ишегалдына бер теләнче килгән. Ул, кулларын күккә сузып:

— Ачтан үләр хәлгә җиттем. Коткара күр, сеңлем, — дип ялварган.

Хезмәтче кыз ялвару тавышын ишеткән, теләнчене өйгә керткән. Кулына букчага салынган дөге тоттыргач:

— Мин бу дөгене мичкә яккан саламнан бөртекләп җыйдым. Алай да хуҗа белә-нитә калса, миңа да, сиңа да көн күрсәтмәячәк, — дигән.

Теләнче янчыкны тиз генә яшергән. Куен кесәсеннән чыгарып, кызга уч төбеннән аз гына зуррак яулык сузган. Рәхмәт әйтеп, башын игән һәм:

— Таң алдыннан көн дә шушы яулык белән битеңне сөрт, — дигән.

Ул арада хуҗалар кайтып кергән. Өйдә теләнчене күрү белән:

— Өйгә хәерче кертергә кем кушты сиңа, маймыл! Үзеңне дә, хәерчеңне дә имгәткәнче ярам хәзер! — дип акырган бай. Кыйнарга теләп, теләнчегә ташлануы булган, тегесе кинәт юкка чыккан. Бай саранлыгыннан һәм ачуыннан шартлый язган. Чөйдәге камчысын

алган да тотынган кызны кыйнарга. Хәлдән тайганчы тукмаган.

Мескен кыз таң алдыннан гына аңына килгән. Теләнче биргән яулыкны исенә төшереп, битен сөрткән.

Өч көн рәттән шул яулык белән битен сөрткән хезмәтче кыз. Дүртенче көнне көзгесе каршына басып карау белән кычкырып җибәргән: көзгедән аңа күзнең явын алырлык чибәр кыз карап тора икән. Ал яулык үз эшен эшләгән, могҗиза ясаган: ямьсез кызны чибәрләрнең чибәре иткән.

Колларын күргәч, хуҗа да, хатыны да көнләшүдән шартлый язганнар.

— Сереңне ач, шунда ук ирек бирәчәкбез,— дигән хәйләкәр бай.

Шул сүзләрне ишеткәч, кол кызның йөрәге ничек типкәнен белсәгез иде! Ирек алу өчен, ул ни сорасалар, шуны бирергә әзер булган бит. Кыз явыз хуҗаларына ал яулыгын сузган. Яулык белән кайчан файдаланырга кирәклеген өйрәткән.

Байларга шул гына кирәк булган да. Алар кол кызны аш бүлмәсенә кертеп япканнар, качмасын өчен, этләрен сакка куйганнар.

Таң алдыннан, байлар битләрен ал яулык белән сөрткәннәр дә ятып йоклаганнар. Күзләрен кояш чыгып шактый күтәрелгәч кенә ачканнар. Шатлана-шатлана көзге янына килсәләр, аларга ике шыксыз маймыл карап тора!

Ирле-хатынлы байлар аш бүлмәсенә чапканнар. Ләкин маймылларны күрү белән, сактагы этләр, тешләрен ырҗайтып, өсләренә ташланганнар. Хуҗалар этләреннән куркып, тәрәзәдән чыгып качканнар, биек

коймалар аша ничек сикереп чыкканнарын үзләре дә сизми калганнар. Шуннан соң урамдагы этләргә чират җиткән. Менә алар, өерләре белән өрә-өрә, маймыллар артыннан чабарга тотынганнар. Эт өргән тавыш күптән тынса да, байлар алларына-артларына карамыйча чапканнар да чапканнар. Үлемнән шулай гына котылганнар.

Ниһаять, аңнарына килеп күзләрен ачып карасалар, үзләрен кара урман эчендә башка маймыллар арасында күргәннәр.

?! 1. «Теләнче яулыгы» әкиятендә автор уйлап тапкан могҗиза турында сөйләгез.

2. Хуҗалар язмышын белдек. Алар яман эшләре өчен җәза алдылар. Инде кол кыз язмышын беләсе калды. Әкиятне үзегез ничек телисез, шулай тәмамлагыз.

Үткән дәресләрдә өйрәнгәннәрне искә төшерү.

СУ ШИГЪРИЯТЕ.

Язгы матур көн. Казанка буендагы Фукс бакчасына барып чыктым. Яр астында әйләндереп капланган көймәләр сузылып ята.

Бакчада кар эри. Бер җирдә чылтыр-чылтыр кар суы киндерә[1] генә юанлыгы булып сикеренгәләп ага... Миңа ул ни өчендер сабый баланы хәтерләтте. Яңа гына тәпи йөри башлаган баланы... Шундый ук сөйкемле, шундый ук гөнаһсыз, саф. Җан иясе шикелле, койма кырыена ялт кына сикерә дә яр битендәге эреп бетмәгән кар астына кереп күздән югала. Әлегә ул бик көчсез, бик зәгыйфь.

Елгага барып төшкәч, ул инде күпердәй бозларны мәтәлдереп агызыр. Ә диңгезгә барып җиткәннән соң, биш катлы шәһәр йортларына охшашлы корабларны үз сыртында чөеп-чөеп йөртер...

...Бер карыйсың — сабый әле анасының күлмәк итәгенә ябышып йөри, икенче карыйсың — ул инде ярты дөньяны үз җилкәсенә алган.

Ибраһим Гази.

[1] Киндерә — ишелгән нечкә бау.

?! **1.** Әсәрне укыганда, агым су сыйфатларын хәтерегездә калдырырга тырышыгыз. Китабыгызны ябыгыз да агым су сыйфатларын дәфтәрләрегезгә кыска гына итеп языгыз.

2. Әсәрнең ике өлешен табыгыз. Аларга исемнәр бирегез.

3. Өлешләр арасындагы бәйләнешне табыгыз.

КОЯШ.

Көнбагышымның
нәни төшләрен
учыма җыйдым,—
әллә нишләдем.

Минем бакчамда
кояш бар иде,
инде ул батты,
инде ул сүнде.

Төшләрне күрше
малайга бирдем,
юлда очраган
бабайга бирдем.

Кызыл бантиклы
кызчыкка бирдем,
урамнан барган
карчыкка бирдем.

Барсы да миңа
рәхмәт диделәр,
җәйге кояштай
карап көлделәр.

Күрәсең, һәр төш
нур белән тулган,
ә баткан кояш
учымда булган.

Камил Мостафин.

?! Шигырьне хикәя итеп языгыз. Андагы вакыйганы үзгәртергә тырышыгыз.

ӨТЕР.

— Матур-матур җөмләләрнең
Ник мәгънәсен җуярга?
Кирәк сине өйрәтергә
Кайда өтер куярга:

Яр буендагы чишмәдән
Ике чиләк су китер,—
өтер;
Әнә теге тиресләрне
Бакчага чәчеп бетер,—
өтер;
Себеркене саплап куй да
Ишегалдын ялт иттер,—
өтер;
Шул эшләрне эшләп бетер
Бүген, мин өйдә юкта,—
нокта.

Данис Хәбибуллин.

?! Этисе улын нәрсәгә өйрәтә?

ҖИҢЕЛ АЯКЛЫ АПА.

Әбиемнең бер сүзе бар
Әлеге дә баягы:
«Юл уң була күрше апаң
Күрсәм — җиңел аягы».
Нигә җиңел?
Күргәнем юк
Яланаяк йөргәнен.
Җәй дә, кыш та,
Яз да, көз дә
Кия кеше кигәнен.

Күп күзәтә торгач, тәмам
Сәбәбен белдем бугай...

Эльмира Шәрифуллина.

?! **1.** Лирик герой тапкан сәбәпне дәфтәрләрегезгә языгыз.

2. Беренче строфада әби оныгына нәрсә ди? Үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

БЕР КҮЗЛЕ КЕШЕЛӘР ИЛЕ.

Берәү баю турында хыялланган, ә үзе эшләргә яратмаган. Эшләмичә генә акча ала торган эш эзләгән. Ләкин, күпме эзләсә дә, мәшәкате аз, акчасы күп булган эш таба алмаган. Ә беркөнне базарда кызыклы хәбәр ишеткән: бик ерактагы ниндидер утрауда бер генә күзле кешеләр яшиләр, имеш.

«Шул бер күзлеләрне тотасы иде. Халыкка күрсәтеп, акча җыясы иде. Тамашага килүчеләрнең һәркайсы берәр генә тәңкә бирсәләр дә баер идем»,— дип уйлаган ялкау кеше һәм, көймәгә утырып, сыңар күзле кешеләр утравын эзләргә чыгып киткән.

Ай йөзгән, ел йөзгән, бер билгесез утрау күргән.

Ярга чыгып, ике-өч адым атларга да өлгермәгән, каршына бер күзле кеше килеп чыккан...

«Бу хәшәрәтне, алдап-йолдап, көймәгә утыртырга кирәк»,— дип уйлаган сәяхәтчебез.

Ул арада сыңар күзле:

— Монда килегез! Тизрәк килегез! Безгә диңгездән ике күзле хәшәрәт йөзеп килде! — дип кычкырган.

?! **1.** Хикәянең беренче өлешен үз сүзләрегез белән сөйләп чыгыгыз. Аннан соң кыскартып сөйләгез.

2. Хикәянең икенче өлешендәге вакыйга — беренчесенең капма-каршысы. Икенче өлешен язып бетерегез.

ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК.

(Әсәрдән өзек.)

Минем Олы инәемне «кендек әбисе», ә үземне «кендек бабасы» дип йөртәләр. Мин бәләкәймен әле. Олы инәемнең камзул кесәсенә буем чак-чак җитә. Ул тылсымлы кесәдән тәмле-томлы нәрсәләр һичвакытта да өзелми. Йә берәр шакмак шикәр, йә дүрт-биш бөртек йөзем җимеше, йә прәннек валчыгы, йә кипкән шомырт, йә куырылган борчак була. Хәтта ара-тирә бакыр тәңкәләр дә чылтырап куя. (Без акчаның кодрәтен күптән беләбез!) Бер хәзинә инде ул кесә — бетмәс-төкәнмәс хәзинә.

Әле дә кулымны тыгуым булды — зур гына ике өрек учыма килеп тә эләкте... Бездә тәмле нәрсәне берьюлы гына комсызланып ашый торган гадәт юк. Без аны рәхәтләнеп суырып кына йөрибез. Икенче өрекне бүген генә киеп чыккан яңа чалбарымның кесәсенә яшердем. Анысын, кайткач, сеңлем белән энемә бүлеп бирермен. Бәлки, шуннан башлап минем чалбарымның да кесәсе тылсымлыга әйләнер. «Юмарт кулга мал керер», — ди Олы инәем.

Мостай Кәрим.

?! Автор үзенең бик кечкенә чагын да хәтерли. Сез һаман исегезгә төшеп тора торган берәр вакыйга хәтерләмисезме? Шул вакыйганы языгыз. Вакыйгада катнашучыларны искә алырга онытмагыз.

Әйдәгез, өйдә укыйбыз!

КЫЙНА, ӘТӘЧ.

Элек заманда бер авылда ике ир туган яшәгән, ди. Бер елны болар күлнең аръягына борчак чәчкәннәр, ди. Яңгырлар явып торганга, борчаклары бик уңган. Менә беркөнне туганнарның өлкәне борчак карарга барса — кемдер борчак кузакларын ярып ашаган. Кайтып, бу хәлне абыйсына сөйләгән. Абыйсы иртүк барып, нәрсә килер икән, дип саклап яткан. Шактый вакыт үткәч, алтын кош төшеп борчакны ашый башлаган. Егет каракны, теге сизмәгәндә генә, аягыннан каптырып алган. Алтын кош моңа:

— Син мине тотма, мин сиңа бер җәймә бирәм. Аңа «Җәел, җәймә!» дип әйтсәң, ул сиңа бик күп ашамлык бүләк итәр,— дигән. Егет кошны җибәргән дә җәймәне алып кайтып киткән.

Кайтканда бик тирләгән. Күлдә коенып чыгарга уйлаган. Күл буенда бер ялгыз карчыкка җәймәсен биреп:

— Син, әби, бу җәймәгә «Җәел, җәймә» дип әйтә күрмә, харап булырсың,— дигән. Әйткән дә үзе су керергә киткән. Әби, егет киткәч үк, җәймәгә: «Җәел, җәймә»,— дигән икән, өстендә бик күп ашамлыклар күреп шаккаткан. Бу җәймә урынына шуңа охшаган башка җәймә куйган. Егет шул җәймәне алып киткән.

Өенә кайткач, егет бик күп кунак җыйган. Өстәл уртасына җәймәсен куеп: «Җәел, җәймә»,— дигән.

Ләкин җәймә җәелмәгән. Кунаклар үпкәләп, каргый-каргый кайтып киткәннәр.

Икенче көнне егет борчакны сакларга энесен җибәргән. Теге алтын кош бу юлы да төшеп борчакны ашый башлаган. Егетнең энесе дә аны тиз генә тотып алган. Кош егеткә әйткән:

— Син мине тотма, мин сиңа алтын төкерә торган ат бирәм. «Алтын төкер, ат» дисәң, ул, «Тукта» дигәнче, алтын төкерә,— дигән.

Егетнең энесе кошны җибәргән дә су коенырга уйлаган. Ә әлеге әбигә әйткән:

— Әби, син бу атка «Алтын төкер, ат» дия күрмә, югыйсә тибеп үтерер,— дигән.

Әби бу юлы да атны башка атка алыштырып куйган.

Өенә кайткач, әлеге үпкәләткән кунакларын чакырып, алтын өләшергә булганнар. Ләкин кунаклар җыелгач, ат алтын төкермәгән. Кунаклар, «Инде башка килмибез» дип рәнҗеп, өйләренә кайтып киткәннәр.

Өченче таңда өлкән туган борчак җиренә тагын килгән. Бу юлы да алтын кошны тотып алган. Кош аңа, мине җибәрсәң, тылсымлы әтәч бирәм дип, әтәч бүләк иткән.

— Бу әтәчкә «Кыйна, әтәч» дисәң, ул кемне күрсә, шуны кыйный, ләкин хуҗасына тими,— дигән. Егет, кошны җибәреп, әтәче белән теге әбигә кергән.

— Мин су коенып кайтканчы гына, әтәч синдә торсын әле, ләкин «Кыйна, әтәч» дия күрмә,— дигән.

Егет чыгып китү белән, әби әтәчкә «Кыйна, әтәч» дип әйтергә дә өлгермәгән, әтәч, кирәкме-кирәк, тукмарга керешкән. Егет су коенып кайтканчы кыйнаган. Әбинең ике кулын бер аягын сындырган. Егет әбигә:

— Син, шулай итеп, җәймә белән атны да алып

калгансың икән. Китер ат белән җәймәне! Бирмәсәң, этәчтән үтертәм,— дигән.

Егет әби күрсәткән урыннан ат белән җәймәне алып, этәчне ияртеп кайткач, энесенә ниләр булганын сөйләгән.

?! Әкият, «Карак карчык һәм аңа җәза» дип, ике өлешкә бүленә. Ләкин әкияттә өч вакыйга бар: берсе — җәймә, икенчесе — ат, ә өченчесе этәч турында. Ни өчен әкиятне ике генә өлешкә бүлдек?

ЙОЛДЫЗКАЙ.

Нәсимә аны юкка гына «Йолдызкаем» дип йөртми шул. Песинең йоннары чем-кара. Ә маңгаенда — нәкъ ике колак уртасында — ап-ак табы бар. Йолдыз кебек янып тора. Көндезләрен алар бергә-бергә чабышып уйныйлар. Кич булу белән, Нәсимә йомшак кына көйли башлый. Әйтерсең ул шулай ягымлы җыры белән дустын йоклата.

Җәйге көннәрнең берсе иде. Нәсимәнең әнисе, май язам дип, баздан сөт өсте алып чыкты. Аны гөбегә[1] салды да, көянтә-чиләкләрен күтәреп, чишмәгә суга китте.

Ә песинең гөбе яныннан һич кенә дә китәсе килми бит. Койрыгын югары күтәргән, ә үзе Нәсимәдән күзен алмый.

— Мияу! Мияу! Каймак исен сизәм! Ми-яу! — дип, сузуын гына белә.

— Әни кайтканын көтмисеңмени? Ярар, алайса, әз генә алып бирим әле, — дип, кызчык, кашык алып, гөбедәге каймакка тыгылды.

---

[1] Гөбе — май язу өчен кулланыла торган тар, тирән кисмәк.

Гөбе биегрәк шул. Нәсимәнең иягенә җитә... Кыз үрелеп-үрелеп карады да, ала алмагач, гөбе янына бүкән тәгәрәтеп китерде. Бүкәнгә басты. Кашыгы белән гөбегә тыгылган иде, бүкән ауды да тәгәрәп китте. Нәсимә егылды, гөбене дә аударды.

Менә көтелмәгән бәла! Инде нишләргә? Нәсимә куркуыннан тезләре авыртканын да онытып җибәрде. Тиз генә гөбесен утыртты. Аннары идәндә җәелеп яткан каймакны, учлары белән җыеп, савытка тутыра башлады.

Ул тутыра, песи лач-лоч итеп ялый, рәхәтләнде песи каймакка!

Кинәт ишек ачылып китте. Әнисе кайтып керде.

— Аһ! Әдәпсез бала! Харап иткәнсең икән! — диде.

Нәсимә әнисенең болай тиз генә кайтуын көтмәгән иде. Каушавыннан:

— Мин түгел! Песи бит! — дип әйтүен сизми дә калды.

— Зуп-зур гөбене мәче аударамы соң? — диде әнисе, ачуланып. Чыбык алды да:

— Кит әле, каймакны пычратма! — дип, песигә берне селтәде. Песи ачык ишектән атылып чыгып китте. Кызга бары тик кырын күзен генә салды ул. Нинди зур үпкәле караш иде бу! Нәсимәнең йөрәге сыкранып китте.

Дәрҗия Аппакова.

?! Кыз ярамаган эш эшләде: үз гаебен якын дустына — песиенә аударды. Хикәянең беренче өлеше шундый. Бу өлеш сәбәп булса, нәтиҗәсен аңлатыгыз.

НИЧӘ ЧЫПЧЫК?

Укытучы балаларга шундый сорау биргән:

— Өй түбәсендә өч чыпчык утыра иде, шуларның берсен аучы атып төшерде. Түбәдә ничә чыпчык калды?

— Берсе дә калмады, — мылтык тавышына түбәдәге чыпчыклар бар да очып китә ич, — дип җавап бирәннәр укучылар.

?! Балалар ялгышкан булсалар, ничек дип җавап бирерләр иде?

ӨЧ БАССЕЙН.

Ике малай сөйләшә:

— Бездә өч бассейн төзеделәр: берсе салкын сулы, икенчесе җылы сулы, өченчесе бөтенләй сусыз.

— Ә сусызы ни өчен?

— Йөзә белмәүчеләр өчен.

?! Төзүчеләр хаклы да, хаксыз да. Шуны исбат итегез.

ИКЕ КЫЗ.

Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Аларның ике кызлары булган. Олы кызлары усал да, ялкау да, саран да икән. Шуның өчен аны беркем дә яратмаган. Кече кыз үги булган. Аның уңганлыгына кешеләр сокланып туя алмаганнар. Үги ананың моңа бик тә эче поша икән.

Көннәрдән бер көнне карчык иренә әйткән:

— Урманга алып барып адаштыр ул кызыңны! — дигән.

Карт, ат җигеп, кызын урманга алып киткән. Барып җиткәч:

— Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин бераз утын әзерлим,— дигән. Кыз, җырлый-җырлый, җиләк җыярга керешкән.

Җиләк җыям, как коям,
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән?

Җыйган-җыйган да кыз, тырысы тулгач, әлеге урынга килсә, әтисе юк, ди. Кычкырып та караган, елап та караган, әтисе юк та юк. Ары сугылып, бире сугылып йөри торгач, бик арыган, бик талчыккан кыз һәм бер каен төбенә тамак ялгарга утырган. Үги анасы биреп җибәргән бер телем ипине чыгарып ашыйм гына дисә, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Куян. Кыз аңа ипиен бүлеп биргән. Куян ипи сыныгын тәмләп кенә ашап куйган да: «Яхшылыкка — яхшылык»,— дип, аңа куян бүреге китереп биргән.

Куян киткәч, ипиен ашыйм гына дисә, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Төлке.

Кыз аңа да ипиен бүлеп биргән. Төлке ипи сыныгын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык»,— дип, аңа төлке туны китереп биргән.

Төлке киткәч, ипиен ашыйм гына дисә, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Бүре.

Кыз аңа да ипиен бүлеп биргән. Бүре ипи сыныгын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык»,— дип, кызга бүре туны китереп биргән.

Бүре киткәч, ипиен ашыйм гына дисә, Аю килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Аю.

Кыз аңа да ипиен бүлеп биргән. Аю ипи сыныгын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык»,— дип, бер тәпән бал китереп биргән.

Аю киткәч, ипиен ашыйм гына дисә, көтүче килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән көтүче.

Кыз аңа да ипиен бүлеп биргән. Көтүче ипи кисәген тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык»,— дип, бер көтү мал куып китергән.

Көтүче киткәч, калган ипи валчыкларын кабып җибәрим генә дисә, моның иңбашына Сандугач килеп кунган.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Сандугач.

Кыз учыннан аңа калган ипи валчыкларын чүпләткән. Сандугач тәмләп кенә ипи валчыкларын чүпләп бетергән дә: «Яхшылыкка — яхшылык, нинди теләгең бар, түтекәй, хәзер үтим»,— дигән.

Кыз әйткән: «Минем өйгә кайтасым килә, әтиемә генә барып хәбәр салчы, Сандугачым»,— дигән.

Кош очып киткән. Ул авылга җитеп, аларның өй каршындагы агачка кунып:

Чут, чут, чут,
Түтәйнең маллары күп,
Килеп алучы юк, юк,—

дип сайрарга тотынган. Әтисе моны ишеткән һәм, атын җигеп, урманга киткән. Кызның бөтен байлыкларын төяп, көтүләрне куып алып кайтканнар. Үги ана, моны күреп, ачуыннан нишләргә белми, ди. «Үз кызыңны баеттың, инде минем кызымны да бает, урманга алып барып адаштыр!» — дип, картына бәйләнә икән.

Карт, ат җигеп, бу кызны да урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин бераз утын әзерлим»,— дигән. Кыз җиләк җыярга тотынган. Бер җиләкне савытка, өч җиләкне авызга салып йөри-йөри, тырыс төбе капланган, әлеге урынга килсә, әтисе юк, ди. «Әйдә, ярар, монда гынадыр әле, мине ташлап әллә кая китә алмас, югыйсә әни аның кирәген бирер»,— дип уйлаган кыз һәм каен төбенә ашарга утырган. Әнисе җибәргән төргәкне чишеп, нигъмәтләрне җәеп куюы булган, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Куян.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм таяк белән башына суккан. Куян, ачу итеп, кызның күлмәген ертып, җиләген түгеп киткән.

«Их, котылдым бу арык Куяннан!» — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй,—

дигән Төлке.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм Төлкенең башына таяк белән суккан. Төлке, ачу итеп, кызның яулыгын ертып, тырысын тетеп киткән.

— Их, котылдым бу ач Төлкедән! — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Бүре.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм Бүренең башына таяк белән суккан. Бүренең моңа бик ачуы килгән һәм кызны кабып йоткан, ди.

Бу вакытта карт өйдә икән. Карчыгы: «Бар инде, кызым баегандыр, тизрәк алып кайт!» — дип әрләшә, ди. Карт, атын җигеп, урманга барса, кызы юк, тетелгән тырысы гына урманда аунап ята, ди. Карт шуны арбасына салып кайтып киткән. Ишегалдына кергәч, карчы-

гы йөгереп чыккан. Арбада кызының тетелгән тырысын күргән һәм хурлыгыннан егылып үлгән, ди.

Ә үги кыз әле дә булса матур гына гомер итә, ди.

?! Әкияттә вакыйгалар бик күп. Ләкин ул барыбер ике өлешкә генә бүленә. Әкиятне ике өлешкә бүлегез.

ӨЧ БӨРТЕК АЛТЫН ЧӘЧ

Бер хатынның улы туган. Күп тә үтми күктән хәбәр килгән, кемдер, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп: «Бәхетле бала тапкансың. Ул гел уңышка гына ирешеп торачак. Ә ундүрт яше тулгач, король кызына өйләнәчәк»,— дигән.

Бераздан болар яшәгән авылга король килеп чыккан. Аның король булуын берәү дә белмәгән. Шуңа күрә ул: «Авылыгызда яңалыклар юкмы?» — дип сорагач, аңа яңа туган баланың король кызын алырга тиешлеген әйткәннәр.

Король усал кеше булган. Бәхетле бала турындагы хәбәргә ачуы килгән. Әти-әнисенә күп акча биреп, малайны сатып алган. Әти-әнисенең улларын бер дә бирәселәре килмәсә дә, ул бит бәхетле бала, король сараенда яшәсә, бәхете тагын да арта төшәр, дип уйлаганнар.

Король малайны тартмага салып кайтырга чыккан. Юлда тартманы елгадагы упкынга ыргыткан, кирәкмәгән кияүдән котылдым, дип шатланган. Ләкин тартма батмаган. Ага-ага, тегермән буасына килеп терәлгән. Аны тегермәндә эшләүче кеше күреп алган һәм ыргак белән тартып чыгарган. Тартманы ачып карагач, анда тап-таза, матур малай ятканын күргән. Малайны тегермән хуҗасына күрсәткән. Тегермәнче хатыны

бик шатланган. Балабыз юк иде, Ходай безгә бүләк җибәргән, дигән.

Ундүрт ел үткән. Малай матур егет булып үскән.

Ә беркөнне, яңгырдан ышык эзләп, болар өенә король килеп кергән. Җиткән матур малайны күреп: «Үз улыгызмы?» — дип сораган.

Тегермәнче хатыны судан агып килгән тартма турында да, хезмәтченең аны багор[1] белән тартып чыгаруы турында да сөйләп биргән.

Король егетнең кемлеген белгән.

— Рөхсәт итсәгез, улыгызны хатынга хат илтергә җибәрер идем, — дип сораган. Тегермәнче белән хатыны шатланып риза булганнар.

Король хатында: «Бу малайны мин кайтканчы үтереп күмегез», — дип язган.

Малай юлга чыккан. Урман эченнән бара-бара, төн җиткән. Караңгыда юлын югалтып адашкан. Бик озак йөргәннән соң, еракта ут җемелдәвен күргән. Утка таба киткән. Кечкенә генә өй янына килеп чыккан. Өй эчендә бер карчык утыра икән. Сораштыра торгач, әби кунагының тегермәнче улы булуын һәм король хатынына хат илтергә баруын белгән.

— И мескен бала, син юлбасарлар оясына килеп чыккансың. Кайткач, алар сине үтерәчәкләр бит, — дип кызганган карчык.

— Бармак селкетерлек тә хәлем калмады. Арыдым, әби. Шуңа күрә берәүдән дә курыкмыйм, — дигән егет һәм йокыга киткән.

Бераздан юлбасарлар кайтканнар. Кунак егетен өйләренә керткән өчен, карчыкны ачуланганнар. Ләкин

---

[1] Багор — озын сапка беркетелгән тимер ыргак.

карчык егетне яклап калган. Юлбасарлар егет илтә торган хатны укыганнар. Андагы язу белән танышкач, мәкерле корольгә ачулары килгән. Король язган хатны боларның атаманнары ертып ташлаган да аның урынына башка хат язган. Хатында: «Кызыбызны хат китерүче егеткә кияүгә бир. Минем кайтканны көтеп тормагыз, туй ясагыз»,— дигән һәм король булып кул куйган. Ә егет уянгач, аңа король булып язган хатларын тоттырганнар да юл күрсәтеп, озатып калганнар.

Король хатыны хатта язылганча эшләгән. Кызын хат китерүчегә кияүгә биргән. Туй ясаган.

Күпмедер вакыт үткәч, король кайтып төшкән. Киявенең хат китерүче егет булуын белгәч шаккаткан. Хатынын орышкан. Ләкин хатыны «Менә бит үзең язган хат» дип күрсәткәч кенә, кемдер аның хатын алыштырганын белгән. Хәзер ул егеттән котылуның башка юлын уйлап тапкан.

—Король кияве буласың килсә, егет, хезмәт ит: тәмугка[1] төшеп, шайтанның өч алтын чәчен алып кайт,— дигән.

Юл егетне ниндидер илнең башкаласына китергән. Капка сакчысы кем булуын белешкән.

— Нинди һөнәрең бар? — дип сораган.

— Мин белмәгән эш юк,— дип җавап биргән егет.

— Алайса, безгә бер файдалы эш эшлә әле. Базар каршындагы фонтаннан моңа кадәр шәраб ага иде. Хәзер корыды, хәтта су да акмый башлады. Сәбәбе нидә? Шуны әйт әле,— дигән капка каравылчысы.

— Кайтышлый аңлатырмын. Көтегез,— дигән егет һәм юлын дәвам иткән. Бара торгач, башка бер шә-

---

[1] Тәмуг — яман кешеләргә җәза бирә торган урын.

һәргә килеп чыккан. Мондагы капка сакчысы да:

— Нинди һөнәрең бар? — дип сораган.

— Мин белмәгән эш юк, — дип җавап биргән егет.

— Алайса, безгә бер яхшы эш эшлә әле. Безнең алмагачларда элек алтын алма үсә иде. Быел хәтта яфраклары да юк. Сәбәбе нидә? Шуны әйт әле, — дигән.

— Кайтышлый аңлатырмын, — дигән егет һәм юлын дәвам иткән.

Бара торгач, киң генә елгага килеп чыккан. Көймәчедән аргы якка чыгаруын сораган. Көймәче дә: «Нинди һөнәрең бар?» — дип сораган. Аннан соң:

— Ни өчен мин гомер буе көймәче булып эшләргә тиеш. Нигә мине берәү дә алыштырмый? Шул сорауга җавап бирсәң иде, — дип үтенгән.

Егет бу юлы да: «Кайтышлый ярдәм итәрмен», — дип сүз биргән.

Елганың аргы ягына чыккач, егет, тәмуг ишеген табып, эчкә кергән. Анда күзгә төртсәң күренмәслек караңгы икән. Өстәвенә барлык стеналарына төтен исе сеңгән булган. Шайтан өендә бер карчык кына утыра икән. Ни өчен килгәнен сорап белгәч:

— Шайтан кайтып керсә, башың бетәчәк бит. Әйдә, энем, яшерим үзеңне. Бәлки, күрмәс, — дигән. Егетне кырмыскага әйләндергән дә күлмәк җөенә кыстырып куйган.

Егет ул арада карчыкка монда шайтанның өч алтын чәч бөртеге өчен һәм өч сорауга җавап табарга килүен әйткән.

— Сораударың бик кыен икән. Алай да мин шайтан чәчен йолкыганда, ул әйткән сүзләрне хәтереңдә калдырырга тырыш, — дигән карчык.

Кич җиткәч, шайтан кайткан. Ишекне ачып керү белән, өйдә кеше исе барлыгын сизеп алган. Өенең астын өскә китереп эзләгән — таба алмаган.

Ашаганнан соң, карчык тезенә башын куеп йокларга яткан. Башыннан бет эзләргә кушкан. Хырылдавын ишетүгә, карчык шайтан башыннан бер чәчен йолкып алган.

— Әй! Нишлисең? — дип уянган шайтан.

— Яман төш күрдем. Шуңа күрә, куркып, чәчеңә ябыштым,— дигән карчык һәм төшен сөйләгән.— Базар янындагы фонтаннан элек шәраб аккан. Хәзер су да акмый, имеш. Фонтан нигә кипкән? Белмисеңме?

—Таш астында бер бака ята. Шул баканы, тотып, таш астыннан чыгарсалар — шәраблары кабат ага башлаячак,— дигән шайтан һәм хырлап йокыга киткән.

Әби аның тагын бер чәчен йолкып алган.

—Уф! Нишлисең? — дип сискәнеп уянган шайтан.

—Ачуың килмәсен. Йокы аралаш чәчеңә тотынганмын. Бу юлы да төш күрдем,— дигән карчык һәм төшен сөйләгән: — Бер патшалыкта алмагачлар алтын алма үстергән булганнар. Ә хәзер аларның яфракларына кадәр коелып беткән. Шуның сәбәбен белмисеңме? — дигән.

—Алмагач тамырларын тычканнар кимерә. Шул тычканнарны тотып үтерсәләр, алмагачлары тагын алтын алмалар үстерә башлар,— дигән шайтан.

Өченче чәч бөртеген йолкыганнан соң, ачуланып уянган шайтанга карчык тагын бер төшен сөйләгән.

—Төшемдә бер көймәче күрдем. Ул миңа: көймәче булып эшлим дә эшлим. Мине ни өчендер берәү дә алмаштырмый, дип зарланды. Шуның сәбәбе нидә?

— Ахмак ул синең көймәчең,— дигән шайтан.— Елганың аргы ягына чыгарган берәр кешегә: «Мә иш, арыдым»,— дип, ишкәген бирергә кирәк аңа. Шулай итсә, теге кеше көймәче булачак, ә бусы азат ителәчәк.

Икенче көнне иртән шайтан тагын кайдадыр чыгып киткәч, карчык, егетне уятып, өч бөртек алтын чәч тоттырган. Ә сорауларыңа җавапны үзең ишеттең, инде юлыңда бул, дигән.

Егет, рәхмәтләр әйтеп, юлы уңганга шатлана-шатлана, елга ярына килгән. Көймәчегә ишкәген башка берәү кулына тоттырырга кушкан. Алмагачлары корыган патшалыкта тамыр кимерүче тычканнарны үтерергә киңәш иткән. Бу яхшылыгы өчен капка сакчысы аңа ике ишәк бүләк иткән. Ә ишәкләргә алтын тутырылган капчыклар салынган булган.

Фонтаннары туктаган шәһәрдә ул: «Таш астындагы баканы алып ташлагыз, шуннан соң гомерегез буе фонтаннан шәраб эчәрсез»,— дигән. Матур киңәше өчен бу капка сакчысы да аңа ике ишәк йөге алтын бүләк иткән.

Ниһаять, бәхетле егет үз шәһәренә дә кайтып җиткән. Шайтанның алтын чәч бөртекләрен кулына алгач, король шаккаткән. Ә дүрт ишәк аркасындагы алтын капчыкларны күргәч, тәмам шашып калган.

— Бөтен шартымны да үтәдең. Кызым белән тату гына яшәгез. Инде бер соравыма җавап бир. Шушы кадәр байлыкны кайдан алдың? — дигән.

— Елга аша чыктым, ә аръякта алтын ком кебек чәчелеп ята. Шуны капчыкларга тутырдым да кайттым,— дигән егет.

— Ә мин барсам, мин дә капчыкларга алтын тутыра аламмы? — дип сораган король.

— Нигә тутырмаска, син дә тутыра аласың. Елгага җиткәч, көймәче күрерсең. Аръякка шул көймәче чыгарыр. Ә анда алтынның чуты юк. Күтәрә алган кадәр тутыр, — дип җавап биргән кияве.

Комсыз король шул көнне үк юлга чыккан. Елгага җиткәч, көймәче аны аръякка чыгарган. Көймә ярга барып төртелгәч, көймәче корольгә ишкәкләрен биргән дә, үзе сикереп төшкән.

Шул көннән алып король үзенең гөнаһлары өчен җәза алган. Көймәче булып хезмәт итәргә тиеш булган.

Ул хәзер дә елганың бер ягыннан икенче ягына кешеләр чыгара. Ничек чыгармасын? Аның кулыннан ишкәкләрен кем алсын, ди.

Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар.

?! Гадәттәгечә, «Әкият нәрсә турында?» соравына җавап эзлик. Әкият авторы бу юлы сорауга үзе җавап бирә: «Король гөнаһлы эшләре өчен җәза алган»,— ди. «Әкият тагын нәрсә турында?» — дип, икенче сорауны бирәбез.

Икенче сорауга җавап эзләгез.

РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ.

(Әсәр кыскартып бирелә.)

Бу озын хикәядә тасвир ителәчәк вакыйгаларның төп каһарманы Рөстәм Әсәдуллинга 1942 нче елның язында унөч яшь тә тулмаган иде әле. Аның кинәт югалуы әтисе Һашим абзыйны да, әнисе Гайшә апаны да тирән кайгыга төшерде.

Рөстәм, гадәттәгечә, иртә белән дәрескә китте һәм шул китүдән кайтмады...

Әйтергә генә ансат: күз алдында йөгереп йөргән бала суга чумгандай юкка чыксын, имеш.

Әби әкияте.

Моннан берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Рөстәмнең әбисе килде. Аның килүен Рөстәм түземсезләнеп көтте. Кадерле кунакның кайчан килергә җыенуын ишеткәч тә, Рөстәм календарьда билге ясап куйды һәм көн саен иртә белән:

— Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды! — дип әйтә торды.

Әби календарьда билгеләнгән вакыттан бер көн элек килде. Рөстәм моңа шатланды. Әби аңа ап-ак җылы оеклар, ап-ак җылы киез итекләр, куян тиресеннән тегелгән ап-ак бүрек, ап-ак бияләйләр һәм бик күп итеп чикләвек алып килгән иде.

Үткән елны ул бөтен җәйне аның белән бергә авылда уздырды. Ләкин ул чакта әби дә, Рөстәм үзе дә әллә ничек бер-берсен аңламыйлар, сөйләргә сүз тапмыйлар иде. Ә хәзер... хәзер бөтенләй башка... Рөстәм дәресләрен әзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә. Рөстәм башта әбинең җырлау рәвешен генә ярата иде, хәзер, ияләшкәч, аның көйләрен дә ярата. Моңлы итеп җырлый ул!

Шундый күңелле әбиеңне ничек яратмыйсың, ди. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Ә әкиятләре ни тора әбинең! Нинди матур сөйли ул аларны... Тыңлап туйгысыз! Андый әкиятләрне Рөстәмнең китапларда да укыганы юк әле.

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый Академия театрына спектакль карарга

киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калдылар. Шул кичне Рөстәм яңа әкият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озын итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге менә болай иде:

Абага — карап торырга гап-гади үсемлек. Исе дисәң — хуш исе юк, яфрагы дисәң — яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар. Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән. Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый, ди, менә шушы күп абагалардан сирәк очрый торганы яз көне, җиде төн уртасында, ике-өч секундка чәчәк ата, ди. Ул чәчәк атканда, яшен яшьни, күк күкри, җен-пәриләр чыга, кара урман яктыра, ди. Бу вакыт абага шундый матур була, ди, аның йолдызлардай атып торган чәчәкләреннән күзләр чагыла, ди, аннан таралган хуш истән башлар әйләнә, ди.

Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр, ди. Дөньяда тереклек булганнан бирле, тылсымлы абага чәчәген өзеп, кеше күзенә күренмичә йөрергә теләүчеләр бихисап күп булган, ди. Ләкин андый абаганы табуы кыен икән. Кайберәүләр, илдән илгә йөреп, бөтен гомерләрен әнә шундый абаганы эзләп уздырганнар.

Яз җиткәч.

Абага турындагы әкият Рөстәмнең холкын да, тормышын да бөтенләй үзгәртеп җибәрде. Әкият аңа шулкадәр нык тәэсир итте ки, ул гел шул хакта гына уйлап йөри башлады. Хәтта төшенә дә керә башлады ул. Абага чәчәге турында хыялланып йөри-йөри, Рөстәм

үзен фронтта, сугыш мәйданында итеп хис итте һәм язны көтте. Ул үзен үзе курыкмаска да өйрәтте. Өйдә япа-ялгыз калып, үзенчә күнегүләр ясады. Утларны сүндереп, сәгатьләр буе караңгыда утырды, төн уртасында ишегалдына чыгып торды.

Май уртасы иде. Рөстәм урманга китте. Эңгер-меңгер вакыты җитте. Ләкин Рөстәм кайтмады, үзенең курку-курыкмавын сынарга теләп, тәмам караңгы төшкәнче урманда йөрде һәм курыкса да, курыкмаска тырышып, бу беренче сынауны яхшы уздырды.

Абага чәчәге турында хыяллану Рөстәмне ялгызлыкка өйрәтте. Әмма дәресләренә зарар китермәде ул, элеккечә тырышып укыды, алдынгы укучылар рәтендә барды. Бары тик дус-ишләре белән генә сирәк очраша торган булды. Берәрсе урамга уйнарга чакырса, олыларча:

— Уйнаудамыни хәзер баш! Күрәсең ич сугыш... Муеннан эш. Юк, бара алмыйм,— дип җавап кайтара иде. Агачлар күптән яфрак ярдылар. Шәһәрдә кошлар сайравы ешайды. Ашыгырга кирәк! — диде Рөстәм үз-үзенә. Рөстәм төн уздырырга урманга китте.

Урманда.

Рөстәм башта, ни өчен килгәнен онытып, матурлыкка, сандугач сайравына хәйран калып, «һу-һу-һәй!» дип, урман яңгыратты. Гитлерчылар сугыш ачмасалар, кешеләр табигать кочагында, менә шушындый гүзәллек диңгезендә нихәтле ләззәтләнерләр иде... Сугыш шул.

Сугыш турында уйлау абага чәчәген хәтерләтте. Рөстәм агач ботагына букчасын элде һәм абагалар

эзли башлады. Ул бик күп абага тапты. Якында гына салкын чишмә бар иде. Рөстәм, шунда барып, туйганчы су эчте, сохари ашады һәм агач башына менеп утырды. Күзләре талганчы абагаларга карап утырды.

Сихерле чәчәкләр.

Урман акрынлап караңгылыкка чумды. Бу вакыт Рөстәм абагалар янында иде инде. Әбисе аңа абага җиде төн уртасында чәчәк ата дигән иде. Бу төнне Рөстәм йоклау түгел, күзләрен дә йоммады.

Шулай уйланып утырганда, каты итеп күк күкрәде. Яшен яшьнәп, кара урман аша яп-якты тасма сузылып үтте. Агач яфраклары һәм үсемлекләр ялтырап яна башладылар. Рөстәмнең күзләре дүрт булды! Ул берничә абагада нәфис бриллиант кашларыдай җем-җем итеп тора торган чәчәкләр күрде. Рөстәм бу тылсымлы чәчәкләрне ашыга-ашыга өзәргә тотынды. Ул аларны учлап-учлап авызына тутырды.

Шуннан соң нәрсә булганын Рөстәм хәтерләми. Аның башы әйләнде, ул, хәлдән таеп, җиргә егылды.

Кем сорый?

Рөстәм бер тәүлектән артык йоклады. Уяну белән, үзен җиңеләеп киткәндәй хис итте. Урманнан ничек чыкканын сизми дә калды.

Рөстәм трамвайлар туктала торган урынга килеп җиткән иде инде. Почмакта портфельле бер иптәш басып тора иде. Рөстәм аның янына килде һәм:

— Абый, сәгать ничә? — дип сорады.

Рөстәмнең соравы портфельле иптәшне сискәндереп җибәрде. Ул як-ягына борылып карады, күзләрен уды һәм сөйләнә-сөйләнә китеп барды.

Рөстәм шатлыгыннан нишләргә белмәде. Сикерәсе, биисе килде. Димәк, Рөстәм, чынлап та, күзгә күренмәс кеше булды. Ул өйгә кайтырга ашыкты. Ләкин өй эчтән бикле иде. Ишек дөбердәтте.

— Кем бар?

— Бу — мин... мәктәптән килгән идем... Рөстәм кайтмадымы? — Әби ишек ачты. Шул арада Рөстәм өйгә кереп китте.

— Ай Алла,— диде әби,— кай арада күздән югалды?..

Рөстәм шкаф тирәсендә актарына башлады. Туйганчы ашады. Су эчте.

Барлык радиолар, газеталар Ватан өстендә куркыныч шәүлә йөри дип кычкырып торалар. Күзгә күренмәс Рөстәм шушындый дәһшәтле көннәрдә Казанда яшәсенме?

Караңгы төшкән иде инде. Рөстәм, башын түбән иеп, авыр атлап, вокзалга таба юнәлде. Таң алдында кешеләрнең, чемоданнар күтәреп, вагоннарга сибелүләре аны да ашыктырды. Рөстәм, пассажирларга комачауламас өчен, кеше азрак йөргән тәрәзә янына килеп басты. Озакламый поезд кузгалды.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем...

Кыенлыклар аша.

Полк төн буе маршта булды. Озын юл кичәргә өйрәнмәгән Рөстәм генә түгел, аннан зурраклар да

хәлдән тайдылар. Һәр ике сәгать саен ясала торган приваллар вакытында сугышчылар тамак ялгадылар, ә кайберләре, кайда тукталсалар, шунда сузылып ятып, татлы йокыга талдылар.

Шушындый привалларның берсендә Рөстәм, җиргә сузылып ятып, бер генә минутка дип, күзләрен йомган иде — изрәп йокыга киткәнен сизми дә калды. Ул уянганда, дөнья яктырган иде инде. Әйләнә-тирә буш, полк киткән иде. Бәлки, куып җитәрмен дип, Рөстәм, сикереп торып, юлга чыкты. Ләкин аяклар кургаш сыман авыр күтәрелделәр, теләккә буйсынмадылар. Рөстәм юл кырыена чыгып утырды. Аның авызы кипкән иде. «Су, бер генә йотым су булсын иде хәзер»,—дип уйлады. Бер йотым су никадәр шифа булыр иде аңа.

Аның күз алдына Идел һәм Кабан күле килеп басты. «Өйдә хәзер чәй эчә торганнардыр»,— дип уйлады ул... Борынга өй исе килеп бәрелгәндәй булды, Рөстәмнең ачуы кабарды:

—Син дә солдат исемен, фронтовик исемен күтәреп йөргән буласың шунда,—дип, ул үз-үзен тиргәргә керешге,—шуңа да түзмәгәч, өйдән чыкмыйлар аны...

Аның каршыннан әле фронтка, әле тылга таба автомашиналар узып тордылар. Башта ул аларга игътибар итмәде, соңра кайсын булса да туктатып, менеп утырырга теләде, хәтта: «Утыртыгыз!» — дип тә кычкырып карады. Ләкин бер генә машина да туктамады, алар, Рөстәмгә үч иткәндәй, аның яныннан мөмкин хәтле кызу узган кебек тоелдылар.

Шул арада әллә каян болытлар чыкты һәм алар, берсе-берсенә кушылып, бөтен күк йөзен каплап алдылар. Озак та үтмәде, коеп, яңгыр ява башлады.

Яңгыр Рөстәм өчен бик җай туры килде, ул, куанып, юл кырыендагы чокыр янына килеп туктады һәм бу минутта аның өчен балдан да татлырак тоелган яңгыр суын тәмләп эчәргә кереште. Башта комсызланып, соңра су җыелганны көтеп, ашыкмыйча эчте.

Мондый вакытта тик торырга ярамаганлыкны Рөстәм аз-маз аңлый иде инде. Ул, таеп егыла-егыла, һаман алга, ут сызыгына таба юл алды. Ә машиналар, пычрак су чәчрәтеп, янгынга чыккан шикелле оча бирделәр.

Д. авылына Рөстәм бөтенләй хәлдән таеп керде. Ул килеп кергән Д. авылы сугышка хәтле, бәлки, зур да булгандыр. Хәзер исә авыл бик кечкенә булып күренә, анда бары биш-алты гына йорт сакланып калган. Йортлар тирәсендә Рөстәм кызыл хаҗ билгесе ясалган палаткалар күрде һәм адымнарын кызулатты.

Кыздырылган суган исләре, борынны кытыклап, Рөстәмне ашханәгә китерде. Ул кухняга узды һәм, мич янына утырып, чыланган өс-башын киптерергә тотынды. Тәнгә җылы кергәч тә түзмәде, өстәлдән икмәк алып, плита өстендәге котлет һәм бәрәңгеләрне ашый башлады.

Аш пешерүче:

— Нишләттегез инде, нишләттегез?.. Котлетларны кая куйдыгыз? Тиз булыгыз, начальник көтә,— дип, буран куптара башлаганда, Рөстәм печәнлектә ял итеп ята иде инде.

Урамга ул икенче көнне иртә белән генә чыкты. Төнне саташып, төшләр күреп уздырды. Төшендә, имеш, Германия җиңелеп, сугыш беткән. Гитлер качкан булган, ләкин аны эзләп тапканнар һәм үтергәннәр. Үтерүче Расад дигән кушаматлы бер кеше икән. Әмма кешеләр Расадның кем булуын белмичә аптырыйлар икән.

Рөстәм, онытылган төшен хәтерли-хәтерли, яралыларны кабул итә торган палатка янына килде. Палатка янында авырулардан бушап калган кечкенә автобус сыман машина тора иде. Палаткадан бер лейтенант килеп чыкты һәм шофёрга:

— Киттек! — дип кычкырды.

Рөстәм, моны ишетүгә, ашыгып, машина эченә кереп утырды.

Безнең нәни каһарманыбыз пыяласы ватык тәрәзәгә башын тыкты һәм кызу хәрәкәттән бәрелә-сугыла күзәтеп барды. Алар рәт-рәт тезелгән блиндажлар яныннан үтteләр, чокырлы юллар һәм траншеялар аша кичтеләр.

Бабайлар: «Эзләгән табар»,—дигәннәр. Рөстәм дә эзли торгач тапты. Дөрес, ул байтак михнәт чикте, аңа ач та йөрергә, дер-дер калтыранып, йокысыз төннәр дә уздырырга туры килде. Ни булса, шул булды, әмма Рөстәм үзенекен итте. Дон елгасы буеннан Иделгә, тарихи көннәр кичергән Сталинград шәһәренә килеп чыкты.

Расад.

Сталинградчылар үлемнән курыкмыйча сугыштылар. Сталинградчылар белән бергә, Рөстәм дә сугышка катнашты, ләкин сугыштан ул, җиңелчә яраланып, бик тиз чыкты. Аның сул аягын шаян пуля чеметеп узды...

Ул, аксый-аксый, читкә китеп утырды. Яралану аны нык уйланырга мәҗбүр итте. Табибларга күренә алмау, ярасын үзенә бәйләргә туры килү, аксау һәм сызланулар аны бик аз пошындырдылар. Ул ялгызлыктан сызланды, сугышка кереп тә, анда үзенә эш таба

алмауга борчылды. Ике-өч көн уйланып йөри торгач, Рөстәм разведчиклар блиндажына килеп эләкте һәм немецларга каршы немецлар ягына чыгып көрәшергә карар итте.

Бу куркынычлы сәфәргә ул кич белән кузгалды. Аның бәхетенә каршы сугыш тынган чак иде. Рөстәм, мина куелган сукмакларга яки кырларга эләкмәс өчен, саклана-саклана, юлның уртасыннан атлап барды. Таң атканда, немецлар тылында иде инде. Ул ике юл чатындагы блиндаж янында немец офицерын очратты. Рөстәм пистолетын чыгарды һәм, моңарчы күргән барлык газап-михнәтләр өчен ачу кайтарырга теләп, офицерга атып җибәрде. Офицер, киселгән агачтай, җиргә ауды. Рөстәм блиндажга керде, анда кәгазь кисәгенә «Партизан Расад» дип язды һәм аны немец офицерының кесәсенә салды.

Рөстәм Асадуллин ничек эш итәргә кирәклекне хәзер яхшы аңлый иде. Җае чыккан саен, ул исәпне арттыра торды һәм «Партизан Расад» сүзләре немецлар арасында телгә дә керә башлады инде.

Төннәрдән бер төнне безнең каһарманыбыз снарядлар төялгән һәм юлга чыгарга әзер торган немец машиналарын очратты. Ул ике-өч сәгать буена шул колонна тирәсендә чуалды һәм, кулларын авырттыра-авырттыра, балоннарның кайсын кисеп, кайсын тишеп, колоннаны сафтан чыгарды. Алгы машинаның бозык тәгәрмәченә, гадәттәгечә, «Партизан Расад» дип язу тыгып калдырды.

Бу искиткеч вакыйганы тикшерергә ниндидер усал полковник килде. Ул кемнедер тиргәде, кемнедер кулга алырга кушты, кемнедер тотып яңаклады. Немецларны үзара кайнаштыру Рөстәмгә кызык тоелды, аның

кәефе килде. Ул «Партизан Расад» дигән язу кисәген әлеге полковникның кесәсенә салды һәм аңа атып җибәрде.

— Тотыгыз! Бәйләгез!

— Атыгыз! — дип акыру-бакыру китте, шау-шу кузгалды. Ләкин кемне тотарга, кемне бәйләргә, кемне атарга белмәделәр. Берсе икенчесеннән шикләнде. Җәрәхәтләнгән полковник кесәсеннән дәһшәтле язу килеп чыккач, берәм-берәм сыздырта башладылар.

Немецлар арасында йөрүдән, алар белән бер өйдә, бер блиндажда бергә кунып, юк-бар сүзләрне тыңлап ятудан Рөстәм тиз туйды. Ул үз ана телен сагынды. Аның бу якын телдә җыр, музыка, сүз ишетәсе килде. Сагыну, юксыну көн саен көчәйде. Хәзер инде мәктәп, андагы шау-шулы тәнәфес вакытлары, күмәк уеннар, ай саен ясала торган кичәләр, көн кебек, Рөстәмнең күз алдында торалар. Рөстәм күңелен Казанга тарталар иде. Ул, төннәрен йоклый алмыйча, торып утырып, шуларны уйлый, әти-әнисен күргән, әбисе янында әкият тыңлаган кебек була... Хискә, хыялга бирелгән шушындый төннәрнең берендә Рөстәм түзмәде: «Шауласын, гөрләсен безнең җыр...» — дип кычкырып җырлап җибәрде.

Немец офицеры Ганс йокламый иде әле — аны курку алды. Башта ул юрганын башыннан ук каплап, гүяки җырның иясен күрүдән куркып, томаланып ятты, колакларын учы белән каплады, ләкин җыр тынмады, киресенчә, тагы да куәтлерәк яңгыраган кебек тоелды. Ганс ачык хәтерли: өйдә ул бүген иң соңгы кеше булып ятты, ишекне дә үзе бикләде. Бу ят җыр кайдан соң? Ул юрган читен күтәреп, күз кырые белән генә карап алды. Ләкин өй эче караңгы иде.

Ул калтыранган кулы белән, мендәр астына сузылып, пистолет алды һәм җыр ишетелгән якка атып җибәрде.

Мылтык тавышына бүтәннәр дә уяндылар һәм, акылдан язган кешеләр шикелле, ярым ялангач хәлдә, ишегалдына йөгереп чыктылар. Ганс эшнең нәрсәдә икәнен аңлатып биргәч, яңадан өйгә кереп яттылар, җырдан курыккан офицердан көлешеп алдылар.

— Партизаннар синең төшеңә дә керә башладылар инде,— диделәр.

Пуля Рөстәмнең җиңен тишеп үтте, ә үзе ул, бу көтелмәгән кинәт атудан әллә сакланганга, идәнгә мәтәлеп төште. Җыр бүленеп калды һәм бу хәл Рөстәмнең ачуын кабартты: «Җырга атасыз, җырны атып үтермәкче буласыз...» — дип, ул өйдән чыкты, көндез баскыч астына яшереп куйган гранаталарны капшап эзләргә кереште.

Гадел Кутуй.

1. Хикәяне өегездә өлешләргә бүлә-бүлә укып чыгыгыз. Сыйныфта андагы төп вакыйгаларны үз сүзләрегез белән сөйләргә әзерләнегез.

2. Рөстәм, партизаннар янына килгәч, дошманга каршы ничек сугыша ала? Хикәяне дәвам итегез.

ФИКЕРЛЕ КЫЗ.

Бер яшь патша була. Көннәрдән бер көнне сарай яныннан бер фәкыйрь үтеп бара. Патша аны чакырып кертә дә ашарга утырта. Китереп куя бер табак токмач. Ашый бу, ашап бетерә. Патша моңардан сорый:

— Туйдыңмы, абый? — ди.

— Туйдым, туйдым, падишаһым-солтаным, бик рәхмәт,— ди. Шуннан соң патша китереп утырта бәлеш. Моны да ашап бетерә бу.

Ашап бетергәч, патша тагы сорый:

— Туйдыңмы? — ди.

— Туйдым, туйдым,— ди фәкыйрь.

Патша тагын китереп куя ит — аны да ашап бетерә. Тагы сорый:

— Туйдыңмы? — дип.

— Туйдым,— ди фәкыйрь.

Шуннан соң китереп куя чәй — чәйне дә эчеп бетерә теге.

— Туйдыңмы? — дип сорый патша.

— Туйдым, туйдым, падишаһым-солтаным, бик рәхмәт, бик күп хөрмәт иттең,— ди фәкыйрь.

Шуннан соң әйтә инде патша:

— Менә син беренче ашаган вакытта ук «туйдым» дип әйттең. Икенчесен ашап бетергәч тә «туйдым» дип әйттең. Өченчесен, дүртенчесен ашагач та «туйдым» дидең. Ә син бөтенләй туймаган булгансың икән, ди. Ни өчен алдадың? — ди.— Минем шушы соравыма җавап китер, ди. Әгәр җавап китермәсәң, иртәгә мин сине җәзага тартырмын,— ди.

Шуннан соң бу фәкыйрь кайтып китә өенә.

Кайта да бу бик уйланып утыра. Моның кызы була. Кызы әйтә:

— Нишләп, әти, болай уйга калдың? — ди.

Карт патша сараенда булган хәлне кызына сөйләп аңлата. Кыз:

— Әткәй, син кайгырма, ят та йокла, иртәгә бар да булыр,— ди. Шуннан соң, иртә торгач, кыз алып керә бер чиләк. Шуңа ваткалап таш тутыра. Әтисенә әйтә:

— Әткәй, тулдымы? — ди.

— Тулды,— ди әтисе.

Кыз чиләккә тагын ком сала, таш арасына ком да керә.

— Әткәй, тулдымы? — ди.

— Тулды,— ди әтисе.

Шуннан соң чиләккә су сала, су да керә. Кыз әйтә:

— Әткәй, бар, патшага шушы нәрсәне күрсәт тә, безнең ашказаны да шушы көенчә, аңа төрле нәрсә дә керергә мөмкин, дип әйт,— ди.

Карт бара, шушы хәлне патшага кыз күрсәткәнчә ясап күрсәтә. Патша бу хәлгә гаҗәпләнә.

— Ярар, картым, монысын булдырдың, менә мин сиңа тагын бер сорау бирәм. Иртәгә син миңа шушыңа җавап китер: ач та килмә, тук та килмә; ялангач та килмә, кием белән дә килмә; атланып та килмә, җәяү дә килмә,— ди.

Шуннан соң карт кайтып китә. Кайта да тагын хәсрәткә батып утыра. Һаман да кыз сорый:

— Әткәй, ничек, ни булды? Патша мин күрсәткәнгә нәрсә дип әйтте? — ди.

— Син күрсәткәнгә рәхмәт белдерде, яңадан бер сорау бирде, ди. Ач та килмә, тук та килмә; ялангач та килмә, кием белән дә килмә; атланып та килмә, җәяү дә килмә, дип әйтте,— ди.

Шуннан соң кыз, тагын әтисен тынычландырып:

— Әткәй, ят та ял ит, иртәгә бар да булыр,— ди.

Кыз шул ук төнне төшеп китә су буена. Анда барып балыкчының ятьмәсен алып кайта. Әтисенә шуңардан күлмәк-ыштан тегә, кесә сала. Кесәсенә көнбагыш сала да әтисен, үзләренең биш яшьлек кәҗә тәкәсенә атландырып, яңадан патша янына җибәрә.

Патша бу картның килүен көтеп тора, чынлап та, сорауга җавап бирә алырмы дип. Караса, карт кәҗә тәкәсе өстендә килә: чынлабрак карасаң — атланган кебек, ә үзе сөйрәлеп килә. Бу атланып та түгел, җәяү дә түгел. Патша моңа да гаҗәпләнә. Киемле киләме, ялангач киләме дигәндә, бер карасаң, өстенә кигән киеме бар, ләкин тәне күренә. Моны киемле дип тә, ялангач дип тә әйтеп булмый. Чыннан да, бу кеше сорауга җавап бирә алырлык. Соң инде бу ач киләме, тук киләме? Ач дияр идең, һаман ашап тора, тук дип әйтер идең, тук булса ашамас иде. Шуннан патша:

— Ну молодец, карт, бу эшләргә барысына да җавап бирә алдың. Моны каян өйрәндең? — дип, сорый.

Карт мактаныбрак:

— Минем кызым өйрәтә шул,— дип ычкындырып куя. Ә патша бу сүзгә:

— Әле син кызың белән икәү эшлисеңмени бу эшне? — дип, яңадан картка бер сорау бирә. Өстәл өстеннән кәтүкне ала да өч чирек җеп өзеп алып картка суза:

— Менә кызың миңа шушы җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегеп китерсен,— ди.

Карт җепне алып кайтып китә. Алып кайта да кызына әйтә:

— Кызым, патша безгә тагын шундый ук зур эш йөкләде. Менә шушы җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегеп китерергә кушты,— ди.

Кыз:

— Ярар, әткәй, тегәрбез,— ди. Себеркедән шырпы буе бер чыбык сындырып ала да:

— Бар, патшага әйт, шушы чыбыктан киндер сугу өчен, киндер станы ясатып бирсен миңа,— ди.

Карт, яңадан патша янына барып, кыз биргән чыбыкны патшага бирә:

— Минем кызым сезнең биргән җебегездән киндер сугып күлмәк-ыштан тегеп китерергә риза булды. Тик аның, киндер сугу өчен, станы юк икән. Шушы чыбыктан киндер станы эшләтеп бирсен, дип әйтте, кызым,— ди.

Патша, чыбыкны күреп:

— Бу чыбыктан киндер станы буламыни? — дип ачулана. Карт патшага карап:

— Падишаһым-солтаным, өч чирек җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегеп буламыни? — ди.

Шуннан соң патша әйтә:

— Менә, карт, мин сиңа җиде яшьлек сарык тәкәсе биреп җибәрәм, иртәгә сәгать уникегә мин барган төшкә сарык тәкәсе бәрәнләсен,— ди.

Карт сарык тәкәсен алып кайтып китә. Кызына әйтә:

— Патша: иртәгә мин килешкә шушы сарык тәкәсе бәрәнләп куйсын. Мин сәгать уникеләрдә барырмын, диде,— ди.

— Ярар, әткәй, бәрәнләр. Алып чык пычак, суйыйк та ашыйк,— ди. Сарык тәкәсен суялар да ашыйлар. Иртәгесен, иртә үк торып, кыз мунча яга да әтисен мунчага җибәрә.

— Мин барып алмыйча, син кайтма,— ди.

Көндезге сәгать уникеләр җиткәч, патша килә дә:

— Фәлән агай өйдәме? — ди. Кыз, тәрәзәдән башын тыгып:

— Өйдә юк,— ди.

— Кайда? — дип сорый патша.

— Әткәй мунчада бәбәйләп ята,— ди.

— Фу, шайтан алгыры, ир кеше бәбәйлимени? — ди. Шуннан соң кыз патшага әйтә:

— Син соң әткәйгә җиде яшьлек сарык тәкәсе биреп җибәргәнсең, сарык тәкәсе бәрәнлимени? — ди.

Шуннан патша, җавабы бетеп, кайтып китәргә мәҗбүр була һәм кызга әйтә:

— Әтиең минем янга килсен әле,— ди.

Кыз картны дәшеп кайта да патшаның чакырганын әйтә. Карт патша янына бара. Шуннан соң патша, картны бик яхшы сыйлап, сүз башлый:

— Бабай, кызыңны миңа хатынлыкка бир,— ди.

Карт:

— Без фәкыйрь кешенең кызын сез алмассыз бит,— ди.

Озак сөйләшеп тормыйлар, карт патшага кызын бирергә була. Озак та үтми туй була. Кыз инде хәзер — патша хатыны. Бик яхшы гына тормыш итәләр, ди.

Гадәттә әкият ничек башланса, шуның капма-каршысы белән тәмамлана. Әкиятне дәвам итик: «Патша яшь хатыны белән чәй эчеп утырганда, сарай яныннан бер картның узып барганын күрәләр...» Ул карт кем була? Аны ничек сыйлыйлар? Аннан соң нәрсә була? Ничек телисез шулай уйлап языгыз.

ЭЧТӘЛЕК

Вакыйгалар бәйләнеше.

Начар гадәте бар... *Әхмәт Исхак* 4
Яхшылыкка — яхшылык. *(Мәсәл.) Габдулла Тукай* 6
Алдакчы Наил. *Абдулла Алиш* 7
Сүз бирдем. *Алексей Пантелеев* 8

Сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше.

Кем гаепле? *(Мәзәк.)* 14
Яшәү. *Мөдәррис Әгъләмов* 14
Апрель ае. *Әминә Бикчәнтәева* 15
Су анасы. *Габдулла Тукай* 16
Хәйләкәр әтәч. *(Татар халык әкияте.)* 19
Ана бәете 21
Икмәк валчыгы. *Нури Арсланов* 22
Тылсымлы кое. *(Әкият.)* 24
Тәүге шатлык. *Габделхәй Сабитов* 30
Тәүге батырлык. *Габделхәй Сабитов* 34
Карачкы. *(Мәзәк.)* 36
Тәрбия. *(Мәзәк.)* 36
Киңәш. *(Мәзәк.)* 37
Иң яхшысы. *(Мәзәк.)* 37

Каршылык бәйләнеше.

Комсызлансаң. *(Мәзәк.)* 38
Батыр кыз. *(Мәзәк.)* 39
Этләрнең дуст булышуы. *(Мәсәл.) Габдулла Тукай* 39
Кем? *Евгений Пермяк* 42
Физзарядка ясый куян. *Шәүкәт Галиев* 43

Ял итми калам. *Мәрзия Фәйзуллина* 43
Табын янында. *Шәүкәт Галиев* 44
Тел. *Роберт Миңнуллин* 45
Озын тел. *Нур Гайсин* 45
Миңа охшаган малай. *Вәсилә Хәйруллина* 47
Хәсән белән Хөсән. *Ш. Мирмухсин* 48
Умарта корты вә чебеннәр. *(Мәсәл.) Габдулла Тукай* 51
Сәер укытучы. *(Мәзәк.)* 52
Кыңгыраулы тычкан баласы. *(Карачай халык әкияте.)* 52
Кояштагы тап. *Фәнис Яруллин* 53

Күренеп торган бәйләнешләр.

Беренче кар. *Нәҗип Думави* 57
Мәктәпкә бармадым. *Галимҗан Гыйльманов* 57

Күзгә күренми торган бәйләнешләр.

Тапкыр көтүче. *(Мәзәк.)* 59
Ярыш. *Камил Мостафин* 60
Дус. *Виктор Драгунский* 61
Җил кумадык. *Нур Әхмәдиев* 63

Әйтми калдыру.

Ялганчы. *(Мәзәк.)* 65
Тәрбияле бала. *(Мәзәк.)* 65
Жәл. *Шәүкәт Галиев* 65
Ат белән Төлке. *(Болгар халык әкияте.)* 66
Үртәсен әле мине. *Эльмира Шәрифуллина* 68
Сәгать ярдәм итте. *Юрий Ермолаев* 70
Почмакта торам. *Роберт Миңнуллин* 72
Урман читендә. *Шәриф Биккол* 73
Бүре. *(Кавказ халкы мәсәле.)* 76
Кара хурлык болыты. *Зәки Нури* 77
Кайсы кирәгрәк? *(Мәсәл.)* 77
Аңлашылды. *Шәүкәт Галиев* 77
Каз. *Габдулла Тукай* 78

Төлке белән Шакал. *(Мәзәк.)* 79
Мескен Федя. *Михаил Зощенко* 79
Кабартма. *(Мәзәк.)* 84
Сабан туенда. *Бари Рәхмәт* 85
Серне ачты. *Григорий Остер* 88

Автор хыялы.

Онытылган туган көн. *Дональд Биссет* 92
Аннабель. *Дональд Биссет* 94
Борчак өстендәге принцесса. *Ханс Кристиан Андерсен* .. 97
Еланга әйләнгән патша кызы. *(Португалия халкы әкияте.)* 100
Гулливер пәһлеваннар илендә. *Джонатан Свифт* 102
Батыр тегүче. *Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар* ... 107
Теләнче яулыгы. *(Кытай халык әкияте.)* 116

Үткән дәресләрдә өйрәнгәннәрне искә төшерү.

Су шигърияте. *Ибраһим Гази* 120
Кояш. *Камил Мостафин* 121
Өтер. *Данис Хәбибуллин* 121
Җиңел аяклы апа. *Эльмира Шәрифуллина* 122
Бер күзле кешеләр иле. *(Япон халык әкияте.)* 123
Озын-озак балачак. *Мостай Кәрим* 124

Әйдәгез, өйдә укыйбыз!

Кыйна, Әтәч. *(Татар халык әкияте.)* 125
Йолдызкай. *Дәрҗия Аппакова* 127
Ничә чыпчык? *(Мәзәк.)* 129
Өч бассейн *(Мәзәк.)* 129
Ике кыз. *(Татар халык әкияте.)* 129
Өч бөртек алтын чәч. *Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар* 134
Рөстәм маҗаралары. *Гадел Кутуй* 140
Фикерле кыз. *(Татар халык әкияте.)* 151

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 3 класса
начальной общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

В двух частях

Часть вторая

Казань. Издательство «Магариф». 2010

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар телендә
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
3 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Икенче кисәк

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 07.06.2010.
Форматы 70×90 1/16. Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,7 + форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 6,4 + форз. 0,49.
Тиражы 3100 д. Заказ О-734.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-7761-2066-4